1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2020 ИЮНЬ № 6

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

Ришат Төхвәтуллин ӨЙЛӘНЕР
вакыт җитте

өлеш пешерәбез
рецепт – авторның үзеннән

ТАССРга – 100 ел
республика тарихында –
хатын-кызлар

Венера ГАНИЕВА:

«Танылу ул – халыкның сиңа булган мәхәббәте, яратуы, карашы...»



Хәтер – мәңгелек...

Хәтер – мәңгелек...

75 ҖИҢҮ! 1945–2020



Әбиемнең абыйсы Нәкыйп Кәрам улы Айтуганов хәзерге Актаныш районы Иске Бикчәнтәй авылында туа. 1929 елда алар гаиләләре белән Әгерҗе районының Нарат авылына күченә. 1940 елда армиягә алына, шуннан артиллерия училищесына укырга җибәрелә. 1942 елда яшь командир Башкортстанга үз частена солдатлар җыярга кайткан җирдән туп-туры Көньяк фронтка китә. Сталинград оборонасында катнаша. Фронтташлары аны Николай дип атый. Хәрби документларында, бүләкләү кәгазьләрендә дә капитан Айтуганов Николай Кириллович дип язылган.

1943 елдан Өченче Белорус фронтында танкка каршы батарея командиры булып хезмәт итә. Смоленск өлкәсен, Белоруссияне, Польшаны, Көнбатыш Пруссияне азат итүдә катнаша. Берлинга җиткәндә 1945 елның апрель азагында Кенигсберг шәһәре янында каты яраланып, сул аягын югалта. Өенә ул II группа инвалид булып, протез белән 1945 елның декабрендә генә кайта.

Сугыштан соң Красный Бор районында эшли, 1950 елдан Карл Маркс исемендәге колхозга рәис итеп билгеләнә. 1979 елда алган яраларыннан 60 яшендә вафат була.

Кыю командир абыебыз дүрт орден белән бүләкләнгән: Кызыл Йолдыз, I һәм II дәрәҗәләрдәге Ватан сугышы, «Александр Невский» орденнары. Бу орден аны 1967 елда гына «эзләп таба» әле. Тагын 8 медале бар, шулар арасында: «За отвагу», «За оборону Сталинграда» медальләре.

Бүләкләү кәгазеннән юллар: «...Капитан Айтуганов Н. К. работая командиром батареи прошел боевой путь от Днепра до Восточной Пруссии, показывая пример управления батареей, с сочетанием личной отваги. Только в последних боях по уничтожению восточно-прусской группировки его батареей уничтожено 475 мм-го орудия, 9 пулеметов и до 250 гитлеровцев, подавлен огонь одной минометной батареи и до 5 огневых точек. Действуя все это время (с 13.03 по 21.03.45 г.) в боевых порядках пехоты и ведя огонь только прямой наводкой со своей батареи, капитан Айтуганов сумел с малыми потерями для себя нанести большой урон противнику. Его батарея при занятии населенных пунктов Хансвальде и Рефельд врывалась впереди пехоты, наводя страх и смятение среди гитлеровцев. В бою храбр, отважен. В любых условиях и видах боя батарея с честью выполняет поставленную задачу. Достоин правительственной награды ордена «Александра Невского».

Нәргиз АЙТУГАНОВА.
Казан шәһәре.

Бөек Җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егетләре, татар кызлары да байтак. Минем бабам, синеке, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш ишек шакымаган капка, гаилә калды микән? Җиңү таңы безгә шуңа да кадерле... Инде бу хакта бүгенге яшьләребезгә дә аңлатасы, төшендерәсе, күңелләрендә горурлык хисләре уятасы килә. Бу проект – шул хакта. Мондый ядкарьләр, бәлки, сезнең гаиләләрдә дә сакланадыр. Юк икән, аларны шушы сайттан табып алырга мөмкин: https://pamyat-naroda.ru. Бабаларыгызга орден-медальләр ни өчен бирелде икән? Балалар, оныклар белән бергә утырып эзләп карагыз әле. Әлеге тарихи документларны үз күзләре белән күргәч, Җиңү сүзенә алар инде берничек тә битараф калалмас... Табышларыгызны безнең белән дә уртаклашыгыз. Хатларыгызны көтәбез.

17/ч Кв. Вх. №-03788 31.3.45 Н

Все графы заполнять полностью

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество Айтуганов Николай Кириллович
2. Звание Капитан 3. Должность, часть Командир батареи 179 отдельного Истребительного противотанкового дивизиона 174 Стрелковой Борисовской Дивизии.

Представляется к Ордену „Александра Невского"

4. Год рождения 1919 5. Национальность татарин. 6. Партийность
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и в Отечественной войне (где, когда) В Отечественной Войне: Южный фронт с 3.10.41 по 26.12.41 г. Сталинградский фронт с 17.8.42 г. по 10.9.42 г. Западный - 3 Белорусский фронт с 12.7.43 года
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне Ранен. 26.12.41 г.; 10.9.42 г.
9. С какого времени в Красной Армии с 1939 года. 10. Каким РВК призван Красноборским РВК Татарской АССР.
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) медалью „За оборону Сталинграда"; медалью „За отвагу"; орденом „Красная Звезда"; орденом „Отечественная война 2-й степени"; орденом „Отечественная война 1-й степени" приказом по 44 СК от 27.2.45 года.
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи

1. Краткое конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

Капитан Айтуганов Н.К. работая Командиром батареи прошел боевой путь от Днепра до Восточной Пруссии, показывая пример управления батареей, с сочетанием личной отваги.
(Только в последних боях по уничтожению восточно-прусской группировки его батареей уничтожено 4 – 75 мм орудия, 9 пулеметов и до 250 гитлеровцев, подавлен огонь одной минометной батареи и до 5 огневых точек. Действуя все это время (с 13.03. по 21.03.45) в боевых порядках пехоты и ведя огонь только прямой наводкой своей батареи, капитан Айтуганов сумел с малыми потерями для себя нанести большой урон противнику. Его батарея при занятии населенных пунктов Хансвальде и Рефельд врывалась впереди пехоты, наводя страх и смятение среди гитлеровцев. В бою храбр, отважен. В любых условиях и видах боя батарея с честью выполняет поставленную задачу.
Достоин правительственной награды ордена Александра Невского.

Командир 179 ОИПТД
майор /Сухоруков/
марта 1945 года.

Ходатайствую о награждении орденом „Александра Невского"
Командующий артиллерией 174 стрелковой дивизии
Командир (начальник)
Полковник (звание) /Мишин/
Марта 1945 г.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019



Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Венера Ганиева
Фото: Анна Арахамия

Верстка:
Резеда Галиуллина
Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 19.05.2020 ел.
Заказ А-1076
Тираж 5263

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+


ПРАВДА





23 января





ТАССР
1920-2020

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургалиевич МИҢНЕХАНОВның котлавы



Татарстан Республикасы Президенты матбугат хезмәте

Хөрмәтле хатын-кызларыбыз!

ТАССРның оешуына 100 ел тулу – республикабыз халкы өчен генә түгел, бөтен дөньяга сибелеп яшәгән татарлар өчен дә зур бәйрәм.

Кайда гына гомер итсә дә, татар хатын-кызының туган телебездә гасырдан артык нәшер ителүче бердәнбер басма – «Сөембикә» журналы тирәсендә туплануы сер түгел.

Журнал битләрендә дөнья күргән язмаларның төп герое исә һәрвакыт сез – республикабыз үсешенә үз өлешен керткән ханымнар! Бүген дә сезне һәр өлкәдә, һәр тармакта очратырга була: ир-атлар белән иңгә-иң куеп эшлисез, уңышларга ирешәсез, яңа үрләр яулыйсыз. Татарстан данын еракларга ишеттерү өчен көчегезне дә, талантыгызны да, вакытыгызны да кызганмыйсыз. Әмма иң беренче чиратта сез – әниләр! Республикабыз киләчәге булачак шәхесләрне сез үстерәсез, сез тәрбиялисез. Без сезгә өмет белән карыйбыз.

Татарстан – уртак йортыбыз. Илебез һәм дөнья киңлегендә республикабызның үз урыны, үз йөзе бар. Аның туган көне барыбыз өчен дә зур вакыйга. Мин сезнең һәммәгезне шушы олы бәйрәм белән чын күңелдән котлыйм! Республикабызның киләчәге якты, барыр юлы озын булуын телим!

Татарстан Республикасы
Президенты Р. Н. МИҢНЕХАНОВ

Фотолар: редакция архивыннан

Безнең тышлыкта

«Мине студент килеш М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры труппасына кабул иттеләр. Консерваториягә кергән һәркем опера җырчысы булырга хыяллана. Миңа шушы бәхет насыйп булды!»



18 Венера ГАНИЕВАның тормыш кагыйдәләре
Гөлнур Сафиуллина әзерләде

Заман һәм без

10 Йөрәк аша узган гамәлләр
Эльмира Закирова



14 Безнең чемпион!
Лилия Гәрәева




26 Чак кына соңрак туганмын
Чулпан Галиәхмәтова

22 Яңа сауган сап-салкын сөт
Раилә Хәялиева

Татар дөньясы




34 «Казан җөе» – бренд ул!
Лилия Гәрәева



38 Якутлар табыладыр вакыт белән
Чулпан Галиәхмәтова

Мәдәни тормыш



44 Тылсым
Мәдинә Маликова

Яшәеш



50 Мин гаепле, кызым...
Гүзәл Сәгыйтова

54 «Хатынны... әтисенә карап сайла»
Илнур Миргалиев

Хуҗабикә





60 Өлеш рецепты – авторның үзеннән

ТАССР
1920-2020





ДЕКРЕТ

27 май 1920 ел.

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы карар бирәләр:

1. Татарстан Совет Социалистик Җөмһүриятен Россия Федератив Совет Социалистик Җөмһүриятенең бер өлеше буларак оештырырга...

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Рәисе М. КАЛИНИН.

Халык Комиссарлары Советы Рәисе В. УЛЬЯНОВ (ЛЕНИН).

Д. БУНТУКОВ,
В. ЗОТОВ,
Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ
фотолары.

ТАТАРСТАН ӨМЕТ



1920 нче елның 26—27 сентябрендә Татарстан АССР Советларының 1 нче Оештыру съезды була. Үзәк Башкарма Комитеты Рәисе итеп Борһан Мансуров, Халык Комиссарлары Советы Рәисе итеп Сәхипгәрәй Сәетгалиев сайлана.

Соңыннан аларның һәр икесе дә репрессиягә эләгә.

●

Татар халкының дәүләтчелеге 1552 нче елга кадәр үк булган. ТАССР исә аның 400 еллап вакыт үткәч яңа торгызылуы белән әһәмиятле.

Бу чорда халык хуҗалыгы, бигрәк тә индустрия, югары үсешкә иреште. Мәдәният, сәнгать өлкәләрендә дә күзгә күренерлек уңышлар бар. Ата-бабаларыбыз җирендә нефть ятмаларының табылуы исә республикабызның йөзен тамырдан үзгәртергә тиеш иде. Тик алай барып чыкмады. Чөнки ул байлыкларга без хуҗа түгел. Мәсәлән, промышленность предприятиеләренең 98 проценты үзәккә буйсына. Кыскасы, автономиябезнең хокуклары бик чикле, ул халык баглаган өметләрне аклап бетермәде.

Шуңа күрә киң җәмәгатьчелек Татарстанга союздаш республика статусы бирүне хуплый. Бу фикер Татарстан АССРның яңа сайланган Югары Советы сессиясендә дә яңгыраш тапты.

Татарстан, ниһаять, күпмилләтле СССР халыклары дәүләтчелегендә лаеклы урынын алсын иде.













ТЛӘР ЧАТЫНДА














Д. БУНТУКОВ фотосы.

Татарстан ССР Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев.

БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТ

Татарстан ССР Югары Советының дүртенче сессиясе тәгәлләнүнең икенче көнендә үк Минтимер Шәрип улы Шәймиев журналистлар белән очрашты. Очрашуда бик күп хак сүзләр сөйләнелде, әмма минем күңелгә кереп калганы сәясәткә дә, суверенитетка да кагылмый. Авылда туып-үсеп, ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен канына сеңдергән җир кешесе сүзләре иде бу.

— Уҗымнар әйбәт күренә,— диде ул эчке бер куану белән,— яңгырлар да явып китсә, шәт, икмәкле булырбыз.

Элек җитәкчелекнең югары баскычында торучылар шарт фигыль кулланмыйлар иде. Ел башында ук йөкләмәләргә центнер-тонналар зур төгәллек белән языла иде. Табигать исә барыбер үзенекен итте, йөкләмәләргә дә, түрәләргә дә карап тормады. Ә бу кешелекле гади мисал Минтимер Шәймиевның реаль чынбарлыкка таянып эш итүен дәлилли. Аны нәкъ менә шуның өчен, җир кешесе булган өчен ихтирам итәләр дә. 12 июньдә үткән сайлаулар моны бик ачык күрсәтте. Сайлауда катнашучыларның 70 проценттан артыгы Минтимер Шәрип улы Шәймиевны яклап тавыш бирде. Бу зур җиңү!

Гади сайлаучы, журналист буларак, мин Минти́мер Шәриповичны 3-4 ел дәвамында даими рәвештә күзәтеп киләм. Аның турында кешеләрнең фикерләренә колак салам. Әйтик, кайберәүләр сайлауда альтернатив кандидатлар булмады, Шәймиев хакимияткә, диктатурага омтыла, диләр. Ләкин фактлар моның киресен исбатлый. Мәсәлән, күп кенә депутатлар Татарстанның Президентын сессиядә сайларга кирәк, дигән тәкъдим кертteләр. Минтимер Шәрипович исә моңа каршы төште, үз фикерен башкаларга җиткерде һәм, иң мөһиме, ышандыра

алды. Мин үзем андый җаваплылыкны үз өстемә алмас идем, диде ул.

Шәхси властька, дан-шөһрәткә омтылган кеше, миңа калса, әлеге мөмкинлеккә теше-тырнагы белән ябышкан булыр иде.

Президент кирәкме-юкмы, дигән икеләнүләр чоры үтте инде. Халык бу мәсьәлә буенча катгый сүзен әйтте — кирәк! Аның шулай икәнлеге көн кебек ачык үзе. Чөнки ул табигатьтән килә. Төркемнәргә бүлгәләнгән барча җан иясе үзенең язмышын башлыкка ышандыра. Башлык исә бу ышанычны аклау өчен хәтта үлемгә дә бара. Безнең шик-шөбһәбез нигезсез дә түгел. Элек җитәкчене, халыкны узып, аның уй-фикерләре белән исәпләшеп тормыйча, югарыдагы түрәләр куя иде.

Күпләрнең фикере уртак — Минтимер Шәймиев Татарстан республикасы, анда яшәүче халыкларның мәнфәгатьләре өчен, халык әйтмешли, утка да, суга да керер. Ул моны исбатлады инде. Хәтерегездәдер, май аенда газеталар, радио-телевидение тапшырулары аша сенсация шары тәгәрәгән иде.

Союз договоры буенча югары дәрәҗәдәге сөйләшүләрдә Татарстанның аерым фикере турында бөтендөнья белде. Ул вакыттагы Татарстан ССР Югары Советы Рәисе М. Ш. Шәймиев республика халкының наказын әнә шулай, бер якта ялгызы гына калган хәлдә дә, зур фидакарьлек белән тормышка үткәрергә тырышты.

Аерым фикерең булу, аны исбатлау кешедән ныклык, барыннан да элек, абруй, компетентлык таләп итә. Безнең Президентта бар андый абруй. Бу бик зур отыш. Чөнки суверенлыкны реаль рәвештә тәэмин итү, практик эчтәлек белән тулыландыру чоры әле яңа башланып кына килә. Башка республикалар, чит илләр белән икътисади, сәяси бәйләнешләр булдырырга, договор-килешүләр төзергә кирәк. Президентның югары абруе, компетентлыгы бу шартларда бөтен республикабызның казанышына, байлыгына әверелә.

Милли республикаларның, милли хисләрнең уянып, гаять киң дәрәҗәдә таралган чорын кичерәбез. Шушы катлаулы заманда Президент тоткан позиция гаять зур әһәмияткә ия. Сәясәтнең иң четерекле ягы бу. Бер яктан, Татарстан — татар халкының туган ягы, тарихи бишеге. Икенче яктан, бездә бик күп милләтләр аралашып, кушылып яшиләр. Башкаларның хәленә дә кермичә ярамый. Үзара ызгыш-талаш килеп чыкмасын өчен иң дөрес таяну ноктасын табарга кирәк. Минтимер Шәрипович бу җәһәттән дә гадел сәясәт алып бара. Ул — интернационалист. Президент өчен, сабырлык һәм таләпчәнлеккә дә кертеп, әлеге сыйфатлар бик зарур дип саныйм мин.

Яшь чагында Минтимер Шәймиев прокурор булырга хыялланган диләр. Ләкин әлеге хыялы гамәлгә ашмый. Юк, булдыра алмаганнан түгел, мәктәпне бишле билгеләренә генә бетерә ул, бәлки, әтисенең, колхоз башлыгының, киңәшен тота. Колхоз өчен ул вакытта МТСтан да югары башка матди көч юк, тракторы да, комбайны да шунда тупланган. Ә Казан авыл хуҗалыгы институтында МТСлар өчен баш инженерлар хәзерлиләр икән...

Әтисенең фатихасын алып шул институтка юнәлә Минтимер. 25 яшендә инде ул Минзәләдә «Сельхозтехника» берләшмәсе белән җитәкчелек итә, 32 яшьтә министр дәрәҗәсенә күтәрелә. Тәҗрибә әнә шулай туплана.

Минтимер Шәймиев 1937 елда Актаныш районының Әнәк авылында туган. Гаиләле. Тормыш иптәше Сәкинә ханым белән ике ул тәрбияләп үстергәннәр. Инде ике оныклары бар. Гармунда уйный, бакчада эшләргә ярата.

Ниһаять, Татарстаныбызның халык үзе сайлап куйган үз Президенты, үз башлыгы булды. Күп меңле укучыларыбыз, редакция исеменнән без беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевны үзенең законлы вазифасына керүе белән тәбрик итәбез. Сәламәтлек, бәхет, уңышлар телибез.

...Журналистлар белән очрашуының икенчеме-өченчеме көнендә яңгырлар башланды. Шәт, икмәкле булырбыз!

Марат ӘМИРХАНОВ.

© «Сөембикә», 1991.

ТАТАРСТАН ЕЛЪЯЗМАСЫ

■ **1920 ел, 27 май** – ВЦИК һәм РСФСР Совнаркомы декреты белән 1920 елның 25 июне Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешу көне дип игълан ителә.
■ **1921 ел, 25 июнь** – Татарстан ЦИКы һәм СНКы барлык дәүләт учреждениеләрендә татар теле дәүләт теле булу турында Декрет кабул итә.
■ **1921–25 еллар** – Татарстанда яңа экономик политика (НЭП) еллары.
■ **1929 ел** – Татарстанда латин алфавитына күчәләр.
■ **1929–33 еллар** – ТАССРда крестьян хуҗалыклары күмәкләшә.
■ **1937 ел, 25 июнь** – ТАССР Конституциясе кабул ителә.
■ **1939 ел, 5 май** – ТАССР Верховный Советы Президиумы Указы белән татар язуы кириллицага күчә.
■ **1943 ел, 25 июль** – Татарстанда Шөгер авылы янында беренче тапкыр кара алтын ятмалары табыла.
■ **1957 ел** – Мәскүдә Татарстан АССР сәнгате һәм әдәбияты декадасы уза.
■ **1958 ел** – «Казаньоргсинтез» заводы төзелә башлый.
■ **1967 ел, 31 июль** – Түбән Кама нефтехимия заводы беренче продукциясен бирә.
■ **1969 ел, 13 декабрь** – ялан кырда экскаватор Кама автомобиль заводы урнашачак мәйданны казый башлый, КамАЗ Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше дип игълан ителә.
■ **1976 ел** – беренче КамАЗ машинасы конвейердан төшә.
■ **1984 ел** – Алабугада Кама трактор заводы төзелә башлый.
■ **1987 ел** – Казан аэропортыннан беренче халыкара очыш ясала: Ту-154 самолеты Берлинга оча.
■ **1990 ел** – Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителә.
■ **1991 ел, 12 июнь** – Минтимер Шәймиев Татарстан Президенты итеп сайлана.
■ **1992 ел** – Татарстан Республикасының яңа Конституциясе кабул ителә.
■ **1995 ел** – тузган торак республика программасын тормышка ашыру башлана.
■ **1997 ел** – Казанда метро төзелә башлый.
■ **2000 ел** – Казан Кремле ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелә.
■ **2002 ел** – Саескан Тавы янында Кама елгасы аша күпернең беренче чираты тапшырыла.
■ **2005 ел** – Казанның меңьеллыгы. Колшәриф мәчете, «Миллениум» күпере, «Татнефть-Арена» үзәге, Казан метросының биш станциясе ачыла.
■ **2006 ел** – «Алабуга» махсус икътисадый зонасы төзелә.
■ **2010 ел, 25 март** – Рөстәм Миңнеханов Татарстан Республикасы Президенты итеп сайлана.
■ **2010 ел** – Республикада Борынгы Болгар һәм Зөя утраушәһәрчегендә төзекләндерү эшләре башлана.
■ **2013 ел** – Казанда студентларның XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасы уза.
■ **2015 ел** – рәсми рәвештә Иннополис шәһәре ачыла.
■ **2018 ел** – Казанда футбол буенча Дөнья чемпионаты уза.
■ **2019 ел** – Казанда WorldSkills Бөтендөнья һөнәри осталык чемпионаты уза.





ЙӨРӘК АША УЗГАН ГАМӘЛЛӘР

Эльмира ЗАКИРОВА

Сәясәттә хатын-кызлар күп түгел. Ә булганнары – югары сыйфат билгесенә ия! Зирәк, алдан күрә белүчән, тәвәккәл, үҗәт, тырыш, булдыклы... Аларның һәркайсы кабатланмас зур шәхес. Һәркайсы республикабыз тарихында якты эз калдырган ханымнар. СССРда тәрбияләнеп, комсомол-партия мәктәбендә чыныгып, матур идеалларны маяк итеп ялкынланып эшли, оештыра белгән, эш дәверендә асыл сыйфатлары белән ачылган чын лидерлар. ТАССРның 100 еллыгын каршылаган көннәрдә сәясәттә һәм иҗтимагый тормышта үзен таныткан шундый күренекле шәхесләрне барлыйбыз. Әйе, гомерләрен җәмәгать эшенә багышлаган хатын-кызлар бар алар. Элек тә булган, хәзер дә бар, киләчәктә дә булырлар. Күп уртак яклар, охшашлыклар берләштерсә дә, һәркайсының үз йөзе, үз язмышы, үз вәкаләте. Атаклы мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдиннең үткән гасыр башында чыккан «Мәшһүр ханымнар» дигән китабы искә төшә. Татар дөньясының данлыклы хатын-кызлары анда. Бүген без дә Мөхлисә Бубый, Зөһрә Акчурина, Фатиха Аитова, Гөлчирә Гафурова, Абруй Сәйфиләрне аерым бер хөрмәт белән искә төшерәбез. Чорлар узган саен, ул исемнәр янына яңалары өстәлә бара. Республика тормышында зур роль уйнаган дәүләт җитәкчеләре, депутатлар, министрлар, иҗтимагый оешмаларның чишмә башында торучылар... Әнисә Мусина, Дания Зариповалар, Дания Дәүләтшина, Зилә Вәлиева, Роза Туфитулловалар, Флера Зыятдинова, Фәридә Гайнуллина, Гүзәлия Минкина, Римма Ратниковалар... Татарстаныбызның үсеше, аның халыкара танылуы, гел алдынгылыкка омтылуы республикабызның йөзек кашы булган бу ханымнарның матур эшләрендә дә чагыла.

Бәйрәм алды көннәрендә «Сөембикә» журналы редакциясендә күренекле сәясәтче хатын-кызлар белән «Түгәрәк өстәл» янында очрашу уздырырга алдан ук уйлап куйган идек инде. Шунысы кызык, кунакларыбыз үзләре дә журнал редколлегиясендә әгъза булып торган, хатын-кызлар мәнфәгатен яклап, зур трибуналардан чыгышлар ясаган ханымнар, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре. Таныш булыгыз: район башкарма комитеты рәисе, КПСС райкомының беренче секретаре, ТАССР Югары Советы Президиумы Секретаре, республика хатын-кызлары хәрәкәтенә юл ачкан Дания Салих кызы Дәүләтшина; балалар матбугатының талантлы баш мөхәррире, 1991–1999 елларда «Сөембикә» журналының баш редакторы, «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасына нигез салучы, депутат, Россия Иҗтимагый палатасы әгъзасы, язучы һәм журналист Роза Рәхмәтулла кызы Туфитуллова; Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе, 90 нчы елларда Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, 2000 нче елларда Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары, «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы рәисе, республикабызның бик танылган хатын-кыз сәясәтчесе Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиева; Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы, «Яңарыш-Возрождение» республика фонды башкарма директоры Татьяна Петровна Ларионова.

Республикабыз юбилеен каршылаган көннәрдә үзләре эшләгән чорның кайсы вакыйгаларын, башкарган нинди игелекле эшләрне сагынып искә төшерә икән алар? Ни өчен? Нәрсәсе белән кадерле ул көннәр? Нинди эш-гамәлләре белән горурланалар? Шулай килеп чыкты инде: бүгенге катлаулы вазгыять сагынышып күрешергә, күзгә-күз карашып сөйләшергә, күзләрдә балкыган шатлыкны тоярга, елмаюларын күрергә мөмкинлек бирмәде. Онлайн: телефон, электрон адрес, ватсаплар аша гына аралаштык. Барыбер дә никадәр күңелле, җылы әңгәмә килеп чыкты! Телефон аша аралашып искә төшерелгән ул көннәр матур хатирә, үткәннәрнең якты мизгелләре булып күңелдә уелып кала. Ә без аларны республикабыз тарихының бер бите, сагынып сөйләнгән бер хикәя итеп кабул итәбез.

ТАССР 1920-2020











Дания Дәүләтшина: «Терешкованың үзенә бардым!»

– Хатын-кызларның тормыш-көнкүрешен яхшыртырга, эш шартларын җиңеләйтергә кирәк дигән уйлар һич тынгы бирмәде миңа. Алексеевскийда эшләгәндә дә, Биләр, Лаешларда да шул уй гел башымда йөрде. Япь-яшь кызлар резина итекләр киеп, пычрак ерып, иртән дүрттә сыер саварга килә. Куллары яргаланып беткән! Кул белән савалар. Берниндимеханизация юк. Җылы су юк та юк инде! Шулкадәр авыр иде эшләре! Бу тормышны ничек җиңеләйтергә дип баш вата идем. Хатын-кызларның эш шартларын яхшырту уе шулкадәр тирән кереп утырды йөрәккә – соңрак, инде югарырак урыннарда эшләгәндә дә шуларны кайгыртудан туктамадым. Татарстан Югары Советы Президиумы Секретаре булып эшли башлагач, хатын-кызлар проблемаларын чишәрлек оешма булдырасым килде. Мәскәүдән тәҗрибә туплап кайтырга хыялландым. Авыл районнарындагы хәлләрне белеп, күреп торам бит инде: тормышлары җиңел түгел. Бөтен эшне җигелеп тарталар, хезмәт өчен уңай шартлар юк. «Түбән Кама Нефтехим», «Түбән Кама шин» предприятиеләрендәге, «Оргсинтез», РТИ заводларындагы зарарлы цехларда эшләүче хатын-кызларны исәпкә алып тикшерә башладык. Сәламәтлек саклау министры урынбасары Гөлшат Бардина белән Түбән Камага киттек. «Түбән Кама Нефтехим»да иң авыр эштә, ир-атлар керми торган цехларда – гел хатын-кызлар! Генераль директор Сәхапов белән сөйләштем. «Болардан нинди балалар туар киләчәктә?! Башка эш тап үзләренә!» – дим. Шулай итеп, 18 ләп кызны иң зарарлы цехтан чыгарттык. Шин заводында да шул ук хәл: резина исе, баш кайный, йөрәк кага, һава җитми. Япь-яшь кызлар эшләп йөри шунда! Генераль директор Зеленов белән дә ул хатын-кызларны башка эшкә күчерү турында сөйләштек. РТИда... тузан оясына барып кердек! Тагын хатын-кызлар эшли инде шунда! Ничек дәшми каласың!



Генераль директор Григорьев шулай ук проблеманы чишәргә сүз бирде. Ә бу эш шартларыннан азат иткән хатын-кызлар, безне коткардыгыз, дип, күргән саен рәхмәт укыйлар иде. Эш шартларын яхшырту турындагы фикер, минем башта зурая-зурая, хатын-кызлар мәнфәгатен яклаучы оешмага кадәр үсте. СССР дигән зур илдә яшибез. Совет хатын-кызлары комитеты дигән оешма бар. Җитәкчесе – беренче хатын-кыз космонавт Терешкова! Киттем янына. «Юк, Дания Салиховна, без бары халыкара эшләр белән генә шөгыльләнәбез. Чит ил делегацияләрен кабул итәбез, үзебез башка илләргә чыгабыз», – ди. «Хөрмәтле Валентина Владимировна, сезгә махсус килдем! Мине тыңлагыз әле, регионнарда нишләргә? Кем шөгыльләнергә тиеш хатын-кызларыбыз белән? Миңа кемнән, кайда өйрәнергә?» – дип тезәм генә сорауларымны. Фикерләремне системага салып килгән идем инде. Эшне түбәннән – авыл, район, шәһәр советлары каршында Хатын-кызлар советлары оештырудан башларга кирәген чамалыйм үзе. Соңрак халык теленә «женсоветлар» булып кереп китте ул... Тәкъдимнәремне хуплап кына калмады, киләчәктә безнең тәҗрибәне өйрәнәсе килү теләген дә белдерде Терешкова. 1985 елда республика хатын-кызларының I съездында Татарстан хатын-кызлары комитетын сайладык. Бездән өйрәнергә күрше төбәкләрдән, хәтта союздаш республикалардан килә башладылар. 80 нче елларда республикада йөзләгән «женсоветлар» – Хатын-кызлар советлары эшләде. Без беренчеләр идек!

Роза Туфитуллова: «Балалар өлешенә кермәгез!»

– 1999 ел. Дәүләт Советы сессиясе бара. «Татарстан балалары» программасына билгеләнгән 100 миллион сум акчаны кисеп, спирт заводына бирмәкчеләр. Түзалмадым, сикереп тордым да күземә яшь тыгылып, кыйсса сөйләргә тотындым. «Бер кеше картайган атасын чанага утыртып урманга илтеп ташларга җыена икән. Капкадан чыгып барганда моңа малае эндәшә: «Әти, бу чананы оны-



тып калдыра күрмә, сине дә шуңа салып илтергә туры киләчәк», – ди икән». Зал тып-тын калды. «Әгәр бүген программаны кыскартсак, белегез, киләчәктә моның кайтавазы үзебезгә төшәчәк! Нинди вөҗдан белән ятим балалар ризыгын өзеп, исерекләр санын арттырмак кирәк!» – дип, сүземне кистереп әйттем. Шунда Минтимер Шәрипович теләктәшлек күрсәтте миңа, акчаның яртысы ятимнәргә бүленде... Халык депутаты булып сайлангач, миңа нәкъ менә шушы мәсьәләләрне күтәрергә туры килде. Балалар йортларына, ятим балаларга, үз гаиләләренә шул ятимнәрне сыендыручыларга ярдәм йөзеннән бюджеттан акчаны арттырырга кирәк иде. Минем өчен иң кыен эшләрнең берсе булды ул. Башкалар батырчылык итми утырганда, әнә шулай «балалар өлешенә кермәгез!» дип акчалар даулап алу, лейкозлы балаларны дәвалау өчен 35 миллион сум акчаны алып бирү, республиканың барлык бала табу йортларына 23 миллионга төшереп УЗИ аппаратлары куйдыртуга ире-

Фотолар: редакция архивыннан

шүләр... 2000–2001 елларда республикада аналар үлеме, авыру балалар туу күзәтелә иде. Бу мәсьәләне күтәреп чыктым. Казанда төзелүче перитональ үзәкне сафка бастыру өчен шактый чабарга туры килде. Демографик хәл буенча мәсьәләне дә тирәннән күтәрдек, парламент тыңлаулары уздырдык. Барысы да киләчәгебезне кайгыртып эшләнде.

Кыз бала тәрбияләсәң, милләтне тәрбияләрсең... Бу сүзләр миңа әйтерсең узган гасырлардан, Казанда кыз балалар өчен мәктәп ачкан Фатиха Аитовалардан әманәт булып ирешкән! Нишләп әле бүген кызлар гимназиясе ачмаска дип уйладым. Хыялымда мин аны кыз балаларны хатын-кыз, әни кеше булырга әзерләү, затлы, зыялы туташлар итеп үстерү мәктәбе итеп күрдем. Кызлар гимназиясен ачу идеясе Президентыбыз тарафыннан да, халык депутатлары, җәмәгатьчелек тарафыннан да хуплау тапты. Милләтнең асыл сыйфатларын килер буыннарга тапшырырлык әниләр тәрбияләү бурычын олы максатыбыз итеп күрдек. Хәзер башкалабыз үзәгендә гөрләп эшләп ята ул гимназия! Милләтең өчен нәрсә эшләдең дисәләр, шушы гимназияне ачуда катнаштым дияр идем. Татар хатын-кызларының «Ак калфак» оешмасына нигез салдым дип горурланыр идем. Гомерем буена кылган бөтен гамәлләрем аналарга һәм балаларга багышланган булып чыкты.

Зилә Вәлиева: «Мин Казанны яраттым!»

– Мин 80 нче елларда Казанга килдем. Яңа шәһәр, яңа кешеләр, яңа эш... «Вечерняя Казань» газетасында эшли башлавым шәһәргә тагын да якынайтты: материал эзләп көн дә Казан урамнарына чыгып китәм. Аеруча тарихи үзәк бик ошый. Хәер, ул чакта бүгенге кебек үк матур түгел иде әле ул. Чөнки Кремль астында тәрәзәләре җиргә баткан кечкенә йортлар тезелеп киткән. Автобуста Казансу күперен чыгып эшкә баргандa көн дә күреп китәм шуларны. Тәрәзәләренә «Спасите нас из трущоб!» дип язылган плакатлар эленгән. Бу, чыннан да, йөрәкне өзә торган әйбер иде. Чөнки, бер яктан, шулкадәр



матур тарихи биналы университет, Кремль... һәм үзәктә шушы ук йортлар. Әле анда керсәң, шунда яшәүчеләр белән танышсаң... Казанда туып, гомер буе шушында яшәгән кешеләр. Казанның төп халкы!.. Менә шуларның язмышын күз алдында тотып, Иванов дигән бер депутат үзәктә яшәүчеләрне тузган тораклан чыгарып, уңайлы шартларга күчерү мәсьәләсен күтәрде. Минтимер Шәрипович беренче сүзеннән үк хуплап, аның тәкъдимен кабул итеп алган иде. Ул әле республиканың акчасы да аз чак, Мәскәүдән яртылаш субсидияләр бирелә торган заманның исе-җиле дә юк. Менә шул чакта бөтен оешмаларның 1 процент салымын шушы фондка түләп, әлеге эшне башлавы – җитәкчеләребезнең зур эше, горурлыгы иде. Икенче яктан, шул чорда эшләгән һәр кешенең – төзүчеме, дәүләт эшлеклесеме, архитектормы ул – күпләрнең көче керде аңа. Бергәләп менә шушы тузган торак программасын җиңеп чыгуыбыз республиканың яңа тормышына җайлашу, яңача фикерләү, яңача карау һәм кешене үзәккә куюның башлангычы дияр идем мин. Чөнки шәһәрләр төзиләр, заводлар күп, ә менә аерым кешенең язмышын шулай хәл итү – зур әйбер ул. Казанның төп халкының язмышын шушы программа хәл итте.

«Советская Татария» газетасында эшли башлаган чагым, Казан турында тырыша-тырыша махсус сан әзерлибез. Башкаланы, аның урамнарын яхшы беләсең дип, миңа Казан турында мәкалә язарга куштылар. Яздым. «Моя Казань» дип басылып чыкты. Исемле, дәрәҗәле бер журналист шалтыратып: «Карале, Зилә, синең Казанда туганыңны белми идем», – ди. «Ә мин Казанда тумадым да!» – дим. Гаҗәпләнеп: «Туган шәһәрең турында гына шулай яратып язып буладыр дип белә идем!» – диде ул. Ә бу миңа мактау сүзләре булып яңгырады! Дистә еллар узгач, безнең археологлар, эшли-эшли, казына-казына, Казанның меңьеллык борынгы шәһәр икәнен исбатлаучы чех монетасын таптылар! Академик Александр Фурсенконың бар күңелен биреп эшләүләре, бергә шатланып йөрүләре, аларның авторитеты белән башланган эше нинди зур бәйрәмгә китереп җиткерде: Казанның меңьеллыгына килдек! Миңа, вице-премьер буларак, 1000 еллык бәйрәмне оештыруда катнашырга, стадионда узган төп бәйрәм чараларында, гомумән, башыннан ахырынача кайнарга туры килде. Ул меңьеллык бөтен кешенең күңеленә үтеп керә алды! 30 августта бәйрәм узуга Мәскәүгә командировкага киттем. Төнлә генә, иң соңгы самолетка утырып, арып-талып барып төштем башкалага. Таксист, кайдан икәнемне белгәч: «О-о! Телевизордан күрдек: шулкадәр матур шәһәрегез! Казанда искиткеч зур бәйрәм уздырдыгыз!» – дип кәефне күтәрде. «Россия» кунакханәсендә дә елмаеп каршыладылар: «Булдырдыгыз! Бигрәк матур Казаныгыз!» – дип сокландылар. Бөтен ил белән шулай сөенделәр. Юбилей үткәрү комиссиясен Президент Владимир Путин үзе җитәкләде. Аларның да килеп, танышып йөрүләре, югары бәя бирүләре бергәләп эшләнгән зур эшебез, олы вакыйга булды. Менә шундый матур эшләр илне берләштерә. Кешеләрне якынайта торган вакыйгалар күңелдә озак саклана, горурланып искә аласың. Һәм ул эшләр конкрет кешеләрнең исемнәре белән хәтердә уелып кала.

«Ана даны» медалебез бар бит әле безнең. Россия күләмендә юк иде ул. Без беренчеләрдән булып үзебезнең республика медален булдырдык. Минтимер Шәрипович та, Рөстәм Нургалиевич та, Фәрит Хәйруллович та тәкъдимемне берсүзсез кабул иттеләр. Көмеш тә булсын анда, кызыл коралл да дип теләгән идем... Матур

килеп чыкты. Андый эшләр бер кеше тарафыннан гына башкарылмый барыбер. Инициативаң булса да, хуплаучылар, ризалашкан кешеләр, матди чыгымнар кирәк. Бу очракта Курчак театры төзүне искә төшерәм...

Ул елларда авыллар бетмәсен, кечкенә мәктәпләр бетмәсен дип, башлангыч мәктәпләрне үз урынында калдыру дөрес адым булды. 1 нче класстан ук баланы юлга ничек чыгарып җибәрмәк кирәк? 3 нче класска кадәр ул балалар үз авылларында, әти-әниләре янында, үзе барып кайтырлык җирдә урнашырга тиеш, минемчә. Бер ягы – башлангыч мәктәп, икенче ягы балалар бакчасы булсын дип йөргән 2000 нче еллар бу. Гореф-гадәтләрне дә, телне дә саклау мисалы булды ул. Һәр заманның үз таләпләре, әлбәттә. Мәдәният министры булып эшләгәндә опера һәм балет театрына, Камал, Тинчурин театрларына ремонт үткәреп, реставрацияләр ясый алуыбызга сөенәм. Яңаларын оештыру түгел, булганнарына акча җитмәгән чаклар бит бу. Ул чакта Минтимер Шәриповичтан, республика өчен кирәк дип, Камера хорын булдыру өчен кул куйдырдык. Ул – мәдәниятнең профессионал дәрәҗәсен күрсәтә торган әйбер.

Татьяна Ларионова: «Полинага, яшьләргә ошасын!»

– Республикабыз юбилее минем өчен Татарстан Республикасының төзелү һәм үсеш тарихын искә төшерү, кыенлыклар аша табылган уңай чишелешләрне, горурланырлык уңышларыбызны барлау ул.

Катлаулы 90 нчы еллар искә төшә: нульдән башлап, халыкны социаль яклау хезмәтен оештырырга туры килде. Ни акчасы, ни төзелеш материаллары, ни җиһазлар юк чак. Көндез өлкән кешеләр килеп йөри торган Үзәкне ачар өчен Татглавснабтан обойлар сорарга мәҗбүр булдык, ә алар балалар бүлмәсе өчен генә булып чыкты. Безнең социаль хезмәткәрләр ял көннәрендә шул обойларны базарда сатып, кергән акчага өлкәннәр учреждениесе өчен кирәк-яраклар алдык. Кемдер, бәлки, юридик яктан бу дөрес түгел дип бәйләнер.



Әмма без булышуның төрле формаларыннан файдаландык.

Әфганстанда һәлак булганнарның гаиләләрендәге үпкә-әрнүләрне мәңге онытасым юк. Әфган җирендә ятып калган ул егетләр хөрмәтенә кичәләр уздырдык. Без бүләкләр тапшырганда әтиләре сугыштан кайтмаган балаларның ничек сөенгәнен күрсәгез!.. Әфган сугышында һәлак булганнар истәлегенә куеласы һәйкәлнең ничек буласын да бергәләп уйлаштык.

Берчак гарип балалары булган әти-әниләр килде миңа. Күзләрендә – яшь. Безнең балаларга җәмгыятьтә урын юк, аларны кагалар, диләр. Инде төрле инстанцияләргә мөрәҗәгать иткәннәр, төрле кабинетларга кергәннәр. Һәркайда кабул итәләр, тыңлыйлар ди үзе. Тик проблеманы аңлаудан ары китә алмыйлар икән. Бу мәсьәлә белән үзебез шөгыльләнергә булдык. «Реабилитация» сүзе ят һәм яңа иде әле. Ә аяк-кулларны хәрәкәткә китерүдә булыша торган тренажерлар, коры бассейннар турында чит ил китапларыннан укып кына белдек. Планыбыз барып чыкты: Зорге урамында үзенчәлекле тернәкләндерү үзәге ачтык! Социаль яклау органнарындагы 15 еллык эшләребез турында сөйләгәндә гел «беренчеләрдән» дигән сүз ялгана иде. Беренчеләрдән булып инвалид балалар үзәге ачтык. Гаиләдә яшәгән килеш, балалар анда дәвалана да, укый да, өстәмә белем дә ала иде. Коляскалы инвалидлар өчен уңайлы мохит тудыруда да беренчеләр булдык, беренче пандуслар куелды. Коляскадагы кешеләр өчен туганнары һәм якыннары белән бергә яшәрлек махсус йорт төзегәч, ничек шатланууларын күрсәгез иде! Мөмкинлекләре чикләнгән кечкенә балалар өчен «әни плюс бала» Тернәкләндерү үзәге дә иң беренче бездә төзелде.

Президент Аппаратында эшләгән елларымны аерым бер җылылык белән искә төшерәм. Хатын-кыз депутатлар белән «Мәрхәмәт-Милосердие» иҗтимагый оешмасында кылган игелекле эшләребезне сөенеп хәтердә яңартам. Хәзер «Яңарыш» фондында эшләвем белән горурланам. Зирәк һәм акыллы сәясәтче Минтимер Шәймиев янәшәсендә эшләү – көн саен алга бару дигән сүз. «Яңарыш»ка үзенең белемен, тырышлыгын, хезмәтен салган, кыю планнарыбызны тормышка ашыруга үзеннән зур өлеш керткән барлык кешеләргә рәхмәтле мин. Минтимер Шәрипович көчле җитәкчеләрнең тулы бер буынын үстерде. Алар белән иртәгәге көнебезгә өмет белән карый алабыз. Бүгенге Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның гаҗәеп тырышлыгы, алдынгы технологияләргә омтылышы, катлаулы хәлләрдән чыгу юлларын таба белүе турында исә легендалар йөри хәтта! Шундый кешеләр янында эшләвем белән бәхетле мин, язмышыма рәхмәтле.


...Еш кына бер вакыйганы искә төшерәм. «Яңарыш» фонды әгъзалары белән Болгарда Идел буен карап йөрибез. Яр буен бик матур итеп төзү планы бар. Шунда Минтимер Шәрипович: «Татьяна Петровна, сез ничек кабул итәсез?» – дип кызыксына. «Миңа ошый. Бик матур булачак!» – дип җавап бирәм. Шунда ул бик җитди итеп: «Ә Полинага?» – дип сорап куя. Полина кем дисезме – минем 5 яшьлек оныгым! «Полинага, балаларга, яшьләргә ошасын ул! Киләчәктә алар бирегә киләчәк! Бу матурлык яшь буынга мирас булып калырлык булсын!» – диде Минтимер Шәрипович. Никадәр алдан күрә белеп әйтелгән сүзләр!

Матур эшләребез, үткән юлыбыз, тарихыбыз балаларыбызга, оныкларыбызга мирас булып барсын иде. Киләчәк буыннар Татарстан дигән гүзәл җирдә яшәүләре белән горурлансын иде!

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүенең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да... Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

БЕЗНЕҢ ЧЕМПИОН!



























Фото: гаилә архивыннан

Наилә ГЫЙЛӘҖЕВА:
«Тормышымда оттырулар күп булды. Әмма аларның һәрберсен җиңүгә таба ясалган адым дип кабул иттем. Җиңелүләр мине җиңәргә өйрәтте».

Фехтование буенча унике тапкыр СССР чемпионы, биш мәртәбә Европа кубогы җиңүчесе, СССР җыелма командасы составында – җиде, шәхси зачетта бер тапкыр Дөнья чемпионы, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, XX гасырда республикабызның иң яхшы спортчысы, Казанның почетлы гражданины! Атаклы спортчы Наилә ГЫЙЛӘҖЕВА турында әлеге сүзләр.

Наилә Казан шәһәренең 110 нчы мәктәбендә укый. Фехтованиегә очраклы гына килеп эләгә. Пионерлар сараенда фехтование секциясенә язылып кайткан көнне аның нәрсә икәнен дә белми әле. 1967 елдан башлап мәктәпне тәмамлаганчы беренче тренеры Александр Кислюнинда шөгыльләнә булачак Дөнья чемпионы. Өч елдан спорт мастерына нормативлар тапшыра. Александр Сергеевич Мәскәүгә күченгәндә аны үзе белән чакырса да, Наилә Казанны сайлый – тренер Владимир Житлов кул астына күчә. Яңа кыз белән бик җитди шөгыльләнә Владимир Васильевич. Әлбәттә, хезмәтенең нәтиҗәләрен дә тизрәк күрәсе килә аның, ә тренерын алыштырган спортчыга исә яңа шартларга, яңа таләпләргә күнегү өчен вакыт кирәк.

1974 елны Франциядә узган Дөнья чемпионатында фехтование буенча СССР җыелма командасы алтын медаль яулый. Бу көн әле дә хәтерендә Наилә ханымның: «Команда зачетында мин иң соңыннан чыгыш ясарга тиеш идем. Һәм шулай килеп чыкты: команданың җиңү-җиңмәвен шушы чыгышым хәл итәчәк булды. Безгә каршы – Венгриянең иң көчле фехтовальщиклары. Минем бер генә хата да җибәрергә хакым юклыгын белеп торам». Шушы ук чемпионатта Наилә Гыйләҗева шәхси зачетта бронзага ия була. Дөньякүләм беренче җиңүе бу аның! СССР җыелма командасы составындагы кызларның өчесе – Наилә Гыйләҗева, Валентина Никонова, Ольга Князеваларның Казаннан икәнен әйтү дә бездәге фехтование мәктәбенең никадәр көчле булуына дәлил. Моңа өстәп, 1976 елны Монреальдә узган XXI җәйге Олимпия уеннарында чемпион булуларын да искә алырга кирәк.

1980 елда Мәскәүдә узган Олимпиададагы чыгышын Наилә Фәйзрахмановна иң авыр җиңелү дип атый. Югыйсә икенче урынны яулау да никадәр зур җиңү! Ә ул чакта... «Минем өчен моннан да зуррак югалту була алмый кебек иде. Әйтерсең дөнья тукталды, яшәүнең яме югалды... Спортчы өчен бу хис белән яшәү бик авыр», – дип искә ала Наилә ханым ул көннәрне.

Зур спорттан китү уе да беренче тапкыр шул елны килә. «Китәргә иртә, әле алтын медаль яуларлык мөмкинлегең бар», – дип туктата аны тренеры. Һәм, ниһаять, 1982 елда Римда узган Дөнья чемпионатында Казан кызы шәхси зачетта Дөнья чемпионы исемен яулый.

1983 елны Наилә ханым спортчы карьерасын төгәлли. Башта МВДның укыту үзәгендә эшли, икенче югары белем ала, милиция подполковнигы дәрәҗәсенә күтәрелә. Бүген ул Татарстан Республикасы балалар һәм яшүсмерләрнең махсуслашкан Олимпия резервы спорт мәктәбендә тренер. Мәктәп директоры Илдар Шәймәрданов үзе дә 1986–1991 елларда фехтование буенча команда зачетында СССР чемпионы, Россиянең атказанган тренеры. Шунысы куанычлы: тренер Наилә Гыйләҗеваның Алина Фәтхуллина, Надежда Балмасова кебек яшь спортчылары үсә.

Лилия ГӘРӘЕВА

БӘЙРӘМЕҢ БЕЛӘН,



Лилия ВӘЛИЕВА, «Бельгия татарлары» берлеге җитәкчесе

Бельгиядә яшәүче татарлар исеменнән халкыбызны, республикабызны ТАССРның 100 еллык юбилее белән ихлас котлыйм! Татар халкы – Россиядә иң күпсанлы халыкларның берсе. Алга таба да үзара килешеп, татулыкта яшәргә насыйп булсын. Татар теле һәм милли мәдәниятебезнең статусы үсә барсын! Татарстанның барлык халкына бәхет, тынычлык, ә республиканың чәчәк атуын телибез! Без исә үз чиратыбызда Татарстанны дөньяга танытуда кулдан килгәннең барысын да эшлибез. Киләчәктә дә шулай булыр. Туган телгә, тамырларга, гореф-гадәтләргә, дингә моңарчы булмаганча тартылу читкә киткәч тагын да көчәя ул. Бу хис безне – Бельгия туфрагында гомер итүче милләттәшләрне дә шуңа бер йодрыкка туплады. Тарихи Ватаныбыздан еракта булсак та, күңелебез һәрвакыт сезнең белән!



Фәвия САФИУЛЛИНА, Татарстанның Уралдагы даими вәкиле урынбасары, «Урал татарлары» конгрессы рәисе урынбасары

Без, Урал татарлары, тарихи Ватаныбызның ярдәмен, кайгыртучанлыгын һәрчак тоеп яшибез. Свердловск өлкәсе белән Татарстан Республикасы арасында төзелгән сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль-мәдәни хезмәттәшлек турындагы Килешү 1997 елдан бирле башланып, даими яңартылып килә, һәм аның нигезендә бик күп эшләр башкарыла. Шулай ук Татарстан һәм Свердловск өлкәсе районнары арасында муниципальара Килешүләр эшләп килә. Әлеге килешүләр, үзара тәҗрибә уртаклашу, товар алмашу, ярдәмләшүдән тыш, төбәкләрдәге милли мәгариф һәм мәдәният үсешенә дә этәргеч булып тора. Татарстанның Халыкара аренада тоткан дәрәҗәсе, аның бүгенге көндәге икътисадый үсеше, инновацион технологияләр буенча зур адымнар белән алга китүе республика җитәкчелегенең генә түгел, алар алып барган зирәк сәясәт нигезендә чит төбәкләрдә гомер итүче татар халкының да абруен арттыруда зур әһәмияткә ия. Татарстанның куәте – Җир шарына сибелеп яшәүче бердәм татар халкында! Татарстан ул – туган телебезнең, татар милләтенең бишеге. Йөзьеллык юбилейга бездән иң зур бүләк – тамырларыбызны югалтмыйк, телебезне, татарлыгыбызны саклыйк, бердәм булыйк!



Зилә МИРГАЛИЕВА, «Мирас» татар мәдәни үзәге җитәкчесе (Канада, Монреаль)

Канада – эмигрантлар иле. Монреаль бигрәк тә. Балалар бакчаларында, мәктәпләрдә елга бер тапкыр «чит илләр мәдәнияте» дигән атна уза. Бу чара вакытында һәр бала сыйныфташларын үз халкының мәдәнияте белән таныштыра. Безнекеләр Татарстан турында сөйли! Кыз-улларыбызһәрвакыт үзләре белән «Мин – татар!» дип таныштыра. Татар чигешле алъяпкыч ябып, дусларын кыстыбый белән сыйлый, татарча биеп, җырлап күрсәтә. Татарстан турында һәр елны зур проект әзерлиләр: Татарстан туграсы һәм әләме белән таныштыралар, Казан шәһәре, Сабантуй бәйрәме, ат чабышлары күренешләрен күрсәтәләр. Татарстанны дөньяга таныту аның милли аш-суларын, җыр-моңнарын, гореф-гадәтләрен таныту аша да бара. Ике ил арасындагы элемтәләрне ныгытуга да үз өлешебезне кертергә тырышабыз. Моның өчен бар мөмкинлекләрдән дә файдаланабыз. Яраткан Татарстаныбызны бер гасырлык тарихы белән чын күңелдән котлыйбыз! Яңадан-яңа үрләр яулавын телибез!

ТАТАРСТАН!



Әлфия АЙЗАТОВА, «Франция татарлары» оешмасы җитәкчесе

Россиянең Франциядәге элеккеге илчесе Александр Орлов һәрвакыт: «Татарстанны Европаның Германиясе белән генә чагыштыра алам. Аның белән нинди генә бизнес-проект башласаң да, гел уңышлы була», – дип кабатларга ярата иде. Татарстанның даны безгә дә кагыла: диаспоралар арасында татарларны аерып куялар. Көчле, бердәм дип саналабыз. Мондагы милләттәшләрнең 80 проценты хатын-кызлар – алар бирегә дөньяның төрле почмагыннан җыелган. Һәммәбезне дә уртак Ватаныбыз – Татарстанга тартылу берләштерә. Казанны барып күрү күпләр өчен хыял әле... Хәер, француз дуслар арасында да: «Ә Татарстанга ничек барырга?» – дип сораучылар байтак. Телдә гел Казан, гел Татарстан булганны ишетеп торалар бит! Республикабыз ирешкән уңышларда үзебезнең дә уңышлар бар кебек тоябыз. Бүгенге бәйрәмебез дә уртак!

Гөлтән БӘДРЕТДИН, Финляндия ислам җәмгыяте рәисәсе

Мөхтәрәм татарстанлылар! Финляндиядә яшәүче милләттәшләрегез исеменнән сезне ихлас күңелдән Татарстан Республикасының 100 еллык бәйрәме белән тәбриклим! Дөнья буйлап сибелеп яшәүче татарлар өчен Татарстан милли үзәк булып тора. Финляндиядә яшәүче татарлар да Татарстанның хәлләрен күзәтеп килә, уңышларына шатлана һәм югалтуларын бергә кичерә. Бу шатлыклы көннәрдә республикага һәм барча татарстанлыларга даими уңышлар, матур киләчәк һәм имин юллар теләп калам! Алга таба да бергәләп газиз ана телебезне, мөкатдәс ислам динебезне һәм милли гореф-гадәтләребезне саклап һәм үстереп яшәргә бөек Раббыбыз насыйп әйләсен!



Тамир АЛИМБАЕВ, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шура әгъзасы, Омск өлкәсе татарларының милли-мәдәни үзәге һәм Омск шәһәренең җирле татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе

Без, ерак Себердә яшәүче татарлар, татарстанлыларның икътисадый казанышлары, мәдәният һәм рухият өлкәсендәге уңышлары, спорттагы җиңүләре белән хәбәрдарбыз. Алар бездә соклану, хөрмәт һәм горурлык хисләре уята! Бу казанышларның нигезе үткән елларда салынган дип беләбез. ТАССР тарихы – моның ачык дәлиле. Татарстан киләчәктә дә барлык татарны берләштереп, халкыбыз өчен рухи маяк булып торсын! Барлык татарстанлыларга саулык, иминлек, эшләрегездә уңышлар, тынычлык һәм татулык телим.

Фәрит ГЫЙБАТДИНОВ, Чуашстан татарларының милли-мәдәни автономиясе рәисе, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шура әгъзасы, «Мишәрләр» ансамбле җитәкчесе



Туган җирне сайлап алмыйлар. Безгә заманында Казан губерниясе чигендә, аннан Татарстанның Кайбыч, Буа, Чүпрәле районнарына чиктәш булып гомер кичерергә насыйп иткән. Үз җиребездә – Чуашстан Республикасында яшәү өчен бөтен уңайлыклар һәм мөмкинлекләр тудырылган. Әмма безнең өчен милли Ватан – ул Татарстан, милли башкала – ул Казан каласы. Татарстан һәм Чуашстанның автоном республика булып тарихта яшәүләренә инде 100 ел! Ике республиканы да Чуашстан татарлары исеменнән котлыйсым килә. Милли йөзләрен югалтмыйча, гомере буе ТАТАР һәм ЧУАШ республикалары булып дәүләт вазыйфаларын үтәсеннәр, горур һәм көчле булып калсыннар! Татарстан инде күптән Россиянең бөтен милли төбәкләрен үзе артыннан ияртеп баручы, аларга үрнәк булып торучы чын локомотив! Милли оеткыны кадерләп саклый – рәхмәт аңа!



«МИН ӘЙБӘТ ӘНИ БУЛЫР ИДЕМ»

Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Венера ГАНИЕВАның тормыш кагыйдәләре



ЙОЛДЫЗ ЧИРЕ БЕЛӘН БЕРКАЙЧАН ДА АВЫРМАДЫМ.

СӘХНӘГӘ КИЛҮЕМ, ҖЫРЧЫ БУЛЫП КИТҮЕМ ӨЧЕН ИҢ ЭЛЕК ӘНИЕМӘ РӘХМӘТЛЕМЕН. БУ АНЫҢ ВӘСЫЯТЕ КЕБЕК БУЛДЫ… Ул, күрәсең, кечкенәдән күзәтеп, сәләтем барлыгын, җырга тартылуымны аңлаган. Өйгә кунаклар килгәндә алар мине гел җырлаталар иде. Мәктәптә хорга йөрдем, аннан – «Саз» ансамбленә… Әнине 51 яшендә үк югалттык. Үләренә бер ел кала: «Кызым, укы, җырчы булырсың», – диде ул миңа. Ул үзе дә бик матур җырлый иде. Әтием дә гармунда уйный, җырлый иде. Тик алар җырчы һөнәре турында уйлый да алмаганнар. Әнинең дә бер хыялы булгандыр бу, менә мин аны тормышка ашырдым. Әти зур сәхнәдә җырлавымны, исемнәр алганымны күреп, шатланып китте.

ҖЫРЧЫ ҺӨНӘРЕ ҖИҢЕЛЛӘРДӘН ТҮГЕЛ. ТАЛАНТ КЫНА АЗ, ТЫРЫШЛЫК СОРАЛА. Чын профессионал булыйм дисәң, бик тырышып укырга кирәк.

УЧИЛИЩЕГА УКЫРГА КЕРГӘНДӘ ҖЫРЛАВЫМ ЧИСТА, РИТМЫМ ЯХШЫ, ӘММА ТАВЫШЫМ КЕЧКЕНӘ БУЛГАН: бүгенгемнән чыгып, ул чактагы үз-үземә шундый бәя бирә алам. Нииндидер тембр сыйфатларын ишетеп укырга алганнардыр мине дип уйлыйм. Сулышны дөрес алырга өйрәнеп, тавышны көйләргә була. Тавышны көчәйтергә («крещендо») һәм киметергә («диминуэндо») өйрәнү ул инде югары профессионализмны аңлата.

Консерваториядә опера классыннан безне М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының баш режиссеры Нияз Даутов укытты. V курста укыганда ул мине опера театрына эшкә чакырды. Студент килеш труппага кабул иттеләр. **КОНСЕРВАТОРИЯГӘ КЕРГӘН ҺӘРКЕМ ОПЕРА ҖЫРЧЫСЫ БУЛЫРГА ХЫЯЛЛАНА.** Миңа шушы бәхет насыйп булды!

КҮП ИЛЛӘРДӘ БУЛДЫМ – САНАП БЕТЕРГЕСЕЗ… ӘММА КАБАТ ПОРТУГАЛИЯГӘ ҺӘМ МАЛАЙЗИЯГӘ БАРЫР ИДЕМ. Табигате, кешеләре белән аеруча күңелгә кереп калдылар. Португалиянең Лиссабон шәһәрендә «Травиата» операсы белән чыгыш ясадык. 3 мең кешелек концерт залында! «Болар барысы да тавышымны ишетерләрме икән?» – дип шундый борчылдым! Ишеттеләр, алкышларга күмделәр! Анда тамашачы үзенчәлекле: син аңа ошыйсың икән – эмоциясен кызганмый: аяк тыпырдата, сызгыра, «браво» кычкыра… Опера җырчысы булуның ни дәрәҗәдә авыр хезмәт икәнен алар яхшы аңлый.

БУЕМ КЫСКА МИНЕМ, БИЛГЕЛЕ. Мәктәптә физкультура дәресендә дә гел иң соңгы булып басып тордым. Иң кыскасы һәм иңябыгы идем.

«Севильский цирюльник»тагы Розинага бик озак иялэштем. Ул холкыма туры килми – җилбәзәк. Наил Курамшевич минем белән шактый интекте. Җилпәзәне ничек тотарга гына да күпме өйрәтте ул?! Аннары инде, профессия таләп иткәч, фантазия эшли башлый – роленнең кызык якларын таба башлыйсың. Яратмасаң, син аның холкын тамашачыга тиешенчә җиткерә алмаячаксың. **ГЕРОИНЯҢНЫ, ҺИЧШИКСЕЗ, ЯРАТЫРГА КИРӘК.** Күпләр «Травиата»ны караганда елыйбыз дип әйтә иде. Виолеттаны йөрәгем аша уздырганга бит ул.

ТАНЫЛУ УЛ – ХАЛЫКНЫҢ СИҢА БУЛГАН МӘХӘББӘТЕ, ЯРАТУЫ, КАРАШЫ. Моның өчен бик күп еллар хезмәт итәргә кирәк. Тамашачы үзенең җырчысын бер ярата, ул аңа гомер буе тугры кала.

СӘХНӘДӘ МИН КҮБРӘК ФАҖИГАЛЕ РОЛЬЛӘР УЙНАРГА ЯРАТТЫМ. «Травиата»да Виолетта үлә, «Патша кәләше»ндә Марфа үлә, «Риголетто»да Джильда үлә…

Яшь буынны театрларда гел көндәш итеп кабул итәләр: ул бит синең үкчәңә басып, синең урынны алырга килә. Артистлар арасында көнләшү бик көчле! Ләкин **МИН ГЕЛ ЭШЛӘДЕМ ДӘ ЭШЛӘДЕМ – КЫЕК, КЫРЫН КАРАШЛАРНЫ КҮРМӘСКӘ ТЫРЫШТЫМ.**

Опера театры артистларын драма театрында уйнарга бик сирәк чакыралар. Безне хиссез, эмоциясез, бер урында басып кына җырлый торган артист дип саныйлар. Ә миңа Марсель Сәлимҗанов Мәйсәрә ролен тәкъдим итте! 1986 ел иде бу. Опера театрында да җырлап торган килеш, анда җиде сезон эшләдем. **КАМАЛ ТЕАТРЫНЫҢ ДАНЛЫКЛЫ ТРУППАСЫ БЕЛӘН БЕР СӘХНӘДӘ УЙНАУ МИНЕМ ӨЧЕН ЗУР ИҖАТ ТӘҖРИБӘСЕ БУЛДЫ.**

МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕМ БАЙТАК, ӘММА ИҢ КАДЕРЛЕСЕ – ТУКАЙ ПРЕМИЯСЕ. Опера театрындагы иң җитди партияләрем – «Травиата», «Севильский цирюльник», «Риголетто» опералары өчен 1996 елда бирелде ул миңа. Алдагы елны да куелган идем, әмма исемлектән төшеп калдым – Фәридә Кудашевага бирделәр. Бер дә үпкәләмәдем, еламадым да. Фәридә апа безнең легенда бит ул!

Сиксәненче еллар ахырында репертуарыма бик сайлап, берәмләп кенә эстрада җырларын кертә башладым. Әмма **МОҢАРЧЫ ОПЕРА КЕБЕК ҖИТДИ ЖАНРДА ЭШЛӘГӘЧ, ТАМАШАЧЫ БАШТА МИНЕ ҮЗ ИТМӘДЕ.** «Әй, ул чәрелдек җырчы», – дип кенә йөрттеләр.

Опера артистларын 20 елдан соң пенсиягә озаталар – 2002 елдан мин инде лаеклы ялда. Шул көннән тормышымның икенче этабы башланды – мине Казан дәүләт мәдәният-сәнгать институтының җырчылар әзерләү кафедрасына эшкә чакырдылар. **ОСТАЗЛЫК – ШУЛАЙ УК ҮЗЕНӘ КҮРӘ БЕР ИҖАТ.** Институтның шундый кагыйдәсе бар: талантлы балаларны музыкаль белеме булмаса да, укырга алабыз. Берәр тембрның матурлыгын ишетәм икән, мин аны үстерә алам.

ТАТАР ЭСТРАДАСЫНЫҢ 70 ПРОЦЕНТ АРТИСТЫ – МИНЕМ ШӘКЕРТЛӘРЕМ. Алар белән бик горурланам!

Фото: Анна Арахамия

һәрвакыт күзәтеп торам. Нәрсәнедер ошатмыйм икән, шунда ук шалтыратам: «Нигә мондый җыр җырлыйсың?», «Нишләп мондый күлмәк кидең?», «Нигә үзеңне шулай тотасың?»... Алар гомер буе «Венера Ганиева мәктәбе» укучылары булып саналачак.

Студентларыма да әйтәм: **АРТИСТ СӘХНӘДӘН ТАМАШАЧЫНЫ КУАНДЫРА БЕЛЕРГӘ ТИЕШ.** Күлмәге, прическасы, макияжы, туфлие белән... Җитди, зәвыклы репертуары белән! Ул сиңа хозурланып карарга тиеш – без тамашачыга матурлык җиткерәбез.

ҖЫРЧЫГА ГАСТРОЛЬЛӘР ТАМАШАЧЫ БЕЛӘН АРАЛАШУ ӨЧЕН КИРӘК. Икешәр айга сузылган гастрольләр була иде. Әлфия апа, Илһам абыйлар белән, Айдар Фәйзрахманов, Рамил Миндияр белән авылларда концертлар куеп та күп йөрелде.

Мин ЗАГСка «Башмагым» спектакленнән Сәрвәрнең туй күлмәген киеп бардым. Яңасына акча булмагандыр инде... Бүгенге яшьләрне карыйм: 200–300 әр меңгә туй күлмәкләре алалар. **БӘХЕТ – ТУЙ КҮЛМӘГЕНЕҢ БӘЯСЕНӘ БӘЙЛӘНМӘГӘН БИТ УЛ.** Иң мөһиме – икең арасында мәхәббәт, аңлашу, тугрылык булсын. Без менә Камил белән инде 35 ел бергә.

Хәзер сәхнәгә һәр чыгуым үзе бер бәйрәм: тамашачы мине дәррәү алкышлап, сөенеп каршы ала. Бүген инде нинди генә җыр җырласам да, кабул итәрләр дип уйлыйм – мине күрү дә бәхет аларга. Моны тою бик рәхәт! **ТАМАШАЧЫНЫҢ КҮҢЕЛЕН, ЙӨРӘГЕН ЯУЛАУ БИК ҖИҢЕЛ ТҮГЕЛ.** Димәк, дөрес юнәлештә эшләгәнмен!

ЕЛАП УТЫРЫРЛЫК ҮКЕНЕЧЛӘРЕМ ЮК МИНЕМ.

Минем төп тәнкыйтьчем – Камил. Ул мине әле дә тәнкыйтьли. Дөрес, хәзер йомшаграк әйтә инде... Элек каты-каты әйткән чаклары да күп булды. Андый вакытта башта үпкәли идем, аннан инде килешәм. **ТӘНКЫЙТЬТӘН, СИҢА ЯХШЫЛЫК ТЕЛӘГӘН КЕШЕНЕҢ ТӘНКЫЙТЕННӘН КУРЫКМАСКА КИРӘК.**

«ЗӘҢГӘР ТОМАН» ҖЫРЫ – МИНЕМ ВИЗИТ КАРТОЧКАМ. Халык аны хәзер дә миннән дә шәбрәк җырлаучы юк дип саный.

МИНДӘ САВЫТ-САБАДАН ДА КҮП НӘРСӘ ЮК!

ҮЗЕМНЕ БИК САБЫР ДИП ӘЙТМӘС ИДЕМ. Мин бит Кучкар! Ут! Бөтен эшне бик тиз эшләргә яратам – миңа нәтиҗәсе шунда ук кирәк. Әгәр шул мизгелдә үк тотынып эшләмәсәм, аннары сүнәм. Өйгә берәр нәрсә алганда да шулай. Кибеттә нидер күреп ошатам кайчак. Кайткач та уемда шул гына була – озак йөрмим, барам да алам.

ЧӘЧӘКЛӘР ЯРАТАМ! ХӘТТА ЯСАЛМАЛАРЫН ДА. Кайсы гына чит илгә барсам да, шуннан чәчәкләр күтәреп кайтам. Бигрәк чынга охшаганнарын күрәм дә, түзмим, алам. Аннары шуларга карап үзем булган-күргән илләрне искә төшерәм.

Концерт күлмәкләрен күбрәк чит илдән алып кайттым. Бик еш кына: «Ничә күлмәгегез бар, аларны сатасызмы, юкмы?» – дип сорыйлар. Юк, сатмыйм, барысын да саклыйм! Дөрес, бүләк иткәләгәнем бар... Яшь чактагы күлмәкләремә карыйм – шундый гадиләр. **Ә АННАН БИТ МИН ИҢ КҮП КҮЛМӘКЛЕ, ИҢ ЗАТЛЫ КҮЛМӘКЛЕ ҖЫРЧЫГА ӘЙЛӘНДЕМ.**

Үземне бөтен җирдә дә тануларының минусларын күрмим. Исәнләшәләр. «Хәлләрегез ничек?» – диләр. «Әйбәт, рәхмәт!» – дим. **МАСАЕП, КЕШЕНЕҢ ГАЙРӘТЕН ЧИГЕРЕРГӘ ЯРАМЫЙ.** Бар андыйлар... Кайбер артистларның автографларына кадәр бәя куелган: 100 сум, 500 сум сорыйлар.

ТАБЫН ЯНЫННАН БЕРКАЙЧАН ДА ТУЕП КУЗГАЛГАНЫМ БУЛМАДЫ. ШУЛ МИНЕМ ДИЕТА... Аз ашыйм, ләкин еш ашыйм. Артистка фигураны һәрвакыт сакларга кирәк, югыйсә концерт күлмәкләренә сыймый башлыйсың.

Әтине югалткач кына еладым. **БАШКА ВАКЫТ ТОРМЫШТА ИР-АТ ӨЧЕН КҮЗ ЯШЕ ТҮККӘНЕМНЕ БЕЛМИМ.**

Сөешеп ташлашулар миндә булмады. Яшьлек мәхәббәтләрен искә дә төшергәнем юк. **МИНЕМ ӨЧЕН ИР-АТ ИДЕАЛЫ ИРЕМ БУЛДЫ.** Аңа бит үлеп гашыйк идем!

Энҗе туебызны зурлап, бөтен туганнарны, шәкертләремне чакырып үткәрдек. «Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык» көне иде ул, «Казан» гаилә үзәгендә безне Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов котлады. Кунакларыбыз йөздән артык булды. Чын туй! Кияү белән кәләш кебек табын түрендә утырдык, күпме теләкләр ишеттек! Ул көнне никахыбызны да яңарттык. **ГАИЛӘ ТОРМЫШЫНЫҢ ҺӘР ЭТАБЫН БИЛГЕЛӘП ҮТӘРГӘ КИРӘК ИКӘН: УН ЕЛЫН ДА, ЕГЕРМЕСЕН ДӘ...** Ике арадагы хисләрне кабызып җибәрә ул.

Картлык куркытамы? Мин үземне инде яшь дип әйтә алмыйм – 65 тулды. 65... **ҺӘРБЕР КӨННЕҢ, СӘГАТЬНЕҢ, МИНУТНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛЕП ЯШИМ ХӘЗЕР.** Чынлап та, тормышка да, сәламәтлеккә дә җитди карамыйсың икән яшь чагында. Ә хәзер уйландыра...

Чәчәкләр бик күп бүләк итәләр, бигрәк тә туган көннәрдә, юбилейларда... **МИН ИСӘ КАШКАРЫЙЛАР ЯРАТАМ!** Хәер, безнең бакчада розаларның да шактый төрлесе үсә. Камил керә дә: «Бар, анда сарысы (алы, кызылы) чәчәк аткан», – ди. Чыгам да озак итеп хозурланып карап торам. Шуннан рәхәтлек алам!

ИРТӘ-КИЧ КӨН САЕН ӨЧӘР ЧАКРЫМ ҖӘЯҮ ЙӨРИМ – МОНЫ ЯШЬТӘШЛӘРЕМӘ ДӘ КИҢӘШ ИТӘМ. Уйларымны тәртипкә салып, җыр сүзләрен кабатлап

йөрим. Аннан велосипедка утырам, «сигезле»ләр ясыйм: склероздан саклану өчен кирәк, диләр. Боларның уңай йогынтысын сизәм. Миндәге энергияне, активлыкны күреп, ирем, энем белән аның хатыны да скандинав таягы белән йөри башладылар. Күрше урамда гына яшәүче дус кызым Миләүшә дә кушылды.

ГАДЕЛСЕЗЛЕК МИНЕ ЧЫГЫРДАН ЧЫГАРА АЛА.

«Туй күлмәге» җыры мине бер көндә популяр итте. **КАЙБЕР ҖЫРЧЫЛАРГА ТАНЫЛУ ӨЧЕН КАЙЧАК БЕР ҖЫР ДА ҖИТӘ.**

Үз йортыбызда инде 15 ел яшибез. Фатирыбыз да бик әйбәт иде безнең. Әмма репетиция ясыйм дип җырларга керешсәң, тирә-яктан күршеләр батарейга шакый башлыйлар иде. **Ә ОПЕРА ҖЫРЧЫСЫНА КӨН ДӘ ӨЙДӘ ДӘ ШӨГЫЛЬЛӘНЕРГӘ КИРӘК.** Булмас болай дип, йорт сатып алырга уйладык.

ГОМЕР БУЕ ПРОФЕССИОНАЛ КОМПОЗИТОР, ШАГЫЙРЬЛӘР ТАРАФЫННАН ИҖАТ ИТЕЛГӘН ӘСӘРЛӘР БАШКАРДЫМ – мин ул яктан да бәхетле. Бүгенге көнгә кадәр Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Ренат Харис, Наил Касыймов, Резеда Әхиярова, Луиза Батыр-Болгари, Рәшит Кәлимуллиннар белән аралашып яшәдем.

Балалар турындагы сорауны миңа еш бирәләр. Инстаграмда да язалар... Мин опера театрына эшкә килгәндә анда контракт системасы иде. Спектакль, гастрольләр бер ел алдан планлаштырыла. Ул ел тәмамлануга, алдагы елга план төзелеп куела. Ә мин бөтен спектакльләрдә дә диярлек җырлыйм... Әни булу хыялы ел саен кичектерелде дә кичектерелде шулай... Ләкин без беркайчан да үзебезнең тормышны китек дип уйламадык. Чөнки янибызда гел бертуган энемнәрнең балалары булды. Аннан – студентларым. Әни була алмасам да, аналык сыйфатларын мулдан өләштем: районнардан, башка шәһәрләрдән яшь-яшь килеш минем кулга килеп кергән ул балаларга бар яктан да тәрбия бирергә тырыштым. **ҮЗЕБЕЗНЕҢ БАЛАЛАРГА ДА МИН ЯХШЫ ӘНИ БУЛЫР ИДЕМ.**

Сугыш турында кино карасам да елыйм – **ШУНДЫЙ ҖЕБЕК ИНДЕ МИН.** «Зинһар өчен кермә төшләремә» җырын яздырган вакыт искә төште әле. Фонограммасы әзер, сүзләре өйрәнелгән – яздыр да чык бит инде. Юк, җырлый гына башлыйм – күңелем тула, елыйм... Ун тапкыр гына бүленгәнбездер. Камил дә хәтерли моны, тавыш режиссеры ул иде бит.

Ә КАЙВАКЫТ ТИМЕР КЕБЕК КЫРЫС ТА БУЛА АЛАМ. Ситуациягә карап үзгәрәмдер... Үземне максатчан дип әйтә алам. Көчле рухлы кешеләр шулай максатчан була, диләр.

АВТОБИОГРАФИК ҖЫРЫМ ЮК ШИКЕЛЛЕ. Әмма безнең кичерешләр җырларда барыбер чагыла инде ул. «Зинһар өчен кермә төшләремә» җыры, мәсәлән, бик күпләрнең тормышында булган хисне сөйли: аны тыңлаганда һәркем үзенекен уйлыйдыр.

МИНЕ ТУЙЛАРГА БИК ЕШ ЧАКЫРАЛАР. «Туй күлмәге»н сезнең башкаруда гына ишетәсебез килә», – диләр. Әлбәттә, барам! Аннан кайчак кибеттә, урамнарда: «Венера апа, хәтерлисезме, безнең туйда җырлаган идегез», – дип килеп дәшәләр. Кайдан бөтенесен хәтерлисең инде?! Әмма: «Әйе, әйе, ничек яшисез?» – дим. Сөйләп китәләр, ике балабыз бар инде, диләр. Мине кайдадыр күргән саен иң бәхетле көннәрен искә төшергән парлар шундый күп алар!

ҮЗЕМНЕ ИДЕАЛ ДИП ӘЙТӘ АЛМЫЙМ. БЕРЕБЕЗ ДӘ ӘҮЛИЯ ТҮГЕЛ.

КОЛЛЕГАЛАРЫМНЫҢ УҢЫШЛАРЫН КҮРӘ, СОКЛАНА БЕЛӘМ. Ул хәтта көндәшем булса да. (Җырчылар арасында көндәшлек бар инде ул!) «Күлмәгең искиткеч!» – дип тә әйтә алам, «Матур җырладың!» – дип тә.

Гомер буе аралашкан, югалту-табышларны бергә кичергән дусларыбыз күп түгел. Әмма алар бар! **ҖАНЫҢА ЯКЫН БУЛГАН, ДӨНЬЯГА КАРАШЛАР, ФИКЕРЛӘР, ЯШӘҮГӘ МӨНӘСӘБӘТ УРТАК КЕШЕЛӘР УЛ ДУСЛАР.**

ЯХИН, СӘЙДӘШЕВЛАРГА ТАЯНЫП, ШӘКЕРТЛӘРЕМНЕҢ ЗӘВЫКЛАРЫН ҮСТЕРЕРГӘ ТЫРЫШАМ. Мин үзем дә аларның әсәрләрендә тәрбияләндем.

СӘХНӘДӘ БУЫННАР АЛМАШУ ТАБИГЫЙ УЛ. Мин опера театрына аяк басканда анда гаҗәеп көчле труппа эшли иде: Зилә Сөнгатуллина, Хәйдәр Бигичев, Разия Үзбәкова... Мин килдем – яңа буын алышынды. Инде минем арттагылар чираты. Яшь-яшь Марфа, Джильда, Розина, Алтынчәчләрне уйный алмыйм бит инде, килешми. Алмашка зәвыклы, тырыш, югары дәрәҗәдәге буын килергә тиеш.

ТЕЛЕВИЗОРДАН ҮЗЕМНЕҢ ЧЫГЫШЛАРЫМНЫ ГЕЛ ТӘНКЫЙТЬ БЕЛӘН КАРЫЙМ. Кайчак сәхнәдә җырның эчтәлегенә тәмам кереп китәм дә, йөзем, битем турында онытам. Күзләр җитди, маңгайда җыерчыклар... Әлбәттә, җырчының кыяфәте җырның эчтәлегенә туры килергә тиеш, әмма чама дигән нәрсә дә бар. Болай итеп спектакльләрдә генә онытылырга ярый.

Эшләп тапкан акчамның күп өлешен гомер буе яңа күлмәккә, туфлигә, чәч ясатырга тоттым. Ә биткә... Битләрен операция ясап тарттырган – җыерчыкларын шомарткан хатын-кызлар байтак хәзер. Бик уңай үзгәрешләр бар, күрәм, сокланам, әмма... **БИТКӘ ЯСАЛА ТОРГАН АНДЫЙ ПРОЦЕДУРАЛАРДАН ҮЗЕМ КУРКАМ.** Бер укол кадатып караганым булды – битем кара янды. Башка моңа тотынмыйм дип үз-үземә сүз бирдем. Бик яхшы кремнар таптым – шуларны кулланам.

Гөлнур САФИУЛЛИНА әзерләде.

ЯҢА САУГАН САП-САЛКЫН СӨТ



Раилә ХӘЯЛИЕВА

Таулар артыннан кояш нурлары күренгәндә Гүзәлия һәм Марат Абзаловларның тәрәз пәрдәләре күтәрелгән, иртәнге чәйләре инде эчелгән була. Сәгать иртәнге биш. Терлекләрнең алларына печән салып, беренче савымны башлый торган вакыт.



Туган җиренә кендеге белән беркен кеше таш шәһәрдә озакка кала алмый.

Шәһәрдән – авылга

Замана алгарышларына омтылганнар – шәһәргә, туган җиргә маңгай тире белән тугры булган фидакарьләр авылга тартыла. Үзен бары җир кешесе итеп күргән, бар дөньясын туган авылына алмаштырырга әзер булганнар турында еш булмаса да, ишеткәлибез. Язмамның геройлары – Түбән Кама районы Кызыл Чапчак авылында яшәп ятучы Марат белән Гүзәлия – шундыйлардан.

1986 елда гаилә кора алар. Яшәргә дип Түбән Кама шәһәренә күчеп киталәр. Берсе – тегүче, икенчесе автомеханик. Еллар җиттеме, авылга ашыга яшь гаилә. Төп нигездәге әтиәни дә аларны көтеп, үзләренә өндәп кенә тора. Бәби чәйләрен дә, башка бәйрәмнәрне дә гел авылда уздыралар. Үзе шәһәрдә машиналар ремонтлауда, ә күңеле белән Кызыл Чапчак кырларында йөргән Марат, озак та үтми, авылда йорт сала башлый. Ә инде 1995 елда Абзаловлар яшәргә дип туган авылларына әйләнеп кайталар. Хатыны Гүзәлия үзе Минзәлә якларыннан. «Чапчак – урманлы, елгалы бик матур, үзенә тартып тора торган җир ул. Шуңа бу якларга күчеп кайтырга риза булдым. Кайнанам белән кайнатам да мине бик яраттылар, үз иттеләр. Бигрәк тә балалар үстергәндә булыштылар. Шәһәр хатыны булырга һич кызыкмадым», – ди ул. Гаилә башлыгы шәһәрдәге һөнәрен дәвам итәргә карар кыла – автосервис ачып җибәрә. Гаилә инде ишәеп, акрынлап авылга тамыр җибәргән вакытта дөньялар үзгәрә башлый: гомерлек кебек тоелган колхоз-совхозлар тарала. Башкалар дөньяны ничек көтәргә дип аптырап калган мәлдә, бергәләп утырып киңәшәләр дә, җир эшенә тотынып карарга булалар. Пай җирләрен алып иген үстерәләр. Кырдан ашлыкны җыеп алгач, урнаштыру мәшәкате килеп туа. Шул вакыт яңа хакыйкать ача алар – үзең эшкәрткәнне үз малларыңа ашату хәерлерәк икән. Шулай итеп терлек-туар да үрчетә башлыйлар. Башта сыерларны үзләренең ишегалдында асрыйлар. Инде маллар күбәя башлагач, аерым мал фермасы төзергә карар кылалар. Ферма төзергә дәүләтнең махсус программасы ярдәм итә, грант алалар. «Лизинг-грант» программасы буенча пресслап бара торган җайланмасы белән МТЗ-82 тракторы, аннары комбайн... Аларның фермерлык дәүләте хәләл көч белән берәмтекләп җыела.

– Элек тә шулай булды, хәзер дә фермерларга дәүләт ярдәменнән башка яшәргә авыр, – дип сөйли Марат абый. – Техникасы, ягулыгы, чәчүлеге... барысы да бик кыйммәт бит. Ә фермерның һәрнәрсәсе исәптә аның. Хәзер иң зур хыялыбыз – күп сөт бирә торган нәселле сыерлар аласыбыз килә. Андый сыерның берсеберсе генә дә 150–180 мең сум тора. Дәүләт ярдәменнән башка ничек аласың аны? Шуңа күрә грантка тырышып карыйбыз. Конкурс зур, грант алулары да катлаулы хәзер. Авылда нинди эшкә тотынсаң да тырышлык, үҗәтлек кирәк.

Үҗәтлек дигәннән... Гүзәлия ире турында гел сокланып сөйли: «Безнең Марат гомер буе булсын дип яшәде», – ди. Һәм... беренче машина алу тарихларын искә төшерәләр. Беренче машиналарын үз куллары белән җыйган икән алар. Советлар Союзы чоры бит, машина алыр өчен озын чират көтәргә кирәк. Ярый әле уч тутырып акчаң булса! «Жигули» турында хыял һәр ир-егет күңелендә яна ул чакта! 1987 елда Марат берәүдән ВАЗ-2101 сатып ала. Бар көчен куеп, шул машинаны тергезергә тотына. Һәр запчастьны кулыннан уздыра, җыя, сүтә... Тәки ясап чыга! Алай гынамы, «копейка»сына алтынчы маркалы кузов та алып куя әле ул, аны яшел төскә буята. Үзе җан өргән машинаны ике елдан капка төбенә чыгарып бастыра оста ирегет. Шулай итеп, гаилә «Жигули»лы була. Озак йөриләр алар ул яшел машинада, күңелдән аерып сатып җибәрүе генә авыр була. Һәр шөребенә кул җылысы сеңгән бит.

Өйдән – фермага, фермадан – өйгә...

Иртәнге биштә фермадагы сыерлар, бозаулар хуҗаларын каршы ала. Улакларга печән төшә, бозаулар су эчә, сыерлар иртәнге савымга әзерләнә. Якында гына җылы су тулы титан: чиләк, бидоннарны, саву аппаратларын күтәреп йөрисе юк. Савылган сөт монда махсус үткәргечләр аша – колбага, колбадан фильтрга һәм суыткычка килә һәм 4 градуска кадәр суытыла. Уңайлы бит, сатып алучыга барып җиткәнче сөт әчеми дә, бөтен витаминнарын да саклап кала. Яңа савылган сапсалкын шифалы сөт! Италиядән кайтарылган югары технологияләр

Фото: Руслан Исламов







PRESSA

Фермерлыкны акчага кызыгып башлау да дөрес түгел.

кулланып, тирә-юньдә салынган беренче ферма бу. Кул көчен мөмкин кадәр азрак куллануга җайланган. Иртәнге савымнан соң сөтләрне пластик шешәләргә тутырып, Марат үз машинасында Түбән Камага сөт сатарга китә. «Шәһәр урамында берәмтекләп сөт сатып утыруы мәшәкатьлерәк шул, бөтен вакытны ала, – ди хуҗа. – Көнне шәһәрдә уздырып кайтканнан соң, янәдән фермага чыгып китәргә кирәк. Терлеккә бит бүген ял итеп торыгыз әле, дип әйтеп булмый. Сыерлар күп булган вакытта сөт комбинатлары белән эшләдек, алай җайлырак, билгеле. Бу арада сыерларны киметтек әле, егермедән артыкны гына калдырдык. Коронавирус аркасында җитештергән продукцияне сатып алучылар да кимеде, катык, каймак, корт җитештерүне әлегә туктатып торырга туры килде. Мал караунің эше күп инде аның. Мин кайтканчы Гүзәлиягә әнә, чаннарны юып, ферманы тәртипкә китереп куярга кирәк, исәп-хисапны да ул алып бара. Җирләрне дә үзебез эшкәртәбез бит. Улым Мурат белән икәүләп чәчү чәчәбез, җәй буе гаилә белән печән эшкәртәбез, көзен ашлыкны җыеп алабыз. Малларга һәртөрле ризыкны үзебез әзерлибез». Мурат – 12 яшеннән сыер саварга өйрәнгән кече уллары. Хәзер дә төп терәк булып әти-әнисе белән бергә яши. Кызлары Диләрә һәм Алия үз гаиләләре белән Түбән Камада гомер итә. Шимбә-ялларда кайтып, әти-әнисенә булышып китәләр.

Сүзгә Гүзәлия кушыла:

– Газеталарда грант, миллионнар бирелде, дип язылгач, башкалар өчен фермерларга акча күктән төшә кебек тоела кайчак. Ул акча шул фермаларны ремонтлауга, техника, ягулыкка кирә дә бетә. Менә хәзер көтүче ялларга кирәк. Көтүченең бер көне кимендә 1500 сум тора бездә. Тәртибе шундый. Көненә 500, 1000 сумга эшләүләр бетте инде. Кайчак әле ул бәягә дә эшләргә кеше табып булмый. Акчадан гына да тормыйсың, яллыйсың, эшләтәсең, әмма кайвакыт кешеләрнең эшкә җавапсыз каравы гына күңелне рәнҗетә. Мондый хәлләр белән күп фермерлар очраша торгандыр. Безнең авылда фермерлык белән шөгыльләнә торган җиде гаилә бар. Кемдер җиләк үстерү, яшелчәчелек, терлекчелек белән шөгыльләнә. Фермерларның уртак проблемалары күп, шулай да күңелне төшермибез. Авылыбыз зур, матур безнең. Яшьләр дә күп кала. Шәһәрдән кырык чакрым гына булгач, шунда йөреп эшлиләр. Тиздән Сабантуйлар җитәр, бәйрәмнәр бик күңелле уза Кызыл Чапчакта.

Фермерлар тормышына кагылышлы бер күзәтүем бар минем. Еш кына дәүләттән бирелә торган махсус кредит, грантларга кызыгыпмы (алданыпмы?), биш-алты баш сыер белән гаилә фермасы оештырып җибәрәләр. Эшләгән кешегә сокланасы гына, әлбәттә. Әмма шул хуҗалыкларның күбесе төпле уңыш, җитәрлек керем ала алмыйча, эшлим дип янып торган теләкләре дә сүнеп, кредитлары өстендә генә утырып кала. Аннан инде, бөтен гаилә белән шул кредитны түләү хакына өстенә бишмәт кия, мал өстенә мал ала. Хуҗалыкларның андый хәлгә калуы кызганыч. Эш оештыра белмәгәннәнме бу, җитәрлек финанс белем булмаудамы, әллә...

Дистә елдан артык фермерлык тәҗрибәсе булган Абзаловлар гаиләсенә дә шул сорауны бирәсе иттем.

– Хак күзәтү. Тәүге эшен башлаган фермерларның күбесе уза торган юл бу. Безнең дә андый хәлләрдә калган булды, тәҗрибә җитәрлек. Кредитларга ышанып эш башлау – үзеңне төпсез чокырга алып төшү белән бер. Кредитларга якын килмәскә тырышабыз. Малыңны сатып түләсәң түлә – акчаң үзеңнеке булсын. Монда эшләгән өчен акча алмыйсың, ә эшләгәнеңне урнаштыра, сата алсаң гына кулга акча керә. Менә шунысын аңларга кирәк. Нәрсә эшләсәң дә, җаваплылык синең кулда. Безнең өчен 2015–2017 еллар бик авыр булды. Көчле җилдавыл ашлык саклый торган складларның, сарайларыбызның түбәләрен алып ташлады. Шуларны ремонтлау өчен үз кесәбездән миллионнан артык акча тотарга туры килде. Беркемгә дә үпкәләп булмый – үз хуҗалыгың! Хакыйкать шул, җир эшен акча өчен генә башлап булмый, иң мөһиме – яратырга һәм үзеңә ышанырга кирәк!

Әйе, яратырга кирәк. Тагын... бик тырышырга, ялларсыз эшләргә, гомер буена да ике тапкыр гына ялга барып кайтырга (бу хәтле мал-туарны кемгә калдырып китәсең?!), заманга җайлаша белергә, балаларга хезмәт тәмен сеңдереп үстерергә, сынмаска, сыгылмаска, оныкларга дәү әни-дәү әти җылысын да биреп өлгерергә кирәк. Тамырлары иген шыткан җиргә береккән, яшәү дәрте туфрак исе белән сугарылган, гомер буе җиргә тугры калган ихлас кешеләр генә бу сыйфатларга иядер.

...Сәгать кичке ун. Кояшның соңгы нурлары болытлар астына качкан. Алар икәүләп кичке савымнан кайтып киләләр. Әле өйдә дә хуҗалык эшләре көтә...



Абзаловларның фермасында һәрчак тәртип, чисталык...

75 ЖИҢҮ! 1945–2020

Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без – балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә. Ләкин без барысына түздек...

ИМӘННӘР ЧЫДАМАС ДАВЫЛГА ТҮЗГӘННӘР



Фото: гаилә архивыннан

Язмыш бусагаларын үткәндә ачы хәсрәтне дә, шәхси фаҗигаләрне күп күргән, әмма күңел матурлыгын, күзләренең яктылыгын, дөньяга мәхәббәтен җуймаган кешеләр була. Әбием Госманова Венера Мәүлетдин кызы да нәкъ менә шундыйлардан! Туган авылым Түбән Шашыда гомер итүче, тормыштан зарлануның ни икәнен белмәгән, яшәүдән гамь, тәм таба белгән Әбием сабый вакытыннан ниләр генә күрмәгән... Ул әле дә, инде ул көннәрдән соң сигез дистәгә якын ел үтүенә карамастан, бала чагын искә төшергәндә еламыйча сүзен дә әйтә алмый. Сугыш башланганда аңа нибары 8 яшь – әмма ул гаиләдә олы бала – энеләре Гадел белән Салихҗанга апа, әнисенә төп булышчы. Ә тормыш – авыр! Әтиләре Мәүлетдин Әстерхан якларында, Каспий диңгезендә пароходта эшли – азыктөлек, корал ташыйлар. Аягы аксак булганга сугышка алынмаган – әнә шуңа әбиләрнең гаиләсенә льготалар да, Америка паеклары да юк. Налогыңны, заемыңны тулысынча түлә! Кәҗәләре була – налог хисабына дип анысын да алып чыгып китәләр... Әниләре ничек итсә алай итеп юнәткән сыңар казны да хөкүмәт тартып ала! Ягарга юк – биш тәрәзәле өйләрен утынга сатып, мунчага күченәләр, кышка башка гаиләгә өйдәш булып керәләр... Кияргә кием юк, бер тәгам ризык юк – авылда ачлыктан шешенеп үлүчеләр күбәя. Әбиләрнең гаиләсендә дә ачлык – 3 яшьлек Салихҗан ачлыктан күзгә карап, тилмереп үлә. Әниләре урын өстендә хәл эчендә ята, әле сабыйлыктан чыгып та җитмәгән кыз бала чарасыз. Ялан аяк, өстендә иске бишмәт – авылдагы хәллерәк гаиләнең ишегенә бара ул. Ояла-ояла тәрәзәләрен шакый. Салкыннан, ачлыктан дер-дер калтырый... Ишектән хуҗа хатын күренә. «Апа, әнием авырый, кечкенә генә ипи кисәге бирә алмассыңмы?» «Хе...» – хуҗа хатын әнә шулай ди дә, ишекне каты ябып кереп тә китә. Елый-елый кайтып китүдән ни чара бар соң кызга? Өйдәш кызның, әнисеннән яшереп, салам көленә күмеп пешергән борчак кадәрле бәрәңге ашавын кызыгып карап торып, әрчегән кабыгын авызына кабуы, язгы кырдан черек бәрәңге җыеп, шуннан апаралы шулпа ясап эчүләре – без боларны тыңлаганда тетрәнсәк тә, ахыргача аңлап җиткерә алмабыз төсле. Авылда ачтан шешенеп үлүчеләр күбәйгәч, колхоз агач кисмәкләр белән эремчек суы кайтарта башлый. Бер гаиләгә ике литр шул суны бирәләр. Әнә шулай җан саклыйлар. 8 яшеннән басуда башак җыйган, әвенгә көлтә ташыган, ашлык сугу машинасын әйләндерүче атларны чыбык белән куып эшләткән кыз бала 12 яшендә инде олы хатыннар белән тулы норма үти башлый. Нормасы – тулы, ә менә эшләгәне өчен ярты гына таяк язалар – яше җитми! Урак ура, көлтә бәйли. Чүмәләндә утыз көлтә булмаса, район вәкиле мең газап белән бәйләп өйгән көлтәләреңне ишеп кенә аудара...

Әниләренә берзаман егерме биш сутый печән чапкан өчен бер стакан он бирәләр. Колхоз амбарына менеп, үлчәтеп алалар, кайтыр юлда шул онга бер генә мәртәбә телне тидереп ялап карыйсы килә! Ничек саклап кайтылган – әниләре шул оннан ничә көнгә җитәрлек ризык әзерли бит! Ә башка көннәрдә ат кузгалагын кайнаткан су, эшкә барганда-кайтканда песи борчагы, акбаш үләне... Каравылчыдан качып кына, әллә нигә бер башак уып ашау... Сабан туе килеп җиткән – ә өйдә бер ризык юк! Узган елгы бәрәңге басуына ашлык чәчкәннәр, ямь-яшел булып уҗым үсеп килә. Шул уҗым арасыннан бераз бәрәңге эзләп таба кыз, өйгә алып кайткач, әнисе шуннан коймак пешерә – бөтен сый шул...

Ачлык дәһшәтен, ялангачлыкны күргән күңел Җиңү көнен бары якты төсләрдә хәтерли. Әниләре колхоз хатыннары белән Арчадан симәнә орлык ташый. Җилкәләренә авыр капчык күтәреп җәяү кайтканда чабаталарының баулары гына кала. Ә ул көнне – кемдә кызыллы алъяпкыч, кемдә кызыл бизәкле яулык – таяк очларына шуларны бәйләп, «Җиңү!» дип сөенеп кайтканнары истә!

Сугыштан соң да сыерын да сава әбием, егерме елга якын төзелештә эшли – данлыклы «Искра» колхозының корылмаларын алар чоры төзи. «Хезмәтемне күрделәр, шөкер, Хезмәт ветераны медале биреп, зурлап пенсиягә озаттылар», – ди ул. Төп нигездә – балалар-оныклар белән бәхетле картлык кичерә. Имәннәр чыдамас давылларга түзгәннәргә генә бирелә торган яктылыгын бүләк итеп, Ак әби булып яши!

Гөлүсә БАТТАЛОВА.

Әтнә.



ЧАК КЫНА СОҢРАК ТУГАНМЫН

Татар эстрадасында тагын шундый тыйнак җырчы бар микән? Юктыр! Тәрбияле, ипле, затлы булуы җырларында да чагыла. Хәтта балачак самимилеге дә чыгып бетмәгән кебек үзеннән. Ә фикерләве исә моның нәкъ киресен сөйли. Әти-әнисе, туганнары өчен җаваплылык алып һәрвакыт ярдәм итәргә тырышуына сокланасың. Җырлый башласа тавышына, моңына мөкиббән китәсең. Ниндидер бер серлелек бөркелә үзеннән. Әдәп-әхлаклы серлелек. Сүзем – Татарстанның һәм Башкортстанның атказанган җырчысы Ришат ТӨХВӘТУЛЛИН хакында.



Син – моң шаһзадәсе. Ә үсмер чагыңда озын бормалы көйләрне яратып бетермәгәнсең. Сәхнәдән исә нәкъ шундый җырлар башкарып, тамашачы мәхәббәтен яуладың!

– Без кечкенә чакта әни ашарга пешергәндә гел озын көйләр көйләп йөри иде. *(Уйланып.)* Андый җырлар һәрчак моңсу, сагышлы була. Октябрьский музыка училищесына җырларга дип түгел, ә аранжировка ясау серенә төшенергә, баянда уйнарга өйрәнергә дип бардым. Шул чорда Филүс Каһиров озын көйләр суза башлады. Аның җырлавын ишеткәч, ул көйләрне бөтенләй башкача кабул иттем. Җырлыйсым килә башлады, өйрәндем. Мин Филүскә бик рәхмәтле!

Аңа кадәр бер дә җырлаганың юк идеме?

– Әни клубта эшләгәч, кечкенәдән сәхнәдә үстек без. Юк, җырламадым. Мин тискәре идем, җырлата алмадылар. Гел аппаратура тирәсендә чуалдым. Әтигә охшап техника ятам. Ә менә абый җырлый иде. Күрәсең, канда булгандыр: берзаман мин дә шул дөньяга кереп киттем.

Әниең Розалия ханым белән иҗатташ дуслар да икән сез. Әнә бит, ул язган җырлар да сиңа популярлык китерә. Авторы әниең булган яңа җырларны да ишетәчәкбезме әле?

– Әни бик тыйнак, үзенә тәнкыйть белән карый торган кеше. Эстәрлетамак мәдәни-агарту техникумын тәмамласа да, үзен профессионал дип исәпләми. Ә ул язган җырларны халык аеруча ярата. Бер җыр яздырыр өчен айлар буе үгетлим мин аны. Быел да шулай, ялына торгач, берничә җыр иҗат итте. Яздырган бөтен җырларымны иң элек әти белән әнигә җибәрәм. Алар инде вак иләк аша үткәрә. Әти техник ягына игътибар итә, әни мәгънә ягына бик талымлы. Менә шундый гаилә инде без.

Син әле яшь, ә үзең инде ике тугандаш республиканың атказанган артисты исеменә лаек булдың...

– Башкортстанның атказанган артисты исемен бирү турында хәбәр килгәндә без гаилә белән юлда идек. Барыбызның да күзләренә яшь килде бугай. Бер елдан соң Татарстанның атказанган артисты исеме бирелә дигән сөенечле хәбәрне ишеткәндә дә әти-әни янымда иде. *(Елмаеп.)* «Яхшы хәбәр бар», – дигәч, әнинең беренче соравы: «И улым, әллә өйләнәсеңме?» – булды. Бу исемнәр минем өчен бик кадерле. Аларны сорап алмадым. Исем алыр өчен кайберәүләрнең ниләр кылганын күреп, исем артыннан йөрмәячәкмен, дип үземә сүз биргән идем.

Ришат, Татарстан һәм Башкортстан синең өчен?

– Туган ягым Башкортстан – горурлыгым. Ул мине һәрвакытта кочак җәеп каршы ала. Татарстан дан-шөһрәт биргән, мине дөньяга таныткан икенче өем. Аңа бик рәхмәтлемен. Монда яшәгәнемә шатланып бетә алмыйм. Гомумән, ике республиканы бүлеп карамыйм. Алар минем өчен бертуган агайлар кебек.

Бер әңгәмәңдә 45–50 яшьләрдә сәхнәдән китәчәгеңне әйткәнсең. Сәхнәсез тормышыңны күз алдына китерә аласыңмы?

– Һәрвакыт гастрольләрдә – чегәннәр кебек йөрибез бит. Яшь барган саен, күңел өйгә тарта икән. Спорт белән шөгыльләнәсем, балалар тәрбиялисем килә. Продюсерлык үзәге ачу хыялым бар. Яшь җырчыларга ярдәм итәр идем.

Социаль челтәрләрдәге үз битеңне бик тыйнак алып барасың. Язылучыларыңа «Тормышыңны бөтен нечкәлекләре белән түкми-чәчми халыкка җиткерү урыныммы инстаграм?» дип сорау биргәнсең. Ә үзең ничек җавап бирер идең?

– Социаль челтәрләрдә дөньяны сугышсыз гына яулап алып була. Тик анда затлылык икенче планга күчкән. Әйткәнемчә, кара пиар куллану минем өчен түгел. Иң элек кеше ни әйтер дип уйлыйсың. Мин, гомумән, чак кына соңрак туган. Иртәрәк яшисе кеше булганмындыр. Хәзерге җәмгыятьтәге кыйммәтләрне аңлап бетерә дә алмыйм кебек. Шуңа күрә социаль челтәрләрдә бары иҗатым гына минем... Кызганыч, сәхнә белән социаль челтәрләр буталып бетте. Акча культы, интернет халык зәвыгын бетерде. Мондый темплар белән барсак, кешелеклелек, яхшылык, игелеклелек дигән сыйфатлар онытылырга мөмкин.

Сәхнәдәге зыялы Ришат белән тормыштагы Ришат аерыламы?

– Озын бормалы җырлар башкаргач, тамашачыларым мине бик җитди кеше дип кабул итә, ахрысы. Тик тормышта алай ук җитди түгелмен. *(Көлә.)* Шаярулар, уен-көлке, юмор яратам. Кечкенә чакта бик очынчык бала идем. Бу сыйфатым өчен яратып кына шелтәләп тә алалар иде. Тәрбияне үзгәртеп булмый. Әти-әниләр мине менә шулай тыйнак булырга өйрәткәннәр инде.

Шулай да шәхси тормышыңа кагылышлы сорау бирми кала алмыйм. Әниең генә түгел, без – тамашчыларың да көтәбез бит инде, Ришат. Гаилә кору мәсьәләсен әйтәм...

– *(Тыйнак кына елмаеп.)* Эшне, иҗатны аякка бастыргач кына өйләнермен дигән максат куйган идем. Бар да җайланды кебек. Хәзер үзем дә өлгердем.

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА. Видео: Фәнис САДЫЙКОВ.

Фото: Анна АРАХАМИЯ

QR-кодны ничек кулланырга:
1. Смартфоныгызга kiozk приложениесен урнаштырыгыз.
2. QR-сканерны ачыгыз.
3. Смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.





Фото: Анна Арахамия

ЧӘЧӘКЛӘР БӘЙЛӘМЕ – ГҮЗӘЛЛЕК ГАЛӘМЕ

Кечкенә генә нәфис бер чәчәк сокландырырлык матурлыкка, теләсә кемне тынычландырырлык, күңелен күтәрерлек кодрәткә ия. Гүзәллеге күзләрне иркәли, ә хуш исе борынны кытыклап күзне йомдыра да, булган борчулардан аерып, бәхет касәсе мөлдерәмә тулган бер мизгелгә алып китә. Кәефне күтәрә. Матур хатирәләргә – сукмак, якты хис-кичерешләр чыганагы ул чәчәкләр. Казан шәһәре уртасында урнашкан «Флореаль» чәчәк модасы үзәгенә кергәч, ирексездән, әнә шундый уйлар килде. Ә нигәдер моңа кадәр уйланмаган ул хакта. Таш шәһәр уртасында искиткеч бер оазис булып утыра ул. Ишеген ачасың да башка бер галәмгә күчәсең. Гүзәллек дөньясына...

«Яшәр өчен кояш, ирек һәм кечкенә генә чәчәк кирәк», – дигән әкиятче Ганс Христиан Андерсен. Чәчәкләр кеше гомеренең аерылгысыз бер юлдашы. Тормыштагы бер генә күңелле вакыйга да гөлләмәләрсез узмый. Димәк, алар – бәхет уртаклашучылар. Чәчәк базары хәзер бик зур. Ә менә өзелгән чәчәкләргә кабат җан өреп сата белүчеләр сирәк. «Флореаль» үзәге – әнә шул сирәкләрнең берсе. Монда җан бар! Ишеген ачып керүгә үк сизелә ул. Хәтта чәчәкләрнең исе дә башка. Хуш исе сине бөтереп ала да иркәләп назга төрә сыман. Моңа ягымлы флорист кызларның елмаюлары да кушыладыр, мөгаен. Юкка гына салон хуҗабикәсенең исеме дә Флора түгелдер. «Корабльгә нинди исем бирәсең, шулай йөзә, диләр бит. Күрәсең, чәчәкләр – минем язмышым», – ди Флора Галиева эчкерсез елмаеп. Ачык күңелле хуҗабикәнең салонында башкача атмосфера булырга мөмкин дә түгелдер. «Үзебезне гаилә дип йөртәбез. Бер-беребезгә булган җылы мөнәсәбәт клиентларга да күчә: шундук дусларыбызга әйләнәләр», – ди Флора ханым. Казанда беренчеләрдән булып чәчәк салоны ачып, менә инде 30 ел эшенә, клиентларына тугры калган кеше ул. Һәр клиентка ярарга, аны таң калдырырга тырышалар бирелә. Көйсезрәкләрне аеруча яраталар, чөнки аларның

гөлләмәгә таләпләре тагын да зуррак. Ә бу исә үсү, тәҗрибә арттыру дигән сүз. Башка бик күп чәчәк кибетләреннән аермалы буларак, монда профессионал флористлар эшли. Даими рәвештә белемнәрен күтәрәләр, төрле мастер-классларга йөриләр. Клиентларны хәйран калдыру өчен заманадан бер адым алдарак атлап барырга кирәклеген белә тәҗрибәле хуҗабикә: чәчәк бәйләме алырга килгән кеше кабат «Флореаль» ишеген ачып керерлек булсын!

Чәчәкләр – эмоция чыганагы. Хәзерге коточкыч югары тизлектә яшәлгән, җитмәсә, катлаулы вазгыятьләр килеп туган чорда безгә позитив, уңай хис-кичерешләр җитми. Ә кайчак якын кешең матур сүзләр әйтеп биргән кечкенә бер гөлләмә дә таулар күчерердәй көч бирә. Дөнья бик тиз төрле төсләргә буялып, баш очыбызда салават күпере чыга. Йөзгә кунган елмаюны күреп, бүләк итүченең дә күңеле шатлык белән тула. Якыныңны сөендерә алу үзе бәхет түгелме соң?! Ә син елмаясың икән, дөнья да сиңа елмаймый калмый. «Паровозик из Ромашково» дигән мультфильм бик ошый, – ди Флора ханым. – Анда: «Соңга калабыз, ашыгыйк», – дип каударланган пассажирга паровоз: «Әгәр дә без хәзер туктап ландышларны карамыйбыз икән, язга соңга калабыз», – ди. Бу җөмләгә тирән мәгънә салынган: матурлыкны бүген күрергә һәм бүген сөенә белергә кирәк». Хис-кичерешләр акчадан кадерлерәк, истә калып, гомер буе күңелне җылыталар.

Матурлык җыелган салонда нинди генә чәчәкләр юк. Патшабикә розалар, купшы чалмалар, нәфис язгы чәчәкләр, альстромерия, затлы гортензияләр, хәтта кыр чәчәкләре дә. «Ромашкалар, зәңгәр кыңгыраулар, сары башаклардан ясалган гөлләмәдән күзне алып булмый. Алар гадилекләре белән матур», – ди флористлар. Менә инде дистә елга якын ел саен бер үк көнне хатынына әнә шундый гөлләмә бүләк итүче клиентлары бар икән. Алар, күрәсең, кыр чәчәкләрендә яшьлек хисләрен саклый. «Чәчәкләргә дә мода бар», – диләр салонда эшләүче кызлар. Мәсәлән, хәзер бик зур гөлләмәләр популяр икән. Аларны гигантлар дип йөртәләр. Шулай ук кечкенә, купшы булмаган йә креатив гөлләмәләргә дә ихтыяҗ зур. Инде берничә ел чалма чәчәкләрне үз итә казанлылар. Хәзер төрле композицияләр ясау да модада. Кәрзин, матур тартмаларга зәвык белән җыелган чәчәкләргә ваза да кирәк түгел. Җиләк-җимешләр белән аралаштырып, махсус савытка утыртылган чәчәкләр, чыннан да, күз явын алырлык.


Чәчәкләр – кешеләр арасындагы гаҗәеп арадашчылар. Алардан җылылык бөркелә. Гүя, син минем өчен бик кадерле, диләр. Шуңа да бер-береңә чәчәк бирү араларны тагын да якынайта. Ә иң мөһиме: кәефне күтәрә. Еш кына хатын-кызлар үз кәефләрен күтәрү өчен гөлләмә алалар икән. Соңгы вакытларда андыйлар аеруча күбәйгән. Композиция алып, бер сәбәпсез сөйгәннәрен куандыручы ир-атлар да җитәрлек, диләр.

Әллә чәчәк модасы дигән исеме, әллә тышкы яктан бик зәвыклы бизәлеше, әллә үзәктә урнашуы сатып алучыларны куркыта, бик еш кына: «Сездә бәяләр артык югары түгел икән, ә мин кыйммәттер дип уйлаган идем», – диләр. Төрле бәядәге гөлләмәләр җыялар монда. Кайберәүләр, 300 сумга композиция ясагызчы, дип шалтырата икән. Клиентлары арасында республика VIPлары да булган салон мондый заказларга да борын чөерми. Дөрес, ул суммага бик авыр чәчәк җыюы, тик тырышалар. «Безнең өчен һәр клиент кадерле. Бәлки, ул кеше, соңгы акчасына чәчәк сатып алып, тормышына могҗиза килүен көтәдер? Могҗиза булмаса да, яхшы эмоцияләр бүләк итәрлек мөмкинлегебез бар безнең. Ник әле сөендермәскә?!» – ди Флора ханым. Бүгенге җәмгыятьтә еш очраган йөз чөерү, масаю, шапырынулардан азат ул. Аның өчен кешеләр белән җылы мөгамәләдә булу мөһим. Һәр клиентының шатлыгы өчен чын күңелдән сөенә. Ул җыйган чәчәкләрне тотып, беренче тапкыр сөйгәне белән очрашуга барган, аннары кәләшенә дип атап гөлләмә ясаткан, хатынын бала тудыру йортыннан «Флореаль» флористлары җылысы иңгән чәчәкләр белән каршылаган, хәзер инде яраткан хатынына һәм сөекле кызларына шушы ук салоннан гүзәллек бүләк иткән клиентлары байтак. Алары аеруча якын. Чәчәк кадерен белгән, матурлык яраткан кешенең күңелендә начарлык булмый, ул кеше кадерен дә белә.




РЕКЛАМА

ТАССР 1920-2020



1.



2.

1. Индус Таһиров.
2. Римзил Вәлиев.
3. Түгәрәк өстәл янында сөйләшүдә катнашучылар. Алгы планда — Р. Туфитуллова.
4. Рәшит Ягъфәров.
5. Флүн Мусин.
6. Конгресс барган көннәрдә. Июнь 1992 нче ел.

Түгәрәк өстәл янында сөйләшү

ТАТАРНЫҢ ЙӨЗЕК

Кем нәрсә генә әйтмәсен, нинди генә бәя чыгармасын, 1992 елның июнь ае татар милли хәрәкәте тарихында хак урынын алачак. Аны инкарь итәрлек көч юк. Чөнки июнь аен татар дигән зур, әмма кагылган, сугылган, күп җәфалар чиккән халыкның берләшү ае дип санарга мөмкин. Тарихта беренче мәртәбә бөтен дөньяга сибелгән татарларның корылтае, конгрессы булды. Дөрес, элек тә андый омтылышлар булгандыр, ләкин әлеге җыенның гаять әһәмиятле бер үзенчәлеге бар: ул дәүләт дәрәҗәсендә суверен Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә чакырылды. Бер яктан, Конгресс җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлеген яклау, аны халыкара аренага чыгаруны күздә тотса, икенче яктан, дөнья каршында татар милләтенең абруен күтәрү дә иде ул. Һәрхәлдә, күпләр аны шулай кабул итте. Конгресс оешуга бер ел вакыт үтеп китте. Әлеге олы максатлар аның эшчәнлегендә нинди урын алды, аңа шушындый бәя биреп ялгышмыйбызмы, өметләребез буш хыял гына булып калмадымы? Менә шушы мәсьәләләр турында сөйләшү өчен без редакциягә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының җитәкчеләрен чакырып әңгәмә кордык. Әңгәмәдә катнаштылар: Индус ТАҺИРОВ — Башкарма комитетының рәисе; Роза ТУФИТУЛЛОВА — рәис урынбасары; Римзил ВӘЛИЕВ — рәис урынбасары; Флүн МУСИН — рәис урынбасары; Рәшит ЯГЪФӘРОВ — Башкарма комитет әгъзасы.

Конгресс үзен акладымы?



ңгәмәдә катнашучыларга беренче һәм принципиаль соравыбыз шушы иде. Аңлашылганча, сүзне Башкарма комитет рәисе ялгап китте.

Индус ТАҺИРОВ. Гади генә әйткәндә, Конгрессның төп максаты татар милләтен барлау, туплау. Моңа кадәр бу эш белән шөгыльләнүче булмады. Дөрес, матбугатта татарлар җиде миллион тәшкил итә дигән мәгълүмат йөри йөрүен, әмма мин моны чын дөреслеккә туры килә дип уйламыйм. Инде халык санын алганнан соң да шактый вакыт узды. Аннан соң, миңа калса, хикмәт рәсмилектә генә түгел, хикмәт рухи бөтенлектә.

Хәбәрче. Бу үзмаксат түгелдер, билгеле, аның нинди дә мәгънәсе дә бардыр.

И. Т. Әлбәттә. Шушы нигездә без татар милләтен халыкара аренага чыгарырга телибез. Татар белән санлашырга тиешләр.

Хәбәрче. Бу эш ничек оештырыла инде?

И. Т. Менә хәзер без элекке СССР территориясендәге татарларны барлауны тәгәлләп киләбез. Сез әйткәнчә, сан белән бергә, безне татарларның яшәү рәвеше, тормыш-көнкүреш дәрәҗәсе кызыксындыра. Нинди проблемалары бар? Иң мөһиме, шул проблемаларны хәл итү механизмын эшләү.



В. МАРТИНКОВ фотосурәтләре.



3.



4.



5.

КАШЫ!?

Әйтергә кирәк, әлеге өлкәдә дә конкрет нәтиҗәләребез бар. Шуларның да аеруча күз уңында торганы — татарлар яши торган төбәкләрдә милли административ районнар булдыру. Март аенда, мәсәлән, Пермь өлкәсенең Барда районында шушы әһәмиятле мәсьәләгә багышлап конференция үткәрдек. Моны Конгресс тоткан концепциянең реаль тормышта сыналуы дип тә карарга мөмкин.



6.

Хәбәрче. Милли районнар оештырырлык төбәкләр күп, хәзер игътибарыгыз кай якларга төбәлгән?

И. Т. Әлеге мөмкинлекләр Чиләбе өлкәсендә тикшерелде, Екатеринбургта. Аларда да милли-мәдәни мөхтәриятне булдыру мөмкинлекләре ачыкланды.

Хәбәрче. Безнең әле Себеребез бар, Ерак Көнчыгыш, Камчатка. Анда татарның иң зыялы токымнары яши дип уйлыйм мин үзем. Чөнки сөргенгә сөрелгәннәрнең күбесе укымышлы нәселдән. Элек-электән шул якта яшәгәннәре дә ким-хур түгел. Мин моны шуның өчен әйтәм, «Сөембикә» журналын әлеге төбәкләрдә теләп алдыралар, яратып укыйлар. Краснодар краенда, мәсәлән, 1286 данә, Хабаров краенда — 1070, Омск өлкәсендә 2536, Чита, Магадан, Приморье, Амур, Новосибирск өлкәләрендә дә шактый. Ләкин бер аяныч хәл, шул якларга безнең кулыбыз житми. Аларның да күңелен күрәсе иде бит. Сез бу тәкъдимгә ничек карыйсыз?

И. Т. Мин тулысы белән яклыйм бу тәкъдимне. Бу безнең теләгебез генә түгел, бурычыбыз да, аны кичекмәстән эшләргә кирәк. Чөнки моның житди сәбәпләре бар. Мәсәлән, Россиянең милли мәсьәләләр буенча дәүләт комитетында, кайбер ялган милли сәясәтчеләр сүзенә таянып, Себер татарларына аерым халык сыйфатында билгеләмә бирелә. Милләтебезне эчтән таркату омтылышы яшәп килә.

Шушы ялган агымга кушылып китүчеләре дә булырга бик мөмкин иң. Чөнки, әйткәнегезчә, без алар белән аралашмыйбыз, хәл-әхвәлләрен белешмибез, читтә яшәп читләшүең дә ихтимал.

Хәбәрче. Рәхмәт, җавапларыгыздан канәгатьмен. Һәм әңгәмәбез үзеннән-үзе Конгрессның эчке проблемаларына, дөресрәге, ул башкарачак эшләрнең асылына кереп китте. Бу бик табигый. Ник дисәң, ул әле эзләнү, үзен таныту чорын кичерә. Шушы җәһәттән, мине Конгрессның статусы мәсьәләсе борчый. Абруе бармы аның, аңа таянып сүз сөйләп буламы?

Вәкаләтең нинди?

И. Т. Башкарма комитет теркәлде. Конгресс үзе дә акрынлап халыкара аренага чыгарга тиеш. Моңа чама белән ике еллап вакыт кирәк булачак. Чит илләрдә без үз филиалларыбызны булдырырга тиеш. Документлары инде өлгереп килә. Шушы елның июнь аенда Венада Берләшкән Милләтләр Оешмасы кеше хокукларын яклау буенча конференция үткәрә. Әлеге документларны шунда алып барып, тиешле докладларны яклаганнан соң, гамәли чаралар күрү зарур. Шул ук июнь аенда Башкарма комитетның киңәйтелгән утырышы планлаштырыла. Без аңа әлеге халыкара конференциядән рәсми вәкил чакырырга уйлыйбыз. Ул күрер, карар, белешмәләр әзерләр. Шул нигездә халыкара регистрациягә юл ачылыр, дип өметләник.

Римзил ВӘЛИЕВ. Бу бик урынлы күтәрелгән мәсьәлә. Марат әфәнде, сезнең соравыгызның нигезендә тагын бер үзенчәлекле мәгънә ятадыр, дип уйлыйм. Әйтик, кайберәүләр, Конгресс Указ белән генә булдырылган оешма, шуңа күрә, янәсе, хокук ягыннан татар халкы өчен легитим түгел диләр. Беренчедән, татар халкы исеменнән рәсми рәвештә нидер әйтердәй легитим оешма юк әле. Әлбәттә, Конгресстан башка. Дөрес, җәмәгать оешмалары бар, хәтта күп тә алар. Конгресс исә җәмәгать оешмаларының берсенә дә ошамаган. Ул партия дә, иҗтимагый хәрәкәт тә түгел, бәлки арадашчылык итүче оешма, аны икенче төрле татарның ЮНЕСКОсы дип әйтергә мөмкин булыр иде. Әйтик, Татар иҗтимагый үзәге бар, милли мәҗлес, ләкин аларның берсе дә татарны барлау, милли округлар, курияләр оештыру белән шөгыльләнми. Конгрессның легитимлыгы турында сүз кузгатабыз икән, билгеле булганча, анда бөтен теләгән кеше дә катнаша алмады. Әмма сез аның географиясенә генә игътибар итегез, татар яшәгән һәр төбәктән конгресста катнашучы булды. Сүз дә юк, алар милләттәшләребезнең мәнфәгатьләрен кайгыртучылар. Аннан китереп, Конгресска җибәрелгән әлеге делегатларга урыннардагы хакимиятләр дә үз фатихаларын биргәннәр иң.

Хәбәрче. Оппонентларның дәлилләре моның белән генә чикләнмидер бит?

Р. В. Юк, әлбәттә. Мисал өчен, Конгресста күбрәк урындагы, ягъни рәсми кешеләр, манкортлар катнашты дигән гаеп тә ташладылар. Ә бу тамырыннан иске караш, мәсьәләгә сыйнфый күзлектән килергә тырышу. Менә шушы куркыныч баш өстебездә кылыч рәвешендә асылы-

нып тормасын өчен Конгресс уставына милли идеянең сыйнфый һәм башка хорафатлардан өстенлеген тану билгеләмәсе кертелде дә инде.

Янә бер әһәмиятле мәсьәлә. Татарлар яши торган республика һәм өлкәләрнең законнарын тану. Әгәр Конгресс шушы принципны боза икән, ул яши алмый. Татарстанныкын да, башкаларныкын да. Безгә Россия законнары да зарур. Гомумән, җир шарындагы һәр мәмләкәтнең рәсми кануннарын Конгресс ихтирам итәргә, үтәргә бурычлы. Шунсыз халыкара оешма югарылыгына күтәрелмәячәк. Уйлап карагыз, татар милләте бүгенге көндә 30 ил Конституциясе нигезендә яши.

Конгресс иҗтимагый хәрәкәтләр шурасына таяна, диаспора үзәгенә таяна, экспертлар советына таяна, географиясе киң. Конгресска конкуренция юк.

Хәбәрче. Уставта әлеге положениеләр урын алгандыр, дип исәплəргә кирәк.

Р. В. Әйе, менә мин аны сезгә бүләк тә итәм. Ул былтыр 24 ноябрьдә расланган. Билгеле, аңа әле үзгәрешләр керәчәк. Әлеге уставны таныган оешмаларга аның составына юл ачык. Әйтик, Чиләбе, Башкортостандагы берничә милли оешма берләшә дә, үзе региональ үзәк рәвешендә теркәлеп, Конгресска керә.

Хәбәрче. Озын сүзнең кыскасы...

Р. В. Озын сүзнең кыскасы, Конгресснең статусы шул, ул халыкара гуманитар арадашчы оешма.

Сүзме, гамәлме?

Хәбәрче. Гамәлгә керешкәнче янә сүзгә мөрәҗәгать итик әле. Сүз бик көчле корал ул. Халык бер дә юкка гына «Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел», димәгәндер, мөгаен. Кайбер кешеләр арасында, мәсәлән, Конгресс татар милли хәрәкәтен йотарга тырыша икән, аерым алганда, Татар иҗтимагый үзәгенә яный икән дигән гайбәтләр йөри.

И. Т. Ләкин бу тулысы белән уйдырма. Без бер генә иҗтимагый хәрәкәтне алыштырырга да, таптарга да җыенмыйбыз. Башкарма комитетның эшчәнлегенә килгәндә исә, тагын бер кат ассызыклап әйтәсем килә, төп мәслəгебез татар халкын, аның иҗтимагый һәм мәдәни-агарту оешмаларын берләштерүдән, Татарстан Республикасының социаль-икътисади, сәяси һәм рухи үсешенә булышудан, дәүләт суверенитетын ныгытудан, татар халкы күпләп яши торган төбәкләрдә милли-мәдәни мөхтәрият булдыру программасын тормышка ашыру механизмын эшләүдән гыйбарәт.

Хәбәрче. Монысын да ачыкладык. Хәзер минем әңгәмәне гамәл ягынарак авыштырасым килә.

И. Т. «Ак калфак» берләшмәсе президенты Роза ханым бу хакта киңрәк сөйләр дип уйлыйм.

Роза ТУФИТУЛЛОВА. Авыз тутырып зур эшләр турында сөйләргә иртәрәк әле, әлбәттә. Әлегә Бөтентатар хатын кызлар берләшмәсе «Ак калфак» оешу, аякка басу дәверен кичерә. «Ак калфак»ның инде Хельсинкида, Пермь өлкәсендә, Уфада, Чаллыда һ. б. кайбер төбәкләрдә бүлекчәләре ачылды. Ул эш дәвам итә. Журнал укучылар белә инде, без Казан шәһәрендә татар балалар бакчасы, кызлар гимназиясе, төрки халыклар өчен бала тудыру йорты ачу мәшәкате белән мәшгульбез. Шушы мәнфәгатьтә мая туплыйбыз. Хельсинки бүлекчәсе «Азатлык» радиосы журналисты Фәридә Хәмит аша, безнең акчага күчереп исәпләгәндә, 1 миллион сумлык доич-марка җибәрде. Бу эшләребез, аңлашылганча, Конгресс рамкаларында алып барыла.

Р. В. Бу сорауга минем дә өстисе мәгълүматым бар. Күпләргә билгеле, Мәскәү галиме Вил Мирзаянов Мәскәүне генә түгел, бөтен дөньяны шаулатты. Ул АКШ журналистына Россиянең хәрби максатларда куркыныч химик газ эшләп чыгаруын дәвам иттерүе турында сөйләгән иде. Аны кулга алдылар. Шул ук көнне Индус Ризаковичның бер танышы Мәскәүдән аңа шалтырата. Индус Ризакович кафедра җыелышын өзеп, телефон аша минем белән элемтәгә керде, хәлне бәян итте. Бер сәгать эчендә без Ельцинга телеграмма җибәрдек, «Азатлык» радиосына мөрәҗәгать белән чыктык, Вил әфәнденең хатыны белән сөйләштек. Америка галимнәренең саллы сүзе таләп ителә диделәр. Икенче көнне бу үтенечне «Азатлык» радиосына җиткердем. Өченче көнне ул хәбәр академик Роальд Сәгъдиевка җитте, аннан русча интервью алдылар һәм эфирга бирделәр. Шунда ук Америка галимнәре федерациясенең рәсми хаты Ельцинга җибәрелде.

Вил Мирзаяновны төрмәдән чыгарырга мәҗбүр булдылар.

Хәбәрче. Кыска дулкынлы радио мәсьәләсе дә хәл ителә икән дип ишеттем. Бу имеш-мимеш кенәме, әллә чынбарлыкка туры киләме. Югыйсә, читтә яшәүче милләттәшләребезнең күптәнге хыялы иде ич бу. «Сөембикә»гә дә йөзләгән хатлар килде бу хакта.

И. Т. Ул хәл ителде инде. Быел ук ерактагы милләттәшләребез Казан тавышын ишетә алыр дип ышанабыз. Оештыручылары — Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, Татарстан дәүләт телерадио кампаниясе.

Тарих безне яклыймы?

Хәбәрче. Кылган гамәлеңнең хаклыгын тәгаенләү өчен үткәнеңә борылып кара, ди халык. Әйтик, Октябрь революциясеннән соң татар әһелләре, аерым алганда Галимҗан Ибраһимов һ. б. культура автономиясе мәсьәләсен күтәреп чыктылар. Бу идеяләр хәзерге шартларга яраша аламы? Бу сорауга җавапны мин сездән ишетергә теләр идем, Рәшит әфәнде.

Рәшит ЯГЪФӘРОВ. Культура автономиясе дигән нәрсәне ике төрле аңларга кирәк: культура автономиясе һәм җирле автономия. Боларны аерып карарга ярамый, безнең халык өчен аның икесе дә кирәк. Культура автономиясе — башка халыклар бергә укмашып яшәгән җирләрдә бер милләтнең яшәү механизмын табу дигән сүз.

Ләкин бу юл белән генә китәргә ярамый. Чөнки тарихи ватан дигән төшенчә дә бар бит әле. Бу халыкның үз җире, анда аның ата-бабалары яшәгән, гореф-гадәтләре, йолалары формалашкан. Әйтик, Пермь, Әстерхан, Себер. Әлеге төбәкләрдә исә җирле автономия булдыру зарур. Инде әйтелеп кителгәнчә, ул эш алып барыла. Иң мөһиме, шул төбәкләрдә яшәгән халыкның хокукый нигезләрен тәэмин итү. Шул нигезләргә таянып, ул милли административ берәмлек буларак яшәп китә ала.

Тик моны һич тә Татарстан белән бәйләнешне өзү дип аңларга ярамый. Татарстанның дәүләт системасында андый төбәкләр белән эшләү структурасы да булырга тиеш, дип саныйм. Күрәсез, идеяләр тулылана, байый гына бара.

Хәбәрче. Туксанынчы еллар татар милли хәрәкәтенең чишмә башы, Флүн әфәнде, миңа калса, «Мирас» комиссиясенә барып тоташа, шулаймы?

Флүн МУСИН. Әйе, милли уяну чоры башлануга, без шундый комиссия оештырып җибәргән идек. Аңа Гаяз Исхакый мәсьәләсе төп этәргеч булган иде. Күрәш, беләсездер, беренче көннәрдән үк кискен төс алды. Ул вакытта хөкүмәтебез андый эшләргә алыныр дәрәҗәдә түгел иде. Шуңа күрә әлеге кайгыртулар безнең җилкәгә төште. Күреп торасыз, хәзер хәл тамырдан үзгәрде. Г. Исхакый уңаеннан инде хөкүмәтнең карары да чыгарылды. Кайчандыр «Мирас» кабызган очкын инде ялкынга әверелеп бара. Без моңа бик шат.

НӘТИҖӘ. Күпләр, мөгаен, бу әңгәмәнең исеменә игътибар иткәннәрдер. Әйе, чыннан да, бәхәсле. Шуңа күрә тыныш билгеләре дә аерым мәгънә салып куелды. Әмма татар халкының рухи йөзек кашы дәрәҗәсендәге оешмасы булырга тиеш. Монысы бәхәссез. Һәм хәзергә бу исемгә Бөтендөнья татар конгрессы гына дәгъва итә ала. Акласын иде ул шушы олы исемне!

Әңгәмәне Марат ӘМИРХАНОВ алып барды һәм язып алды.

ИГЪТИБАР, ИГЪТИБАР! КИЛЕННӘР КОЛАГЫНА!

Уңган-булган, чибәр, зирәк, җор, сабыр вә һөнәрле киленнәребез! «Ак калфак» Бөтентатар хатын-кызлар ассоциациясе, «Сөембикә» журналы халкыбызның борын-борыннан килгән гаилә кануннарын, күркәм йолаларын, әхлак, тәрбия мәсьәләләрен, яшьләребезгә гыйбрәт итүне күз уңында тотып, «Киленбикә» бәйге-тамашасы үткәрергә ниятли.

Шартыбыз түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) Яшь килен — 18—25 яшькә кадәр. 2) Уртанчы килен — 26—45 яшькә кадәр. 3) Олы килен — 46 яшьтән...

Халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын, динен, телен, һөнәрләрен белгән, кайнаналарына кадер-хөрмәт саклаган, бәйгедә катнашырга теләк белдергән асыл хатын-кызларыбызның фотосурәтләре белән хатларын көтәбез.

АВЫРЛЫКЛАР АЛЛАҺЫГА ЯКЫНАЙТА



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Безгә килгән авырлыкларның сәбәбе нидә?

– Авырлык дип нәрсәне атарга була соң? Бу төшенчә кешенең субъектив фикере генә. Гадәттә, тормышыбызга җайсызлык, борчу-хәсрәт кертә торган хәлләрне авырлык, дибез. Ә Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә: «Без сезне, һичшиксез, курку, ачлык, фәкыйрьлек, үлем һәм уңышсызлык белән сынарбыз», – ди. Димәк, авырлык дип шушы биш әйберне генә әйтеп була. Безгә бүген, Аллага шөкер, аларның әле берсе дә килмәде дип әйтергә була. Күпчелек кешегә килмәде... Шуңа күрә «авырлык» дип әйткән сүзебез күп вакыт бер урынсыз зарлану гына. Температура белән ике көн ятса да, «үлемнән калдым», ди кеше. «Гаилә тормышым бәхетсез», ди ул, баксаң, ире 8 Мартка чәчәк бүләк итмәгән икән... Шуңа күрә безгә бүгенге көнгә башка күз белән карарга, хәлебезне алда санап киткән авырлыклар белән чагыштырырга кирәк. Пәйгамбәребезнең: «Кыенлык килгәндә, үзегездән дә авыррак яшәгән кешеләрне искә төшерегез», – дигән сүзе дә бар.

Инде сәбәпләргә күчик. Беренче сәбәп, әлбәттә, газап. Авырлык килсә, иң беренче итеп: «Мин нәрсә эшләдем, хатам нидә?» – дип уйларга тиешбез. Күпләр: «Бу газапка лаек булырлык гөнаһым да юк», – дип уйлый. Бу – тәкәбберләр фикере. Кеше фәрештә түгел, һәркайсыбызның гөнаһысы бар. Һәм һәр кешенең үз гөнаһысына күрә газабы, сынавы да бар. Мәсәлән, урамда хатын-кызга һөҗүм иткәннәр, әйберен талап киткәннәр ди. Бар да: «Ничек хатын-кызга кул күтәрә алганнар, нинди начар кешеләр!» – дип аптырый. Хатын-кыз үзе дә: «Ни гаебем өчен инде бу миңа?!» – ди. Бер караганда, аның, чыннан да, бер гаебе дә юк. Ә хәзер икенче яктан карыйк. Ул өеннән чыгып киткәндә иреннән рөхсәт алганмы? Яулык бәйләгәнме? (Бәйләмәгән икән, димәк, аның янында рәхмәт фәрештәләре йөрми – алар яулыксыз хатын-кыздан ояла). Юлга кузгалганда «Аятел көрси»не укыганмы? Дога кылганмы? Хәтта сиңа һөҗүм итсәләр, зыян күрсәң дә, гаепне иң элек үзеңнән эзләргә тиешсең.

Авырлык шулай ук сынау буларак килергә дә мөмкин. Эзләп-эзләп үз хаталарыңны тапмыйсың икән, сынау өчен килгән дип уйлыйсың. «Нишләп инде Аллаһы Тәгалә тик торганда мине сыный соң?» – дип уйлап куярга мөмкинсең. Пәйгамбәребез: «Аллаһы Тәгалә кемнедер үзенә якынайтасы килсә (ә бу кеше аңа якынаер өчен бернәрсә дә эшләми), ул аңа сынау бирә», – ди. Шул сынауны җиңеп чыкса, бу кеше Аллаһы Тәгаләгә якыная, ягъни аның каршында дәрәҗәсе күтәрелә.

Гадәттә без: «Бу миңа нәрсәгә бирелде инде, нигә миңа гына, кешегә юк», – дия башлыйбыз. Бөтен фаҗигабез дә шушында. Болай уйлап кына хәлебез үзгәрми. Хәлебезне үзгәртер өчен беренче чиратта килгән авырлыкка карата мөнәсәбәтебезне үзгәртергә кирәк. Дөресен генә әйткәндә, аның сәбәбен белү бик мөһим дә түгел. Бу очракта сынауны, авырлыкны ничек җиңеп чыгасың – шунысы күпкә мөһимрәк. Сынау нинди генә газап буларак килсә дә, сәбәбе ахыргача безгә билгеле булмаска мөмкин. Сәбәбен үзең белмисең икән, белемле, озак гомер кичкән, үзләре авырлык күргән хикмәтле кешеләр бар – алар белән киңәшләш. Үзеңнең моң-зарыңны «болай булды, тегеләй булды», дип, теләсә кемгә түгеп, елап йөрергә кирәкми: чит кешенең зарланганын тыңлап торырга берәү дә яратмый. Авырлыкны ничек җиңәргә, аны башка булдырмас өчен нишләргә – әңгәмәдәшең шушы сорауларны чишәргә ярдәм итә алса гына аңа күңелеңне бушатырга мөмкин.

Авырлык тизрәк узсын өчен нишләргә кирәк?

– Әйткәнебезчә, башта: «Бу авырлык нинди хаталарым өчен килде икән?» – дип уйларга кирәк. Шул хаталарны төзәтү бу авырлыкны җиңәргә ярдәм итәчәк. Ә инде сәбәбен ачык белмәсәң, авырлыкны ничек җиңәргә кирәк? Моның өчен беренче чиратта сабырлык кирәк. Сабырлык – түземлек дигән сүз түгел. Сабыр итү – кабул итү, шушы халәтеңә риза булу дигән сүз, ул – күңел халәте. Икенчедән, сабыр иткәннән соң бу мәсьәләне чишү өстендә эшлисең. Үзең генә җиңеп чыга алмыйсың икән, ярдәм сорыйсың. Сиңа килгән авырлык ул әле күршеңә дә сынау булырга мөмкин. Мәсәлән, син авырлыкка тарыйсың, көрәшәсең, ә ул берничек булышмый, карап кына тора: бу инде хәзер аңа килгән сынау, аңа килгән авырлык. Ярдәм итәрме ул күршесенә, юкмы? Әмма иң элек, әлбәттә, Аллаһыдан сорарга кирәк: һәр авырлык сине аңа якынайтыр өчен килә. Бер көтси хәдис бар: Аллаһы Тәгалә баласы үлгән кешеләр янына фәрештәләрне җибәрер ди. «Мин бит аның йөрәк җимешен алдым, ул анда нишли?» – дип сорар. Фәрештәләр: «Ул сиңа шөкер кылып утыра», – диярләр. «Минем аңа җәннәттән башка бернәрсәм дә юк», – ди Аллаһы Тәгалә.

Кичергән авырлыклар бөтен кешене дә көчлерәк итәме?

– Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: «Мин сезгә күтәрә алмаслык авырлык бирмим», – ди. Димәк, кешегә сынау килгән икән, ул аны күтәрә ала һәм һәрбер авырлык аны көчлерәк итә. Шуңа күрә беркайчан да авырлык кешене сындырыр өчен бирелгән дип уйларга кирәкми. Әгәр син ул авырлыкны кабул итә алмасаң, бирешсәң, әлбәттә, сынасың. Монда инде Аллаһының гаебе юк, гаеп синең көчсезлегеңдә. Авырлык шулай ук, әйткәнемчә, Аллаһы Тәгаләнең якын бәндәсенә бирелә, чөнки җаваплы, авыр эшне якыннарыңа гына кушып була. Берәү бер авырлык та кичерми яши икән, димәк, Аллаһы Тәгалә аны зәгыйфь дип уйлый. Авырлык бирсәм, түзә алмас, ди.



Фото: Анна Арахамия

«Читек чигәр өчен материал да җитәрлек, эшен дә өйрәнеп була, осталык та килә, ихтыяҗ да бар, әмма күп очракта кешеләрдә иң мөһиме юк. Ә бу эштә иң мөһиме – түземлек. Бик сабыр кешеләр генә башкара ала аны». Оста яңа тегелеп беткән читекне ала да биш-алты метр читкә барып баса. «Ерактан сезгә аның бизәкләре генә күренә, шулаймы?» Килешеп, баш кагам. Фирүзә җирлектә ак һәм яшькелт бизәкләр. Оста бер-ике адым якынлаша. «Хәзер сез җөйләрне дә күрәсез». Ул хаклы. Ак һәм яшел чәчәкләр арасыннан төсле җөй уза лабаса! Инде читекне алдыма ук китереп сала. Менә хәзер җөйдәге һәр атлам күз алдында. Һәр атламда өчәр төен…



Лилия
ГӘРӘЕВА

«КАЗАН ҖӨЕ» – БРЕНД УЛ!

Читекченең төп сыйфаты – түземлек.
Бик сабырларның гына бу эшкә түземе җитә.

Балачагымнан бер матур хатирә җанлана: мәктәптән кайтышлый әнинең эшенә керәм. Стеналарда төргәге белән мулине җепләре эленгән. Озын өстәлләрдә – күн кисәкләре... Чигүче апалар станокларына иелгәннәр дә, энәне тиз-тиз уйнатып, читек чигәләр. Арча милли аяк киемнәре фабрикасы ул елларда гөрләп торды. Чүәкләр, читекләр, кәвешләр тегәләр иде. Ә әниләр шуларның бизәкләрен чикте. Аннан соң инде күпме сулар акты, чигүче апаларның да кайсы картайды, кайсы мәңгелеккә күчте... Әнидән «Казан җөе»н өйрәнеп калмавыма көенә идем, язмыш мине бу эшнең чын остасы белән таныштырды. Әле аның да нindие диген! Күнне кисүдән башлап, читекнең соңгы җөенә кадәр үзе башкарган мондый осталардан Россиядә ул үзе генә.

Илдар ШӘЙХЕТДИНОВ Аксубайда туган. Гаиләдә алты бала үсә алар. Тормышны бөтәйтү өчен, 80 нче елларда әтиләре Гамир абый сарык тиресеннән унты тегәргә өйрәнә. Гаилә подряды булып олысы-кечесе бергәләп тотына бу эшкә. Илдар абый үз тормышын булдыргач та әлеге һөнәре ярап куя. Шактый еллар аяк киеме төзәтүче булып эшли ул.

Шулай бервакыт бер ханым аңа әнисенең чигүле читекләрен алып килә. Борынгы икәнлеге күренеп торган ул читекнең сыйфатына, бизәкләрдәге төсләр сайланышына карап, оста таң кала. Бернинди ярылып торган төсләр юк, барысы да шулкадәр табигый, үзара шулкадәр ярашлы...

Татар халкының күн мозаикасы белән Илдар Шәйхетдинов моннан ун-унике еллар элек кызыксына башлый. Бизәкләрне өйрәнә, тарихка күз сала, музейларда саклanучы күн мозаикасы белән таныша. Теләге булган җаен табар, диләр бит. Китаплардан карый-карый, булачак оста да үзенең бизәкләр коллекциясен булдыра. Күн кисәге бизәкле читеккә әверелгәнче, ничәмә капчык материал турамый?! Юк, чыгарып ыргытмый ул аларны. «Күн мозаикасы шуның белән дә кызыклы, – ди ул, – монда бер күн кисәге дә әрәм булмый. Хәтта 1 сантиметрлысы да эшкә яраклы».

Күн мозаикасын аппликация белән бутаучылар да булгалый икән. Аппликация ул – бөтенләй бүтән техника. Татарларның күн аяк киемнәрендәге бизәкләр исә вак-вак кисәкләрдән җыела. Һәр бизәк үзара махсус җөй белән тоташтырыла. «Казан җөе» – икенче төрле аны «читек җөе» дә диләр – бары тик татар халкына гына хас, башка бер генә халыкта да очрамаучы уникаль техника.

Бу рәвешле чигеп тегелгән иң борынгы читек-кәвешләр XIX гасыр башына карый. Әмма чигүле аяк киемнәре турындагы язмалар инде XVI–XVIII гасыр язуларында да очрый. Димәк, ул тагын да борынгырак.

Илдар Шәйхетдинов менә шушы борынгы һөнәрчелегебезне үзләштереп, кабат торгызып, башкаларга да өйрәтүче осталарның берсе инде. Остаханәсенең Казаныбызның иң борынгы урамнарының берсендә урнашуы да юкка гына түгел. «Казан ханлыгы яулап алынгач, татарлар Кабан күленең бу ягына күченә. Һөнәрчеләр мәчет тирәләрендә үзләренең остаханәләрен, мануфактура кибетләрен булдыра. Урамнар да шунда яшәүче һөнәр ияләренә бәйле атала башлый. Әйтик, әле бүген дә Казанда Күнче урамы атамасы сакланган. Бу тирәдә күнчеләр, читекчеләр яшәвенә ишарә ул, – дип, бераз тарихны яңарта оста. – Ул һөнәрчеләр мәчет-мәдрәсәләрне дә карап торган. Минем кабаттан шушы гадәтне торгызасым килә. Остаханәм шушы максатны да күздә тота. Мәдрәсәдә белем алучы балаларга, аларның әниләренә халык һөнәрчелеге буенча дәресләр бирәбез».

Күн мозаикасы серләренә, «Казан җөе»нә, читек тегү эшенә өйрәнергә теләүчеләр бүген дә бар. Башка шәһәрләрдән, күрше республикалардан киләләр, хәтта чит илләрдән дә кайталар. Үзе белгәнен башкаларга өйрәтү – Илдар абый өчен савапл эш. Ул һәр сере белән уртаклашырга әзер. «Бу эшне бер генә укучым дәвам итсә дә, тырышлыгым әрәм түгел, – ди. – Ләкин күпләр бер башлап карый да, кул селти. Әйе, кул эше белән коммерция күп очракта янәшә яши алмый. Фәкать матди файда гына күрергә омтылучылар өчен түгел бу кәсеп. Монда җаныңны салып эшләргә кирәк».

Беренче карашка бик катлаулы кебек тоелса да, читек тегәргә өйрәнүне артык кыен эш дими оста. Аның өчен иң минималь эш кораллары сорала. Илдар абый бер почмакта торган элеккеге кул машинасын өстәлгә куя. Хәтта менә шушы машинкада да тегеп була, дию. Ә башка эш коралларын ул үзе ясаган. Станок һәркемнең буена, гәүдә торышына карап ясала. «Бер читекне чигеп чыгу өчен тәүлегенә 10–12 сәгать станок артында утырырга кирәк. Эш урыны җайлы булса, бу эш ял гына», – ди оста. Бер читектә якынча 6 мең тирәсе атлам була. Илдар абыйның җөйгә карата да үз таләбе. Аның 1 сантиметрына нәкъ биш атлам сыярга тиеш. Дүрт тә түгел, алты да түгел – бишәү генә. Моның да сере бар. Алты атлам булса, җөйнең рельефлыгы инде бүтән, төеннәр ап-ачык ярылып ятмый, күзне иркәләми, атламнар бер-берсенә керешеп киткәндәй тоела. Менә шуның өчен дә ул үзе белән бергә эшләүче осталардан биш атлам таләп итә. Бу аның үз теләге генә түгел, клиентларның да теләге. «Кул эше бик сыйфатлы булырга тиеш. Яхшы күннән тегелгән сыйфатлы аяк киеме хуҗасына озак хезмәт итә. Меңа илле ел элек тегелгән аяк киемнәрен дә алып килгәннәре бар. Ул күннең сыйфаты



Читек – чигүле итек дигәнне аңлата. Икенче мәгънәсе – эчке итек.











бөтенләй бүтән шул», – дип аңлата үзенең таләпчәнлеген.

Күн аяк киемнәре өчен мөгезле эре терлек тиресе кулланыла. Юфть дип атала ул. Күпләр Гаяз Исхакыйның «Кәҗүл читек» әсәрен хәтерли булыр. Кәҗә яки сарык тиресеннән ясалган үтә дә нәзек, йомшак күнне кәҗүл дип әйтәләр. Оста бүгенге күннең химик состав белән эшкәртелүенә офтанып та куя. Сыйфаты кими, чыдамлыгы бетә, ди. Элеккеге чимал бары тик табигый матдәләр белән генә эшкәртелгән булган, шуңа да дистә еллар хуҗасына хезмәт иткән. Җепләрнең дә ефәген кулланганнар. Аларның төсләре дә уңмаган, сизрәмәгәннәр дә. Бүгенге осталар вискоза, полиэстер җепләр белән эш итә. «Казан җөе»ндә 10, 12, 14, 16 катлы җеп кулланыла. Монда барысы да мөһим: төсләрнең ярашуы да, контрастлылык та, җепләрнең ничә катлы булуы, хәтта ничек бөтерелүе дә...

«Өч атламнан соң кул үзе өйрәнә аңа», – дигән иде оста. Ай-һай! Шикләнүемне сизеп, Илдар абый станокны алдыма көйли. «Менә бу без гап-гади кадактан ясалган. Очындагы энәсе – тегү машинасыныкы. Озын улагы өскә карап торсын. Аны уң кулыңа тот. Сул кулга эш энәсе алына...» Беренче өч атламны ясаганчы тәмам каушап чыгам. «Булдырасың, булдырасың», – дип куәтли оста.

Остаханә киштәсендә әзер читек-кәвешләр, чүәкләр хуҗалары килеп алуны көтә. Игътибарымны башы өскә таба очланып торган башмаклар җәлеп итә.

– «Султанкалар» бу, – дип аңлата Илдар абый. – Төрки яугирләр уйлап чыгарган аяк киеме. Очлы башы ат белән идарә итү өчен кулай булган. Аның ярдәмендә өзәңгегә эләгеп, егылудан сакланып калганнар. Намаз уку өчен дә уңай ул.

Асты йомшак читекләрне бүлмә эчендә киеп йөрү җайлы. Урамга чыкканда аның өстеннән кәвеш киеп куела. Элеккеге татарлар шулай киенгән. Күн аяк киеме бик уңайлы бит ул – кышын аякны туңдырмый, җәен тирләтми. Читекнең тәбәнәк үкчәле булуы да сәламәтлек өчен файдалы. Үкчәнең 2,5 сантиметрдан артмавы умыртка баганасын, аяк буыннарын саклый. Бүген күпчелек хатын-кыз артык биек үкчәле аяк киеме киеп йөреп сәламәтлеген бетерә.

Читек тегүнең бер авырлыгы юк дисә дә, четерекле яклары бихисап, әлбәттә. Аякка ятып торсын өчен иң әүвәл аның өлгесе үк дөрес булырга тиеш.

– Кәвешләрне теккәндә уңайлы өлге әзерли алмый аптырадым. Ничек кенә тексәм дә, йөргәндә үкчәсе аяктан төшә иде, – ди оста. – Бер өлге белән башта берничә пар аяк киеме тегелеп, кешеләргә кияргә бирелә. Кайсы җире уңайсыз, кайсы җире кыра, кайда бушрак – бөтен кимчелекләре ачыклана. Икенче өлгедә бу кимчелекләр бетерелеп, тагын берничә пар тегелә. Кабат барлык җитешсезлекләр төзәтелә. Менә шуннан соң гына бу өлге куллануга әзер була.

Күбесенчә кара, аксыл, сөтле чәй, елга комы төсле читекләрне сорыйлар икән. Ул төсләр һәртөрле кием белән дә яраша. Бизәкләрне сайлаганда да зәвык кирәк. Читекче ул үзе рәссам, үзе модельер, үзе кисүче, үзе чигүче һәм тегүче дә.

...1883 елда Парижда татар читекләре алтын медаль белән бүләкләнә. Германия музеенда чигелгән читек татарларның символы буларак куелган. Әйе, чигүле читек, «Казан җөе» – безнең бренд ул. Илдар Шәйхетдиновның хыялы – шушы брендны тагын да ныграк таныту, әлеге һөнәргә тагын да күбрәк кешене өйрәтү, чигүле читекләрне һәркемнең аягында күрү.

P. S. Остадан файдалы киңәш: чын күнне тану өчен, аны уң кул белән тотып карарга кирәк. Кул күнгә орынган мизгелдә уч төбенә җылы бөркелсә, бу – чын күн. Ясалма күннән кулга салкын бәрелеп тора.

МОДАДА – МИЛЛИЛЕК

Хәзерге заман этнография фәнендә һәм җәмгыятьтә милли кием дигәндә гасырлар буе калыплашкан традицион өс һәм аяк киемнәре, шушы милләт вәкилләре кулланган аксессуарлар күздә тотыла.

Нурия УМАЙ – татар халкының милли традицияләрен, шул исәптән, һөнәрчелеккә, никах укыту һәм милли костюмга кагылышлы гадәтләрне дә яңарту һәм популярлаштыруга йөз тоткан «Национальный» – «Милли» мәдәни-социаль проектның авторы. «Балачактан матурлыкны яратам, – ди ул. – Төрле образлар, матур өс киемнәре иҗат итә идем. Хәзер бик кызыксынып төрки-татар мәдәниятен, мифологиясен, орнаментикасын өйрәнәм. Алар миңа стильләштерелгән милли киемнәр булдыру идеясен бирде. Бүген Татарстанның иң яхшы мастерлары белән хезмәттәшлек итәм, шуңа да теләсә кайсы идея тормышка ашырырлык». Алар иҗат иткән костюмнар – татар киеменең җыелма мәгънәсе. Нурия Умай киемнәрендә традицияләр дә, тарих та, татар халкының символлары да бар.

Бүгенге татар җәмгыятендә, аеруча аның алдынгы карашлы өлешендә (бизнесменнар, иҗади элита, фән эшлеклеләре), үзләренең татар милләтенә хасиятле булуларын милли костюм элементлары аша күрсәтү ихтыяҗы барлыкка килде.

Милли кием сайлаучыларга киңәшләр.

Көндәлектә куллану өчен традицион татар милли бизәкле аксессуарлар отышлы. Әйтик, стильләштерелгән лалә чәчәге рәвешендәге брошьлар, татар бизәкле алкалар, беләзекләр. Хәзер яшьләр милли бизәкләр төшерелгән футболка һәм туникаларны бик яратып кия. Сыйфатлы һәм дөрес башкарылган булса, бу бик матур күренә.

Тантаналы очраклар, бәйрәмнәрдә киеменңне хәситә яки яка чылбыры, изү белән бизәргә була. Кулдан чигелгән ефәк яки йон палантиннар да модага кереп бара.

Татар элитасы бу бизәкләрне ханнар заманыннан ук кулланып килгән. Безнең көннәрдә ул алтын-көмеш яки асылташлар белән генә түгел, ә ярымкыйммәтле ташлар, аппликация ысулы, Коръән савыты кебек бөтиләр дә кулланып ясала. Бүгенге хәситәләр төрлечә эшләнергә мөмкин. Ул тулысынча зәркән эшләнмәсе рәвешендә дә була ала, хәтта традицион лалә чәчәкләре кулланылган пэчворк техникасы яки чигү белән башкарылуы да ихтимал.

Традицион татар киемен милли бизәкләр һәртөрле фасоннар белән яраштырып кия белү үзе бер сәнгать, этикетның мөһим өлеше. Милли кием кигән хатын-кыз үз халкының гореф-гадәтләренә ихтирам күрсәтеп кенә калмый, әлеге халыкка хасиятле булуы белән үзе дә горурлана.

Рәмзия КАШАПОВА

Инстаграм: **@raido_hotenamel**



• Моңарчы онытылган һәм осталар тарафыннан кабат торгызылган борынгы «кайнар эмаль» технологиясе белән эшләнмәләр җитештерү.

• Татар бизәнү әйберләре ясау һәм реставрацияләү.

• Сезнең эскиз белән автор эшләнмәләре булдыру.

• Никах һәм башка тантаналар өчен зәркән шәмаилләр ясау.

Контактлар: **+7 (927) 40-49-448; +7 (904) 66-45-744**

РЕКЛАМА



WA: +7-987-404-82-86

- **тантаналар һәм чаралар уздыру (туйлар, никах, юбилейлар һ. б.);**
- **никах өчен кәләш белән кияүнең образларын уйлап табу;**
- **тантаналы һәм эшлекле очрашулар өчен заманча татар костюмы булдыру;**
- **эксклюзив баш киемнәре;**
- **кутюрьедан кул белән чиккән чигү, кулдан бизәлгән автор тукымалары, зәркән эшләнмәләр;**
- **татар халкының традицияләре темасына семинарлар һәм сессияләр уздыру.**

Instagram: @nuriya_umai

РЕКЛАМА

PRESSA



ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН

Заманасы өчен зур тоелган ачышлар гасырлар үткән саен төссезләнә, югала бара. Ярый ла моңа катышы булган исемнәр онытылмаса?! Ә казанышлар өчен бөтенләй башка берәүләр макталса? Талантлы уйлап табучылар исеме еллар диңгезендә югалса?! Тик тарих тәгәрмәче гаделлекне барыбер тантана иттерми калмый. Еллар, дистә еллар үтсә дә. Язмабыз – шундый шәхесләрнең берсе хакында.



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

ТАССР
1920-2020



«Әскар Гали улы Шәехгали турындагы архив документлары кулыма очраклы гына килеп керде. Узган гасыр башындагы татар зыялылары вәкиленең фаҗигале язмышын игътибарсыз калдыра алмадым. Аның исемен еллар буе телгә алмадылар, уйлап табулары, инженерның оригиналь ачышлары гаделсез рәвештә укучылары, коллегалары исеменә язылган...» – «Казан хисаплау техникасы музее» директоры Маргарита БАДРУТДИНОВА сүзен әнә шулай башлады. Милли архивка сорау җибәргәч тә, «андый кеше юк» дигән җавап килә аңа. Тик Маргарита ханым туктап калмый, әлеге шәхес язмышын өйрәнү аның тормыш мәгънәсенә әйләнә. Төп эшеннән буш вакытларында 15 ел буе (!) тарихта казынып, гаделсезлекне фаш итә. «Эхо веков. Судьба изобретателя» исемле китап язып бастыра. Әскар Шәехгали – талантлы инженер, Мәскәүдә, Урман-техник институтының төгәл механика остаханәсендә механик, аннары мөдир булып эшләгәндә гарәп графикасы нигезендә татарча текстлар җыю өчен яңа төр язу машинасы конструкциясен эшли. Без һич шикләнмичә СССРның беренче язу машинасы авторы, Казан «Пишмаш» заводына нигез салучы дип әйтә алабыз. Әскар Гали улы Шәехгалинең тамырлары Казакъстан далаларына барып тоташа. Әүвәл заманнарның аксөяк затлары – Бүкәй Урдасының соңгы ханы, рус армиясе генералы Җиһангир (Җиһангир Нургали улы Бүкәев) Россиянең беренче мөфтие Мөхәммәтҗан Хөсәеновлар токымыннан ул. Хатыны Суфия Әхмәрова – Казанның иҗади татар зыялылары гаиләсеннән. Әхмәровлар язмышы – үзе аерым тарих! Маргарита ханым алар хакында сәгатьләр буе түгел, тәүлек әйләнәсе сөйли алады. Ул шулхәтле бирелеп һәм мавыгып бәян итә – моннан бер гасыр элек булган вакыйгалар җанланып, күз алдына килеп баса.

XX гасыр Стив Джобсы

Әскар Гали улы Шәехгали – мәшһүр ата-бабаларыннан мирас булып күчкән акылы, алтын куллары белән төрки дөньясында үз эзен калдырган олы шәхес. 1885 елда дворян гаиләсендә туган. Әтисе – Россиягә 1860 елда Төньяк Кавказдан, имам Шамил гаиләсе белән бергә килгән кеше, шул елдан империя армиясендә хәрби хезмәттә, отставкага генерал-майор дәрәҗәсендә чыга – җәмәгать эшлеклесе, Санкт-Петербургта мөселман җәмгыяте башлыгы Гали Дәүләт улы Шәехгали. Бу кеше мөселман балалары өчен приют, мәктәпләр ача. Шәһәрдә мәчет салдыру өчен янып йөри. Шәехгали гаиләсе Петербург, Казан, Оренбургта татар телендә нәшер ителүче басмаларда еш искә алына. Әнисе Гөлсем Тәфкилева – Бүкәй Урдасының соңгы ханы Җиһангир һәм Россиянең беренче мөфтие кызы Фатыйма дәвамчысы. Кечкенә Әскарның гимназиядә укыган еллары Россиядәге «техник күтәрелеш» чорына туры килә. Керосин лампаларын «Ильич утлары» алмаштыра, шәһәрдә беренче трамвайлар йөри, күккә беренче аэропланнар күтәрелә. Әскар техника белән «женләнә». Беренче казанышы – үзе укыган гимназиянең актлар залына электр уты үткәрә. Гимназия директоры шул вакытта ук егеткә инженер киләчәге юрый. Әскар өчен бу иң зур мактау сүзләре булып яңгырый. Ул заманда әлеге һөнәр ияләре алтын бәясенә тора бит! Гимназияне тәмамлагач, Петербург университетының физика-математика факультетына укырга керә. Танылган татар мәгърифәтчесе Шаһбазгәрәй Әхмәров кызы Суфиягә студент елларында ук гашыйк була һәм өйләнә. Бу инде тыныч, көйле тормышка чик куелган көннәр. Илне бер-бер артлы сугыш афәте каплый. Беренче бөтендөнья сугышы, гражданнар сугышында катнашып демобилизацияләнгәч, Әскар Шәехгали Мәскәүдә фатирлы булып, ике кызы, хатыны, әнисе, тол калган апасы Мәрьям белән тыныч тормышта, яңа шартларда яшәргә өйрәнә башлый. Ул хакимият алышынганнан соң җәмгыятьтә үз урынының табарга кирәклеген аңлый. Алтын куллары булачак һөнәрен билгели. Төрле механизм һәм җайланмаларны җыеп-сүтүне биш бармагыдай белгән инженер эш эзләп озак интекми. Урман-техник институты каршындагы төгәл механика остаханәсенә механик булып урнаша. Нәрсә генә ремонтларга туры килми аңа: йозаклар, арифмометрлар, сейфлар, язу машиналары... Соңгылары белән бигрәк тә кызыксына. Чит илләрдә чыгарылган (ул вакытта язу машиналары Россиядә җитештерелми) машиналарны төзәтеп, функцияләрен тагын да камилләштерә.

Ә бу вакытта Казан яңа шартларда яшәргә өйрәнә. 1920 елда Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелә. Бер елдан соң ТАССР территориясендә махсус декрет белән татар теле дәүләт теле дип игълан ителә. Канун буенча республика күләмендә документ әйләнеше татар телендә дә алып барылырга тиеш була. Тик моның өчен техник мөмкинлекләр җитешми. Документларны кулдан язалар. Бу хәл җирле хакимиятне уйга сала. Килеп туган бу четерекле хәлдән Әскар Шәехгали коткара. Шул заманның Стив Джобсы була ул! Тик талантлы инженерның Казанга күченеп килүе тормышындагы иң зур хатасы да булгандыр, бәлки. Әмма язмыштан узмыш юк шул...

Ул елларда язмада гарәп графикасы кулланыла. Гарәп хәрефләре белән баса торган язу машиналары юк. Яшь республикадагы әлеге проблеманы туганнарыннан, дусларыннан ишетеп белә Шәехгали. Һәм тәвәккәлләп зур эшкә алына: чит илдә җитештерелгән язу машинасын гарәп графикасына яраклаштырып көйли!
Ике патент ала. Республика җитәкчелеге тиз арада әлеге патентларны куллану өчен лицензия булдыра һәм Шәехгалинең Казанга күченеп килүенә ирешә. Инженерны Татар язу машиналары остаханәсе – «ТАТЯЗМАШ»ка механик, аннары аның мөдире итеп билгелиләр.
Тик остаханә әле сүздә генә була. Шәехгали аны үзе оештыра. Кирәкле җиһазлар сатып ала, кадрлар туплый, аларны өйрәтә. Менә ни өчен «ТАТЯЗМАШ» аңа баласы

Хәтта гарәп графикасын моңарчы кулланган чит илләр дә Казан чыгарган машиналарны алырга теләде.



Әскар Гали улы Шәехгали хәләл җефете Суфия ханым һәм кызы Динора белән. 1913 ел.

кебек кадерле була! СССРның төрле милли республикаларыннан да заказлар килә башлый.

«82 ләр хаты»

СССР җитәкчелеге, Төркия үрнәгенә ияреп, гарәп графикасыннан яңалифкә – латинга күчәргә мәҗбүрили башлый. Янәсе, иске язу дин белән бәйле, ул социализм төзергә комачаулый. Зыялылар арасында алфавит буенча кайнар бәхәсләр куба. Кемнәрдер яңалифне яклый, интернационализм юлындагы зур адым дип бәяли. Икенчеләре, татар халкы гарәп графикасыннан баш тартып, бай мирассыз калачак дип искәртә. Ул вакытта гыйлемле татар бары тик гарәп графикасында гына язган. Мирастан өзелүне, буыннар бәйләнешендә килеп чыккан кыенлыкларны безгә аңлатып торасы юк, үзебез кичердек. Без хәтта борынгы кабер ташларындагы язуларны да укый алмыйбыз. Ләкин монысы, кем әйтмешли, бөтенләй икенче зур фаҗига.

Латин графикасына күчәргә каршы булганнар арасыннан 82 интеллигенция вәкиле, СССР җитәкчелегенең бу ашыгыч адымын шик астына куеп, И. В. Сталинга хат яза. 78 нче кеше булып бу хатны Әскар Гали улы Шәехгали дә имзалый. «82 ләр хаты» дип тарихка кереп калган әлеге документка кул куйганнарның алдагы язмышы ничек тәмамланганын чамалыйсыз инде... Дүрт ел эчендә алар барысы да «халык дошманы»на әйләнә. Гарәп графикасы бары тик ун ел гына кулланылышта булып кала. Ә күпме язмышлар сына...

Белгечләр кытлыгы шартларында да Шәехгалинең таланты ярдәмендә остаханәдә эш гөрли. Алар машиналарны латин графикасына көйли. Инженер идеясе белән 1929 елда Казанда, илдә беренче тапкыр, барлык деталь һәм конструкцияләре үзенеке булган һәм латин графикасы нигезендәге татар шрифты куелган «Яңалиф» язу машиналары эшләнә. Тик Шәехгалинең барлык милли республикаларны тәэмин итү өчен зур производство булдыру идеясе ТатЦИК һәм Совнарком җитәкчелеге тарафыннан яклау тапмый. Алар җаваплылыктан курка. Хәтта амбицияле җитәкче идарә иткән остаханәне ябарга да уйлыйлар. Шәехгали бирешми. Ул үзенең «баласын» Мәскәүгә алып китеп экспертизага бирә һәм аны «совет материалларыннан СССРда ясалган беренче язу машинасы» итеп теркәтүгә ирешә. Зур көч түгеп, Шәехгали остаханәне дә яптырмый кала. Алай гына түгел, остаханә базасында «Пишмаш» заводы ачылып, ул шунда директор һәм баш инженер вазыйфаларын башкара.

Җанын биреп эшләгән җитәкчене 1931 елда эш урынында кулга алалар. «82 ләр хаты»н искә төшерәләр. Дәһшәтле 58 нче статья буенча гаепләп, биш елга лагерьга озаталар. Ул Ак Диңгез-Балтыйк каналын төзүдә катнаша. Тик гәүһәр су төбендә дә ялтырый. Талантлы инженер анда да баш энергетикның исәп-хисаплары дөрес түгеллеген исбатлап, гидротехник төзелешне зур чыгымнардан алып кала. Моның өчен аны бүләклиләр – вакытыннан алда иреккә чыгаралар. Тик Шәехгалигә зур шәһәрләрдә, шул исәптән, Казанда да яшәргә рөхсәт ителми. Суд хөкеме дә юкка чыгарылмый. Реабилитация сорап, берничә тапкыр хатлар белән мөрәҗәгать итеп карый. 1953 елда Сталин вафат булгач кына боз кузгала – 1959 елда гына аның эшен кабат карап, гаепләүне алалар. Казанга ул бары тик 20 елдан соң гына кайта ала. Аңа инде 75 яшь була.

Гомеренең соңгы көннәренә кадәр яраткан эшеннән аерылмый инженер. Янәшәсендә ике кызы була. Табиб һөнәрен үзләштергән Динора, Бөек Ватан сугышында катнашып, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Гомере буе табиб булып эшли. Медицина фәннәре буенча кандидатлык диссертациясе яклый, ТАССРның атказанган табибы исеменә лаек була. (Динора Шәех-Али хакында журналыбызның март санынннан укырга мөмкин.) Гульнор инженер-химик була. Ә Шәехгалинең тагын бер «баласы» – язу машиналары заводы, заманга яраклашып, башка төр продукция чыгара башлый. Язу машиналарын инде күптән компьютерлар алыштырды. Совет чорындагы техник күтәрелешнең бер символы булган бу җиһазны хәзерге буынның белмәве дә ихтимал. Тик моңа карап кына Әскар Гали улы Шәехгалинең интеллектуаль табышы юкка чыгарга тиеш түгел. Ул – XX гасырда төрки дөньяның мәшһүр бер уйлап табучысы, ТАССР үсешенә зур өлеш керткән зур шәхес. Ә иң мөһиме: авырлыкларга бирешмичә, нык рухлы көчле кеше булып кала алган шәхес!

Шәехгалинең якты йолдызы

Һәр уңышлы ир заты артында зирәк хатын тора, диләр. Әскар Шәехгали дә, бәлки, язмыш сынауларыннан сынган булыр иде, әмма тугры хатыны Суфия Шаһбазгәрәй кызы аның тормышта терәге, ярдәмчесе, якты йолдызы, ныклы тылы була. Яшьлектә кабынган ярату хисе гомер буе озата бара аларны. Аерылышып яшәргә туры килсә дә, мәхәббәтләре сүнми, киресенчә, ныгый гына... Беренче татар профессиональ актрисаларыннан берсе, театр күгендә йолдыздай балкырга тиешле талант иясе сәхнә карьерасын гаилә тормышына алыштыра, гомере буе ир хатыны булып яши.

Маргарита Бадрутдинова Суфия Әхмәрова гаиләсен дә җентекләп өйрәнә. «Борынгы татар морзаларыннан булган бу нәсел әгъзаларының һәрбарчасы – XIX йөз ахыры XX йөз башлары Казан татар зыялыларының алтын вәкиле», – дип сөйли Маргарита ханым. Милли гореф-гадәтләр, дини кануннарны саклап калып, дөньяви мәдәнияткә тартылучы гаилә була бу. Әтиләре Шаһбазгәрәй – Казан татар укытучылар мәктәбе директоры – бөтен гомерен татар халкын агартуга багышлый. Әниләре Хәдичә – Казанда укучы яшьләр өчен «Шимбә» түгәрәген оештыручы. Гомумән, театр ул заманнарда бер культка әйләнә. Барлык зыялы яшьләр театр тирәсендә кайнаша. Алардан бөек актерлар, музыкантлар үсеп чыга. Алдынгы карашлы Әхмәровлар өчен «Шимбә» икенче йортына әйләнә. Балаларының театрга булган мәхәббәтен өлкән буын хуплый. Шуңа да кызларының язмышы тарихи «Сәйяр» труппасы белән бәйле. Әхмәровларның җиде баласы да – заманының укымышлы кешеләре. Ләкин гражданнар сугышында ике уллары һәлак була, өченче уллары кулсыз кайта. Олы кызлары Маһипәрвәз, Петербургта хатын-кызлар медицина институтын тәмамлап кайтып, Казанда дипломлы беренче татар хатын-кыз гинекологы булып танылa. Әхмәровлар йортында авыруларны кабул итү өчен махсус кабинет ачыла. Маһи гомеренең ахырына кадәр һөнәренә тугры кала. Ленин ордены белән бүләкләнә, ТАССРның атказанган табибы исеменә лаек була. Сара – Россия юристы һәм фәлсәфәчесе. Үтә зыялы һәм укымышлы кызларына гаилә зур өметләр баглый. Тик Мәскәүдә яшәүче Сара, дин тарихы һәм фәлсәфәсе белән кызыксына башлап, католик диненә күчә. Бу хыянәтне әнисе соңгы көненә кадәр кичерә алмый. Кызына хәтта ата-ана йортына кайтырга рөхсәт булмый.



Әхмәровлар гаиләсе.

Фотолар: М. Бадрутдинова архивыннан.

Кече кызлары Заһидә Казан медицина университетына укырга керә. Кечкенәдән спектакльләрдә катнашып үскән кыз «Сәйяр» труппасы актрисасы да була. Шул чорда танылган режиссер, драматург Кәрим Тинчурин белән таныша. Әнисеннән фатиха алып, Заһидә тормышын Кәрим Тинчурин белән бәйли. Табиб булырга язмый аңа, ул иренең ярдәмчесе, фикердәше булып китә. «Халык дошманы»на әйләнгән Кәримгә гомере буе тугры кала, аның мирасын барлап, киләсе буыннарга тапшыра, иренең намуслы исемен кайтаруга күп көч куя.

«Шимбә» түгәрәгендә әзерләнгән спектакльләрдә гимназистка Суфия дә катнаша. Шаян, фантазиягә бай кызга, төрле рольләргә кереп, сәхнәдә уйнау бик ошый. Гомерен театр белән бәйләргә уйлап, ул Петербургта шәхси театраль студиядә укый. Ике ел укып кайткач, профессиональ татар актрисасы дәрәҗәсендә спектакльләрдә уйный. Петербургта укыганда Әскар Шәехгали белән таныша. Алар кавыша. Казанны, театрны калдырып, Суфия ире янына Петербургка күченә. Бер-бер артлы ике бала тапканнан соң, богема дөньясы еракта калган кебек тоела. Шулай да җәйләрен, туганнары белән очрашканда, төрле пьесалардан өзекләр уйныйлар әле. Тик тыныч, кайгысыз тормышны сугыш җимерә. Ирен сугышка алганнан соң, Суфия балалары белән Казанга кайта. Анда яшьлек хыялы белән кабат очраша әле. «Сәйяр» театры куйган спектакльләрдә уйнап ала. Тик бу дөньяда ул хәзер «кунак» кына була.

«Халык дошманы» хатынына әйләнгәч, Суфия ханым бик зур авырлыклар белән язу машинасында текст җыючы булып эшкә урнаша. Аннары Мәскәү янындагы кечкенә бер шәһәргә күченә. Кызы Динора да шунда табиб булып эшли. ГУЛАГ лагереннан азат ителгән әтиләре алар янына кайта, эш таба. Әмма аны, зур шәһәрләрдә яшәргә рөхсәт булмаганлыктан, гаиләсеннән аерып, Алатырьга җибәрәләр. Суфия балалары белән кабат ялгыз кала. Ул елларда гаилә бергә җыелышудан да курка. «Халык дошманы» исемлегендә торган ата сөекле кызларының тормышына зыян салудан шикләнә. Шуңа да аерым яшәргә мәҗбүр булалар. Бөек Ватан сугышы башлангач, Суфия Казанга – әнисе һәм кызы Гульнор янына кайтып, гаилә җылысын саклап яшәргә тырыша. Әмма инде ире янәшәсендә гомер итә алмый кала. Әскар Казанга әйләнеп кайтканда ул инде җир куенында була.

Аларга бергә бакыйлыкта гына булырга язган, күрәсең. Иске татар зиратында каберләре янәшә. Кызганыч ки, затлы шәхесләрнең соңгы йорты бүгенге көндә караусыз, инженерның дусты Бакый Урманче ясаган истәлекле кабер ташлары да ташландык хәлдә. Ләкин гаделлек тантана итми калмас. Әскар Гали улы Шәехгалинең татар дөньясын үстерүгә, алга җибәрүгә керткән өлеше лаеклы бәясен алыр, мәңгелек йорты да тәртипкә китерелер.

Дөнья куласа...

ИЛЕ БЕЛӘН КЕШЕ МӘРТӘБӘЛЕ...

Сибгат ХӘКИМ

Бер горурлык хисе

Бер горурлык хисе яна миндә,
Эчтән бәреп яна битләрдә.
Сөйләр идем аны дөньядагы
Барлык-барлык парламентларда.

Кирәк булса, дөнья картасыннан
Кырык илне эзләп табармын.
Мин яшәгән Татарстан менә,
Күр, кайларга илтә товарын...

Керосины да юк, көндездән ул
Телеп куя иде чырасын.
Кем юрады икән нефть төяп
Океаннарга аның чыгасын?!

Карындыклы иде тәрәзәсе,
Яба, яга иде саламын.
Хәзер аңа дөнья базарында
Зур дәүләтләр бирә сәламен.

Татарстан үсте, үзе булыша
Ул элекке колонияләргә...
Эшем дә шул минем: җырлап илтү
Халыкларның данын елларга.

Бер горурлык хисе яна миндә,
Эчтән бәреп яна битләрдә.
Сөйләр идем аны дөньядагы
Барлык-барлык парламентларда.

Роберт ӘХМӘТҖАНОВ

Төп йорт

Төп йортым син, төп йортым,
адым белән үлчәнгән
яшел кәсле төп йортым –
түмгәкләр һәм билчәннәр
телен белгән төп йортым...
Төп йортым син, төп йортым,
тургайлы түбәләрем!
Тәрәзәңдә кемнең бу
Ак җаны – күбәләге?
Төп йортым бу, төп йортым,
бабамнар сөйләшкән җир!
Чит җирдән бүреге белән
кайтырга киңәшкән җир...
Бәхетле кеше генә
ятып үз түшәгенә,
багып үз түшәменә,
суың эчкән бер йотым...

Туган илем – Идел-йорт,
Татарстан – төп йортым!

Салисә ГӘРӘЕВА

Татарстан

Карталарда уч төбедәй генә
Минем тыйнак Татарстаным!
Ул охшаган чигү үрнәгенә
Сафьян читек теккән Останың!

Ул йөрәгем кебек тибеп тора,
Нефть ургымнарын озатып;
Ул күпереп пешкән икмәк кебек,
Күңелләр көр шуңа, тамак тук.

Борынгыдан Болгар ярын юып,
Диңгезләргә ага Иделем;
Халкым гомер иткән төбәкләр бу –
Үз туфрагым минем, үз илем!

Магнит кебек ул үзенә тарта
Татар җанын, татар бәгырен.
...Чит җирләрдә генә аңлыйбыз без
Туган-үскән җирләр кадерен!

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ

Татарстаным

Шагыйрь дустым сәяхәттән кайткач
Әйткән иде, Татарстаным,
Картадагы синең сурәтеңнең
Чабып барган атка охшавын.

Ничек кенә әле чабасың син,
Томырылып,
Татарстаным,
Ялларыңнан чытырдатып тотып
Синең белән мин дә очамын.
Синең белән ул – без мәртәбәле,
Синең белән ул – без канатлы,
Бабаларым, атларыннан егылып,
Ничә тапкыр борын канатты...

Затлы аргамаклар кайсы чорда,
Кайда гына илтеп сукмады?!
Ил бәясе башлар ярылдылар,
Шөкер әле күзләр чыкмады.

Ярый әле шундый заманнарда
Югалмаган күрү сәләте,
Егылганда авырткан җир була,
Авырткан җир була, гадәти.

Авырткан җирем син – Татарстан,
Без чабабыз менә әлегә...
Әмма беләм, кайда бәрелсәң дә,
Авырткан җир алдан бәрелә.

Авырткан җирем син – Татарстан,
Син йөрәктер миңа, бәгырьдер...
Кайда гына килеп бәрелсәм дә,
Иң беренче сиңа бәрелер.

Башка халыклар күк безне дә бит
Азатлыкка сусау уяткан.
Без чабабыз,
Еллар очкын булып
Очып кала безнең тояктан.

Без чабабыз
еллар,
чорлар аша,
Яңгыратып бөтен тарафны,
Иле белән кеше мәртәбәле,
Иле белән кеше канатлы.

Бер канатың була туган илең,
Бер канатың була туган җир;
Кошка гына түгел, кешегә дә
Канат кирәк була торгандыр.

Син чыннан да, илем, әкияттәге
Чабып барган атка охшаган.
Шушы ике канат бар чагында,
Киләчәккә, илем, ышанам.

Разил ВӘЛИЕВ

Ватаным

Инде мин ничәнче мәртәбә
Гасырлар китабын актардым.
Күпме яу, сугышлар аркылы
Син җиңеп чыккансың, Ватаным.

«Сез кайсы халыктан?» – дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр,
Тик исән булсын, дип, Ватаным.

Илемнең хуҗасы булганга,
Мин җиргә нык басып атладым.
Кешеләр күтәрде Ватанны,
Кешене күтәрде Ватаным.

Мин күрдем, төннәрне таратып,
Дөньяда алсу таң атканын.
Яктыра, аллана җир йөзе...
Таң булып нур сибә Ватаным.

«Сез кайсы халыктан?» – дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр,
Тик исән булсын, дип, Ватаным.

Саҗидә СӨЛӘЙМАНОВА

Ак калалар

Траншеяләр,
ташлар өеме,
узганмыни яулар!
Таш калалар сала кыюлар,
актарыла таулар.

Ак калалар сала кешеләр,
ай катында утлар.
Акчарлаклар оча диярсең –
ак чардаклы йортлар.

Кәрван шәһәр
Кама ярында,
колачлары зурдан.
Яшь калага яулык болгыйлар
ак кораблар судан.

Ак калалар сала кыюлар,
як-яклары – урман.
Таш калалары бизи кешеләр,
урам – каен бульвар.

Ага Кама, атлый төзелеш,
адымнары күркәм.
Ак каеннар әнә тезелеп
суга бара иртән.

Гәрәй РӘХИМ

Туган илем – Татарстан

Синең тарих – минем гомер башым,
Киләчәгең – минем киләчәк.
Син күрексез булсаң – мин күрексез,
Һәм син чәчәк булсаң – мин чәчәк.

Мин дошманга синең җавап белән
Җавап бирдем – кайтты үчләрем.
Тик сүземне үлчәп сөйләдем мин –
Синең үлчәм белән үлчәдем.

Синең үсеш белән мин зур үстем,
Синең дәртең белән дәртләндем.
Канатларың белән канатландым,
Шатлыкларың белән шатландым.

Синең яшьлек белән яшәрдем мин,
Синең яшен белән яшьнәдем.
Синең көнең белән көн күргәнгә,
Синең гомер белән яшәрмен.

Син бит мине шундый көчле иттең,
Өстәп бирдең тагын изгелек.
Рәхмәт, илем! Инде үзем сине
Күтәрергә көчем бар кебек.

Фәннур САФИН

Татарстаным

Чын батырлар җире, диеп,
Мактау ява барлык дустан.
Кайда гына, кемнәр генә
Белми сине, Татарстан!

Кара алтын вышкаларын
Кулларына тотып барган
Сабыр җанлы батыр кебек
Күренәсең ераклардан...

Ә иңендә шул батырның
Дулкынлана арыш кыры.
Офыкларга кадәр яңгырый
Көрәш җыры, ярыш җыры.

Бу җирләрдә бар кешелек
Бәхете өчен көрәш бара.
Туганнарын чакыра ул
Хезмәт тулы мәйданнарга.

Аның якты көрәш дәрте
Килеп чыга далаларга.
Читкә китеп карап тора
Үзе салган калаларга.

Карашыннан таныгандай,
Йомшак куллы җилләр килеп,
«Рәхмәт!» диеп, маңгаеннан
Тирен сөртеп китә кебек...

Клара БУЛАТОВА

***

Шушы яктан, шушы туфрактан без.
Китә калсак, үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр елап озата.

Шушы яктан, шушы туфрактан без.
Читтә йөрсәк шуңа күрәдер,
Чишмә чыңлап, өянкеләр елап,
Таллар җырлап төшкә керәдер.

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Шушы җиргә дәшеп кайтырга,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр зурлап чакыра.

Мөхәммәт МИРЗА

Идел-Йорт

Идел-Йортта гомер иткән халкым,
Чуен койган, иген иккән ул.
Игелекле, батыр, гадел атын
Тап төшерми горур йөрткән ул.

Бабайлардан мирас – Идел-Йорт –
Ядкаре һәм намус аклыгы.
Безнең максат, кардәш, истә тот –
Хак Ватанның чәчәк атуы.

Идел-Йортта шөһрәт тоткан халкым,
Тылмач кирәкмәгән аңарга.
Иле, ирке булса, югалмас ул
Сынау тоткан тарих-заманда.

Бабайлардан мирас – Идел-Йорт –
Ядкаре һәм намус аклыгы.
Безнең максат, кардәш, истә тот,
Хак Ватанның чәчәк атуы –
Татарстанның чәчәк атуы!

ТАССР 1920-2020



Тылсым

Дәресләр тәмамлангач, барлык кызлар, малайлар, шау-гөр килеп, кайсы кая таралыштылар. Сажидәгә исә тагын эш табылды: тәрбияче Нәжибә, аңа игълан язарга кушып, малайлар яши торган тулай торакның кызыл почмагына кертеп утыртты. Тышкы ишек янында, табуреткада утыручы кизү егет Идрискә:

— Кызыл почмакка берәүне дә кертмә, — диде. — Сажидәне борчып йөрмәсеннәр, тынычлап кына эшләсен.

Сажидә өстәлдәге яшел постауга ак кәгазь җәеп салды да, катыргы кисәгендә пумалачык белән төрле төстәге буяуларны бутарга кереште. Ул моны гадәттәгечә бик бирелеп, ләззәтләнеп эшләде, ерактан ук күренерлек булып, янып торган шаян хәрефләрне язганда калын ирен читләрендә елмаю чагылды. Ул буяу белән эш итүдән тәм таба, андый чакта рәхәтлек кичерә, чөнки буяуларның башка бик күпләр өчен яшерен серен, тылсымын белә, төсләрнең кеше күңеленә ничек тәэсир иткәнен бик нечкә сизә, тоя иде.

Аның бу сәләте бөтен училищега мәгълүм, ә буяучылыкка өйрәтүче Асия шундый укучысы булуга сөенеп бетә алмый иде. Буяу бит ул бик хикмәтле нәрсә. Юеш чакта бертөсле була, кипкәч, бөтенләй икенче төскә керә дә куя. Ә менә Сажидә стена буявының кипкәч ни төслегә керәсен алдан ук чамалый. Бүлмәгә күз йөртеп чыга, тәрәзәләргә кояш ничек төшкәнне карый, аннары буяу тулы чиләк янына баса да, учын учка кушып, бармакларын ияк астына терәгән хәлдә бераз уйлана. Башкалар, тылсымчыга карагандай, күзләрен зур ачып, тын калып, хәрәкәтсез басып торалар. Ниһаять, Сажидә:

— Яшелне өстик әле. Җылырак булсын,— ди.

Ул төсләрне «матур» я «ямьсез» дими, «җылы» яки «салкын» ди. Чыннан да, ул буяган стеналардан җылылык бөркелә сыман тоела иде.

Беренче курста укучы малайларның һәммәсе дә Сажидәгә гашыйк, кызларның да күбесе аны ярата, чөнки, беренчедән, ул башкалардан өлкәнрәк. Гадәттә профтехучилищега сигез класс белем белән керәләр, ә Сажидә урта мәктәпне тәмамлап, унсигезен тутырып килгән. Икенчедән, ул чыннан да күз кунарлык кыз: каратут йөзе сөйкемле, калын кара чәчен баш түбәсенә өеп куя, көнчыгыш кызлары кебек, төз сынын туры тотып, тигез атлап йөри, баш өстенә чүлмәк тулы сөт куйса, чайпалдырмас та иде, мөгаен. Ләкин Сажидә өлкәнлеге белән дә, сәләте белән дә, чибәрлеге белән дә масаймый, үзен бик гади тота. Хәер, ул үзен чибәрләрдән санамый да, чөнки гомере буе сары чәчле, зәңгәр күзле кызларга кызыга иде.

Шулай итеп, февраль аеның аяз көне кичкә авышкан бу минутларда Сажидә бик мавыгып игълан яза иде. Тышкы ишек ягыннан ишетелгән кычкырышуга, шакуга ул бөтенләй колак салмады.

Шау-шуга коридорның аргы башыннан тәрбияче Нәжибә йөгереп килде. Килсә ни күрсен: Идрис, терәү салгандай янтаеп, иңе белән тышкы ишекне тотып тора, ә тыштан берәү бик каты шакый иде.

— Нишлисен? Ач!

Идрис тайпылуга, кинәт ишек ачылды, аннан озын буйлы бер матрос, бескозырка тасмаларын җилфердәтеп, атылып килеп керде, егыла язды. Ләкин шундук тураеп басты, кара бушлат чабуларын ачып, киң хәрәкәт белән бил каешын рәтләп куйды. Диңгез суыдан зәңгәр күзләрен, якорьле пряжкасен, түше тулы значокларын елтыратып сорау бирде.

— Кая Сажидә?

— Сез кем соң? — дип сорады Нәжибә.

Озын буйлы матрос, егерме өчен генә тутырган җыйнак гәүдәле Нәжибәнең бөдрә чәчле башы өстеннән стенага карап:

— Мин — Мансур, — диде.— Ә Сажидә — минем кәләшем.

— Кәләш? Ә син кияүме? — Моны кинәт нечкәргән тавыш белән Идрис әйтте. — Күп йөри монда синең кебек кияүләр!

— Сабыр ит, — диде аңа тәрбияче. Үзе каршыдагы ишекне ачты. — Сажидә!

Матрос, Сажидәне кочагына алырга теләп, кулларын җәйгән иде дә, кыз уңайсызланып чигенде, аллы-гөлле буяуларга тапланган кулын биреп кенә күреште.

Нәжибә, алар кыенсынмасын дип, шунда ук китеп тә барды, ике адымнан матрос-кияүне бөтенләй онытты да. Ләкин кияүнең килүе юкка түгел икән, тәрбияченең эченә ут кабар чаклар алда булган икән. Бер сәгать үттеме-юкмы, Сажидә, аны эзләп, укытучылар бүлмәсенә килеп керде дә, ишек төбенә баскан килеш, кыюсыз гына:

— Нишлим икән, Нәжибә апа, Мансур мине алырга килгән бит, — диде.

— Алырга дисеңме?

— Әйе шул. Алырга килгән...

— Ничек инде... Кил әле утыр.

Сажидә, тәрбиячегә туры карамый гына, Мансурның кемлеген аңлатып бирде. Алар бер авылдан икән. Матрос чыннан да дөресен әйткән, узган җәйне, егет армиядән ялга кайткач, алар вәгъдә бирешкәннәр: Мансур хезмәтен тәмамлап кайткач та өйләнешергә. Инде менә шул вәгъдәне үтәр чак килеп җиткән. Егет кәләшенең, укуын ташлап, авылга кайтуын, аңа кияүгә чыгуын таләп иткән.

— Укып бетергәнче көтсен, — диде Нәжибә. — Күп калмады бит инде. Тагын бер генә ел. Кулыңда һөнәрең булыр.

— Ул көтәргә риза түгел шул. Бүген үк китик, ди.

Нәжибә аптырап китте.

— Соң ул ни әйтмәс. Үзең ни уйлыйсың?

Сажидә башын тагын да түбәнрәк иде.

— Мин вәгъдә биргән идем бит... Ант иткән идем...

— Әгәр ант итмәгән булсаң?

Сажидә тәрбиячесенең күзенә туры карап:

— Укып бетерер идем башта, — диде.

— Бар әйт, монда керсен әле, үзем сөйләшеп карыйм, — диде Нәҗибә бик тәвәккәл кыланып.

Ул көзгегә карап коңгырт чәчен сыйпап куйды, түгәрәк йөзенең бик яшь күренүенә ачуы чыкты — их, бер-ике җыерчык булса шунда, сөйләшә белер иде ул матрос белән!

Ул матросны әле генә Сажидә утырган урындыкка утыртты, егетнең йөзенә чыккан тискәрелеген күрмәмешкә салышып, Сажидәнең искиткеч таланты турында сөйләргә тотынды. Укуын тәмамлап, кулына диплом алгач, Сажидә алтын бәһасенә торырлык һөнәр иясе булачак! Андый осталар бик сирәк очрый, аларны үстерергә кирәк, кадерен белергә кирәк. Гомумән, башында акылы булган кеше үз иркеннән укуын ярты юлда ташлый димени?

Мансур бескозыркасын да салмаган, терсәкләрен киереп, учлары белән тезләренә таянган килеш, тәрәзәдән урамга, җир тетрәтеп үткән куәтле машиналарга карый.

Хәер, урамны күрми ул, Нәҗибәнең сүзен дә юньләп ишетми, үз уй-хисләренә бирелгән.

Гомере буе нык җиргә басып йөргән бу бөдрә чәч аңлый аламы соң өч ел буе дулкыннарда чайкалган матросның хәлен, дип уйлый егет. Күз күременә җәелгән салкын суны, томанлы офыкны, туктаусыз тирбәлгән корабны, шул корабта, сәгатен-минутын санап, кайтыр көннәрен зарыгып көткән авыл малаеның хәлен күз алдына китерә аламы соң ул! Авылын, сөйгәнен, туган йортын төшендә күргән кешенең, кысан кубрикта уянгач, үзәкләре ничек өзелгәнен беләме?

Әйе, Мансур кайту белән гөрләтеп уздырачак туе турында, аннары әй буе Сажидә белән, бер минут аерылышмый, күзгә-күз карашып ял итү турында нәкъ бер ел хыялланды.

Егет уенча, вәгъдә биргән кыз, авылдан беркая чыкмыйча, сөйгәненең кайтканын сабыр гына көтәргә тиеш иде. Сажидәнең кинәт кенә Чаллыга, укырга китеп баруын Мансур вәгъдә бозу, антка хыянәт итү дип аңлады. Аның Сажидәгә язган хатларыннан ялкын бөркелә, очкын чәчри иде.

Ләкин кыз Мансурның сүзен тыңламады, укуын ташламады. Егетнең яну-көюләренә җавап булып, машинкада басылган бер открытка гына килеп төште. Анда: «Сезне Яңа ел белән котлыйбыз. Сеңелегез Сажидә бик яхшы укый. Шундый сәләтле сеңел үстерүегез өчен бөтен училище исеменнән рәхмәт белдерәбез», — дигән сүзләр язылган иде. Бу язу егетнең телгәләнгән бәгыренә тоз сибү белән бер булды. «Сеңел»! Димәк, Сажидә аны яратышкан егете дип танымый! Вәгъдәсеннән баш тартуы, Мансурны мәсхәрәләве шушыдыр! Үзгәрде кыз училищега кергәч, бозылды!

Шул язу аркасында кичергән газаплар өр-яңадан матросның исенә төште, ул хәтта Нәҗибәнең сөйләп бетергәнен дә сизми утырды.

Аннары ачына килеп, кулын бушлат кесәсенә тыкты.

— Сез яздыгызмы моны?

Ул открытка чыгарып, Нәҗибәгә сузды.

— Мин... — Тәрбияче мәсьәләне шунда ук аңлап алды. — Без мондый открыткаларны яхшы укучыларның ата-аналарына җибәргән идек. Сажидә сезнең адресны бирде... Абыем, диде. Яхшы укуын белдереп, сезне сөендермәкче булгандыр... Тик, егетем ул, дип әйтергә кыенсынгандыр...

Матрос аягүрә торып басты — тәрбиячнең күзе турында аның пряжкасе ялтырады.

— Сез, алайса, яңа совет семьясы төзелүгә каршы, — диде ул.— Сажидәне сез котыртасыздыр әле!

Нәҗибә бөтен сабырлыгын җыйды, кызмаска тырышты. Елга якын укыган укучыны, бигрәк тә Сажидә кебек сәләтле, уңган кызны, училищедан җибәрергә һич ярамый иде. Тәрбияче мәсьәләгә икенче яктан килергә булды.

— Иҗтимагый интересларны уйлап карагыз бераз, — диде. — Кешене профтехучилищеда бер ел укыту җәмгыятькә шактый кыйбатка төшә бит. Анысын да исәпкә алырга кирәк.

— Кыйбатка төшә, дисезме?

— Әйе шул. Шуңа күрә безнең укучыбызны җибәрмәскә тулы хокукыбыз бар.

— Сез нәрсә, миннән акча түләтмәкчеме әллә? — Матрос кискен хәрәкәт белән каешын төзәтте.— Кәләш өчен... калым түләтмәкчеме әллә сез миннән?

Нәҗибә ни дияргә белми аптырап калды. Мансур күзләрен дә, иреннәрен дә кысып:

— Ярый, — диде. — Без җәмгыятьне рәнҗетмәбез. Чыгымнарны түләрбез. Күпме түләргә кирәк инде ул... калымны?

Ул шунда ук борылып чыгып та китте. Сажидәне почта бүлегенә барырга ашыктыра башлады:

— Хәзер абыйга телеграмма сугам. Бер дә борчылма, абыйның аңа гына акчасы җитәрлек!

• • •

Ерак Көнчыгыштан алып кайткан гадәтенчә, Мансур бик иртә уянды. Мамык юрган, мамык түшәк дингезченең чыныккан тәнен эссе йомшаклык белән кочып алган, ул идән уртасында ак җәймә генә ябынып яткан хуҗаларга кызыгып карады. Бәхетлеләр! Парлылар! «Бер-ике көннән Сажидә белән без болардан да бәхетлерәк булачакбыз, — дип уйлады Мансур. — Боларның иркенләп яшәргә үз куышы юк. Ә безнең авылдагы өй — хан сарае кебек».

Кичен Сажидә Мансурны монда алып кереп, хуҗалар белән таныштырган иде. Хуҗалар — буяучылыкка укытучы Асия белән аның ире Фәрхад. Күптән түгел генә өйләнешкәннәр. Бу бүлмә — Асия яши торган тулай торак бүлмәсе икән, бирегә яшәүче ике кыз, яңа өйләнешкән парга комачаулмас өчен, кунарга иптәшләре янына киткәннәр. Әнә, аларның караватлары да җыелган килеш тора. Мансурның кунар урыны юклыгын белгәч, Асия аны үз караватына яткырды.

«Без бәхетлерәк булырбыз. Безгә иданнәрдә аунарга туры килмәс. Бүген кичкә абыйдан акча да килеп җитәр...». Мансур, алдагы бәхетле көннәрен уйлап, үзалдына елмаеп куйды. Шунда ул хуҗаларның пыш-пыш сөйләшкәнен ишетте:

— Ашыкма әле, бүген отгул алдым, дигән идең бит, — диде хатын.

— Йокы качты инде барыбер. Виктор бүген күченә, әйбер ташырга чакырган иде.

— Аңа соң булмас әле.

— Вахтадан калмам, дигән идем.

Иртәнге чәйгә утыргач, Фәрхад Мансурның бүгенгә ниятенниндилеген сораштырды, аның кичкә хәтле бер эше дә юклыгын белгәч, үзе белән чакырды:

— Шкаф күтәрешерсең. Яңа шәһәрне күрерсең. Чаллыга килеп, яңа шәһәрне күрми китү синдәй егеткә оят!

Мансурның риза булмый хәле юк иде.

Поселок читендә, бетон мәйданчыкта тезелеп торган автобусларның берсенә кереп утырдылар. Фәрхад кебек үк җылы кара куртка кигән кешеләр автобуска керәләр, әкрен тавыш белән җиңги итеп бер-берсенә сәлам бирәләр.

Менә автобус кузгалды, башта яңа йортлар салынган киң урам буйлап, аннары авыл өйләре тезелгән урамнар буйлап барды, туктап-туктап кешеләр утыртты. Ниһаять, кырга чыгып, тизлекне арттырды, күксел төтен бөркеп, торбаларга уралып утырган бетон заводы яныннан алга, каядыр еракка ашкынды.

— Килеп җиттек!

Автобус аларны юл читендә калдырып китеп барды.

— Менә!

Фәрхад кулы белән киң хәрәкәт ясап, каршындагы гаҗәеп манзарага күрсәтте.

Февраль азагының аяз, җилсез иртәсе иде. Салкынча, әмма күтәрелеп килгән кояшның чамасыз мул яктысыннан, һаваның гадәттән тыш саflыгыннан яз сулышы сизелеп тора иде. Кар ак әле, күзне камаштырырлык ак, әмма инде мамыктай йомшак түгел, баскан саен кетердәп тора. Менә шул язгы күк фонында, шикәрдәй ак кар өстендә ап-ак ташпулатлар тезелеп баскан иде. Бишәр, тугызар катлы йортларның тәрәзәләре, балкон пыялалары күзне чагылдырып ялтырый.

— Моннан өч ел элек, мин килгәндә, монда такыр басу иде, — диде Фәрхад. — Да, малай, мондый калада яшәүнең үз рәхәте бар. Бу йортлар шаһиншаһ сараеннан данлырак. Аларның сурәте чыкмаган гәзит-журнал калмады. Әйдә, карап чык.

Фәрхад ике кулын нык болгап, йортлар арасына юнәлде. Ул бик ыспай гәүдәле, җиңел атлый, яшькелт күзләреннән сирпелгән балаларга хас горурлык аны яшәртә иде. Аннан

калышмас өчен, Мансурга адымып шактый тизләтергә туры килде.

Фәрхад тугыз катлы йортның ишегенә килде дә:

— Безнең резиденция менә шушы, — диде. Ак лифт тавыш-тынсыз гына, әмма зур тизлек белән аларны өскә алып менде.

Резиденция — ялт иткән өч бүлмәле квартир икән — аны вакытлыча гына тулай торак иткәннәр. Фәрхад ишекләрне берәм-берәм ачып карады да:

— Чыгып сызганнар да, — диде. — Сине чәй белән сыйлый алмыйм инде, нәрсәнең кайда ятканын да белмим. Туйдан соң сирәк кайта торган булдым. Ә туйны монда ясаган идек. Менә бу ишекне ачып, ике бүлмәгә өстәлләр тездек, ә бусында биедек. Да, малай, безнең туй бер гаҗәп вакыйга булды. Бер заман загстан кайтып кердек, өй тулы кунак көтә бит инде. Кайтсак, лифт эшләми. Ярый, кулда кодрәт бар чак. Асияне күтәрдем дә тугызынчы катка йөгереп мендем бит. Баскычка үкчәсе дә тимәде. Табын түренә утырдык. Инде караңгы төшкән, кунакларны да күреп булмый, өстәл дә күренми. Шампан кая да, су кая! Электр юк, ут кабызып булмый, көтәбез, шаярышкан булабыз. Караңгыда утыруның үз кызыгы бар, тик озакка киткәч, аның да кызыгы бетә икән. Егетләр чыгып, белеп керделәр: кайдадыр кабель өзелгән, иртәнгәчә ут булмаячак, имеш. Яңа шәһәр, андый хәлләр булгалый. Сизәм: Асиянең бите дымланды. Туй өзелә бит, туй! Нишләргә? Шуннан Виктор минем янга килде дә, хәзер җайлыйбыз, бераз сабыр итегез, дип пышылдады. Цех егетләреннән берничәү чыгып киттеләр болар. Ярты сәгать үттеме-юкмы, дөбер-шатыр кайтып та керделәр. Кочак-кочак шәм күтәргәннәр. Каян тапканнар диген! Тездек өстәлләргә, тәрәзә төпләренә шәм, кабызып җибәрдек бер заман! Шәмнең үз матурлыгы бар икән аның! Ул туй бер әкият кебек, Асия фәрештә кебек булды. Андый туйның Чаллыда бүтән булганы да юк, буласы да юк!

Фәрхад бүлмә уртасындагы балкон ишеген ачып җибәрде:

— Бу өй Мәскәү проекты белән салынган, ә менә мондый балкон Мәскәүдә дә юк, Ленинградта да. Карап кал, матрос!

Балкон астында иркен, ак сахра җәелеп ята, еракта Кама ярлары, елга артындагы күксел урманнар күренә иде.

— Карап кал, син икенче килгәндә бу балконнан урман күренмәс. Бу төшкә ундүртәр катлы йортлар салачаклар. Андый йортны монда өч-дүрт айда торгызып куялар. Ә мин барыбер алдатмам, квартираны кырый йорттан алырмын. Балконнан урман күренеп торуын тели күңел. Асия дә риза.

Асия, Асия... Алар икәү түгел, өчәү йөриләр кебек иде, чөнки Асиянең исеме Фәрхадның теленнән төшмәде. Алар кибеткә кереп — кибетләр шул ук йортларның аскы катындагы квартирларда ачылган икән — әйе, кибеткә кереп, түгәрәк көзге алдылар. «Асияне сөендерим әле»,— диде Фәрхад. Ашханәгә кереп ашадылар. Анда, комбинезон кигән егетләр-кызлар арасында, бушлат кигән Мансур үзен шактый уңайсыз, чит сизде. Ә бит ул бескозырка тасмалары белән кызларның йөрәгенә ут кабызмакчы иде! Фәрхад исә һаман Асияне сөйли. Кухняга кереп, култыгына тагын бер төргәк кыстырып чыкты: «Кишер бу. Кичкә пылау пешерербез. Мин ике ел Урта Азиядә эшләдем бит, пылау пешерергә үзбәкләрдән өйрәндем. Асия ханымны сыйлыйк әле».

Ашханәдән чыгып, автобус тукталышына барганда, Мансур тагын шуларны белде: Асия кичке институтта укый икән. «Бер генә мәсьәләдә уңмады ул, — диде Фәрхад, — укымышлы кияүгә тап булмады. Аның иң куркынычы — минем дипломым булмауда түгел, минем укыйсы килмәүдә. Станокны яратам мин. Тимер кыруның үз ләззәте бар аның». Туганнарына ярдәм иткән Асия, эшләгән, укыган. Егерме яшендә җитеп, егетләр белән чуалмаган... Бу сүзләрне әйткәндә Фәрхадның күңеле нечкәргәндәй, тавышы йомшарып китте. Мансурның көлемсерәвен күреп, ул:

— Мәхәббәт мәсьәләсе уен-муен гына түгел ул,— диде.— Әгәр мин хатынымны яратмасам, әгәр ул уллар-кызлар тапмаса, бу каланы төзүнең кирәге булыр идеме? Бу заводларны салуда мәгънә булыр идеме? Мин шулай аңлыйм: барысы да безнең балалар өчен эшләнә болар. Әнә, күр: заводлар алар!

Еракта офык сызыгыннан калкып озын-озын күксел корылмалар күренә иде.

— Без үзебезнең заводта станоклар куя башладык инде. Мактанып әйтмим, минем эше тимер кортлары алтын бәясенә йөри монда. Ну цех егетләре дә шәп шул. Алар, матрос, туйда гына түгел, эштә дә ут өераләр. Әгәр җитмеш дүртенче елга берәр завод аякка баса алмаса, беренче «КамАЗ» машиналарын үзебезнең заводта гына да ясап чыгарачакбыз, валлаһи!

Кайчак шулай була: көтмәгәндә өеңә чит кеше килеп керә дә, син кинәт кенә үз йортыңны үзең кунак күргәнчә күрәсең, карале, чыннан да минем өй иркен икән, ямьле икән, дип уйлап куясың. Фәрхад та Мансур янында шундый хәл кичерә иде булса кирәк. Офыкта, аксыл рәшәдә тибрәлгән завод корпусларына озак кына карап торгач, тирән итеп көрсенде ул:

— Да, матрос, Сәҗидәгә җиңел булмас. Боларны тиз генә оныта алмас ул. Училищеларын да яңа бинага күчерергә торалар иде; күп сөенечләрдән мәхрүм була кызыкай.

— Ә Сәҗидәнең бу төзелешкә ни катнашы бар?

— Алар практикага йөриләр бит. Ә-ә-нә, теге корпуста шактый күп эшләделәр. Минем Асия синең Сәҗидәне көн дә сөйли. Бер стенаны буяса, мине кат-кат чакырып китерә, «Карале, Асия апа, мин эшләдем бит моны, менә шушы кулларым белән эшләдем бит!» — дип әйтә, ди. Әйе шул, бу каланы да, заводларны да без торгыздык, без бар иттек, без!

* * *

Иртәнге сигезгә эшкә килгән тәрбияче Нәҗибә, ишек төбендә әрле-бирле йөрүче Мансурны күргәч, шактый күңелсезләнде. Ул әле, егетнең нияте үзгәрмәсме, дигән өметтә яши иде. Матросның бик тәвәккәл кыяфәттә икәнен күргәч, тәрбияче тәмам өметен өзде.

Кызыл почмакка керү белән, егет кесәләрен актарырга тотынды, төргәк-төргәк уңлыклар, бишлекләр чыгарып, яшел постауга салды:

— Җитәме шушы? Әллә тагын кирәкме?

Нәҗибә, аягының җегәре киткәнен сизеп, урындыкка утырды.

— Җитәме? — дип кабатлап сорады матрос. — Яңа калада, бөтен бригаданы чакырып, шәмнәр яндырып, ундүртенче катта туй ясарга шул җитәме?

Нәҗибә әле һаман берни аңламыйча, дөресрәге, үз колагына үзе ышанып җитмичә, егетнең диңгез суыдай зәңгәр күзләренә карап, сүзсез утыра иде.

МАНСУРНЫҢ ДУСТЫ.

ИСКӘРМӘ

ТАССР 1920-2020

1972 елның башында «Азат хатын» журналы редакциясе эшче хатын-кызлар һәм профессиональ-техник училище укучылары образын чагылдырган хикәяләргә ябык конкурс игълан итә. Хикәяләр 1972, 1973 ел саннарында басылып бара. Конкурсның жюри әгъзалары Гомәр Бәширов, Туфан Миңнуллин, Фәүзия Илалова, Асия Хәсәнова, Мирсәй Әмир, Марс Шабаев, Нил Юзиев һәр кулъязманы игътибар белән укыганнан соң, йомгаклау утырышында уңышлы хикәяләрне билгеләде. Сез Мәдинә Маликованың «Мансурның дусты» девизы (псевдонимы) белән 1973 елның 8 нче санында басылып чыккан «Тылсым» хикәясе белән таныштыгыз. Ул кызыксындыру премиясенә лаек дип табылды.



Абдулла ДУБИН күпләргә Татарстан телевидениесе дикторы буларак таныш. Без аны сирәк открыткалар җыючы филокартист буларак та беләбез. Аның коллекциясендә хәтта 1896 елда ук чыккан открыткалар бар! Абдулла Дубин – «Иске Идел» һәм «Иске Казан» фотоальбомнары авторы. Соңгысында Казанның XIX гасыр азагы – XX гасыр башындагы күренешләре тупланган. ...Открыткаларга карыйсың да үткәнгә – ул чактагы Казан урамнарына барып чыгасың. Базар-мәйданнарда барган әңгәмәләргә колак саласың, бик якын тоелган тыкрыкларга кереп китәсең, үзеңә бик кадерле булган кешеләрнең кул җылысын саклаган ишек тоткаларына кагыласың. Таныш йөзләр күзгә чалына, таныш моңнар ишетелә... Казан! Безнең Казан!



НЭП чорының шәхси кибетендә төшке чәй вакыты.



Казансуда язгы ташу. Бишбалта бистәсе.



Әбиләрнең эше тыгыз: сату итәсе дә бар, бала-чагага да күз-колак булырга кирәк.



Кремль диварлары янында узучы Ташаяк ярминкәсендә аю биетүче урам артисты.



Печән базарындагы «Обжорка» рәтләре.



Урамнар киселеше: уң якта – Балык рәтләре мәйданы, сулда – Зур Проломная урамы.


Фото: Фирдәвес Исмәгыйлева

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Әтиемнең әтисе Җәлә-летдин улы Шәйхеләхмәт 1879 елда Бондюг районы Песәй авылында туган, ЗАГС материаллары буенча, 80 яшендә дөнья куйган.

Минем хәтеремдә ул бик пөхтә, акыллы, белемле, матур тавышлы булып калган. Ул гел китаплар укыды, намазда булды. Бик бай китапханәсе өйнең бер почмагында үзе ясап куйган шкафларда саклана иде. Ул китаплар белән очрашу һөнәр сайлауга этәргеч биргәндер, үзем Алабуга китапханәчеләр әзерләү техникумын (без укырга кергәндә шулай атала иде, аннан Алабуга мәдәни-агарту училищесына әйләнде) бетердем. Башта китапханәдә, аннан архивта эшләдем. Ялда, үзизоляция вакытында кулга каләм алып хатирәләр яңартырга утырдым. Телевизор күп материаллар бирә: ТНВ каналын карарга яратам. Бер көн шулай Бохара шәһәрен, аның урамнарын, мәчетләрен, безнең замандашларыбызның тормышын тәфсилләп төшерелгән фильм карадым. Бу мине тагын бабам тормышы белән бәйләгән хатирәләргә алып кайтты. Авылда бабайны Шәкерт бабай дип йөртәләр иде, чөнки ул Әгерҗе районында урнашкан Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлый, аннан Бохарага укырга китә. 1911 елда мәдрәсә ябыла, шәкертләрне эзәрлекләү башлана, бабай авылга кайта. Авыл халкы бабайны хөрмәт итә, ул авылда Шәкерт бабай булып, яңа туган балаларга исем кушып, яшь парларга никах укып, авылдашларын җирләргә ярдәм итеп, соңгы көненә кадәр туган нигезендә яши. Бабайның оныклары, туганнары, авыл халкы ярдәме белән Шәйхеләхмәт мәчете төзелде, авыл тагын да ямьләнеп, нурланып китте.

Нәсел шәҗәрәсен барлый башлагач, Иж-Бубый, аның тарихына бәйле яңалыклар белән кызыксына башладым. Берничә ел элек без мәдрәсә тарихы музее урнашкан мәчеттә дә булдык. Үз чорының зур каршылыкларына очраса да, Иж-Бубый мәдрәсәсе тарихын беренчеләрдән булып Мөхәммәт Мәһдиев күтәреп чыкты. Тарихи мәдрәсәдә дин нигезләре белән бергә дөньяви фәннәр: риторика, логика, рус, фарсы телләре, география, ул гына да түгел, матур язу (каллиграфия), физкультура, җыр, рәсем дәресләре укытыла. Мәдрәсәдә рус классиклары Пушкин, Лермонтов, Толстой әсәрләре өйрәнелә. Хатын-кызларга әхлак, гигиена, балалар тәрбиясе, хуҗалык алып бару, кул эшләре кебек дәресләр дә үткәрелә. Ул вакыт өчен Иж-Бубый мәдрәсәсе күпкырлы белем учагы булган. Бабабыз укыган мәдрәсәдә, мәчеттә булу, аның кешеләре белән очрашу, сөйләшү безнең өчен бик кадерле минутлар булып истә калды.

Бабайның уллары Мәхмүт, Мәүҗит, Хәмит Бөек Ватан сугышында катнашалар. Мәхмүт сугышта һәлак була. «Үлемсез полк» хәрәкәте көнне оныклары аның фотосы белән катнашалар. Җиңүнең 75 еллыгына кадәр яши алмаган ветераннар тыныч йокласын. Тормышларыбыз матур, бай булсын, җирдә яшәүнең матурлыгын татып, уңышлы эшләр кылып, истәлекләргә бай эз калдырып, балаларга тапшырырга язсын.

Илгизәр ТИМЕРГАЛИЕВА.
Менделеевск шәһәре.

Исәнмесез, «Сөембикә» журналы хезмәткәрләре!

Мин бик күптәннән сезнең журналны яратып укыйм.

Быелгы март санын кулга алгач, Вәсилә Әсхәдуллинаның язмасына игътибар иттем. Шулхәтле кызыксынып укыдым, нәкъ безне язган кебек тоелды. Без дә – Арча районы Субаш-Аты авылы – гөр килеп яшәп ятабыз. Авылыбыз бик матур урында урнашкан. Якында гына урманы бар, ике яклап елга ага. Элек бик зур булган безнең авыл. Данлыклы урта мәктәбе, ятим балаларны сыендырган балалар йорты, ипи пешерү цехы, татар халкының милли бизәкле читек-чүәкләрен чигү артеле – болар барысы да үткәндә калды инде. Без хәзер алар турында истәлекләрне язып, туплап калдырырга тырышабыз. Клуб мөдире Ләйсән борынгы әйберләрне җыеп музей оештырырга йөри.

Авылдашларыбыз аңа теләп булыша, байтак материал тупланды инде. Хәзерге вакытта башлангыч мәктәп, китапханә, клуб гөрләп эшли. Рүзәл абый асфальт юллар салдырды. Әле дә халык рәхмәт укый үзенә. Авылыбыз таза тормыш белән яши. Бик күңелле вакытларыбыз кышкы чорга туры килә безнең. Бәйрәмнәрне бик матур итеп оештырабыз. Ул ир-егетләребез ясаган, су сибеп катырган хоккей мәйданчыгы гына ни тора?! Урта яшьтәгеләр һәм кечкенәләрдән торган ике командабыз бар. Әти-әниләр ярышлар оештыра, бүләкләрен дә табалар. Коймаклар пешерәләр, чәйләр кайнаталар. Ул көн чын бәйрәмгә әйләнә! Егетләребезнең даннары еракларга таралган. Ярышларда алар һәрвакыт беренче. Барысы да үзебез һәм читтә яшәүче дусларыбыз хисабына башкарыла. Көрәш белән дә, шашка-шахмат белән дә шөгыльләнә яшьләребез. Хатын-кызларыбыз да тик ятмый. Үзем дә балалар, әти-әниләр белән эшләргә яратам. Бергәләп Туфан Миңнуллинның «Алты кызга бер кияү» әсәрен сәхнәләштердек. Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышлап куелган спектакльдә катнаштык.

Аякта йөри алган барлык кеше кичен гел хәрәкәттә була Субаш-Атыда. Олы апаларыбыз урамда йөри, ә безнең ише урта яшьтәгеләр рәхәтләнеп тау шуа. Андагы күңеллелек! Ә иң күңеллесе – авылдашлар белән бергәләп Казанга төрле концерт-театрларга бару. Көне буе Казанның истәлекле урыннарында булып, театр карап, ял итеп кайтабыз. Балалар белән бергәләп Кырлайдагы Тукай музеена да автобуста күңелле сәяхәт оештырабыз. Зиратларда, авылда өмәләр үткәрелә. Бу эшләрне авылыбыз мулласы башлап йөри.

Мин язганнарның барысы да 70 ләп хуҗалыгы булган Субаш-Аты авылында булган вакыйгалар. Вәсилә Әсхәдуллина язган Ядегәр авылы зурдыр ул. Алар белән бергәләшеп чана бәйрәме уздыру турында хыялланабыз инде без хәзер. Бәлки, хыялыбыз чынга ашар әле, Алла боерса!

Фәридә НИГЪМӘТҖАНОВА.
Арча районы Субаш-Аты авылы.

1979 елның кояшлы, матур май аенда Казан автовокзалыннан Балык Бистәсенә кайтучы автобуска 70-75 яшьләр тирәсендәге бабай кереп утыра.

Ул юл буе тәрәзәдән күзләрен дә алмый тирән уйларга чумып бара. Нәрсәдер исенә төшкән кебек яшь аралаш елмаеп та ала. Бабайның үзен сәер тотуын күреп, янындагы юлдашы сүз катып караса да, ул юл буе беркем белән дә сөйләшми, аратирә битеннән тәгәрәгән яшьләрен генә сөрткәләп кайта. Кече Елга авылына җиткәч, бабай шофердан автобусны туктатуны сорый. Автобустан төшүгә җиргә ятып, сабый баладай үкси-үкси елап туфракны үбә башлый. Автобустагы халык моны хәйран калып күзәтә. Бабай бер уч туфракны кулъяулыгына төреп кесәсенә салып куя да яңадан автобуска утыра. Аннан яшь аралаш телгә килеп: «Биредә кечеелгалылар юкмы?» – дип сорый. Тик автобуста бу авыл кешеләре булмый. Шуннан соң бабай үзенең Балык Бистәсе районындагы туган авылына кайтып баруын, сугыш вакытында фашистларга әсирлеккә төшүен, сугыш беткәч, Сталинның каты карарын Германиядә үк ишетеп, әсирлектә булган солдатларны, аларның гаиләләрен, балаларын биредә үлем җәзасы көтүен хәбәр итүләрен сөйли. Ә инде бу бер уч туфракны үзе кебек әсирлектә калып, туганнарын, балаларын бер күрергә тилмереп, сагынып гомер итүче туганыбыз Шиһабетдин абыйның гозере буенча алуын сөйли. «Каберемә сибәргә бер уч туган як туфрагын алып кил», – дип, дустына үтенечен әйткән була ул.

Автобустагы бу вакыйгага шаһит булган хатын – Масловка авылыннан әтиемнең яхшы танышы булып чыга. Беркөнне иртән безгә килеп керде ул. Өйдә әти белән икәү генә идек. «Сезнең авылда сугышка киткән Шиһабетдин исемле кеше бармы?» – дип сорады. Әтием: «Әйе, син каян беләсең, миңа туган тиешле абый ул», – дип җавап бирде. Масловка апасы үзенең автобуста күргәннәрен, ишеткәннәрен түкми-чәчми безгә сөйләде. Биредә калган хатынының, балаларының да исемнәрен әйтте. Без әти белән бу тарихны елый-елый тыңладык. Масловка апасы чыгып киткәч, балачаклары куркыныч Сталин репрессиясенә эләккән, юк кына сәбәп өчен дә төрмәгә утырткан елларны күреп үскән әтиебез нигәдер куркып калды. «Кызым, бу хәбәрне бүген ишеттең, бүген оныт», – диде. Бу вакыйга 40 ел инде йөрәгемне тырнады, туганнарына да сөйли алмадым, әтигә биргән вәгъдәмне дә боза алмадым. Авылга кайтып, Шиһабетдин абыйның улы Нуретдин абыйны, якыннарын күргәндә минем күз алдыма гел шул күренеш искә төшә иде.

Әсирлектән котылгач, чит илдә яшәп калган ватандашларыма, кулсыз, аяксыз гарипләнеп кайткан солдатларга караганда да аянычлырак, үкенечлерәк гомер насыйп булган икән. Алар бит Германиянең матур табигатенә, чибәр кызларына алданып калмаган. Гаиләләрен, балаларын үлем кочагыннан коткарып, үзләрен шундый язмышка корбан иткәннәр. «Адәм баласын ашыйсы ризык, эчәсе су йөртә», диелгән бер хәдистә. Бу туганымның да ашыйсы ризыклары читтә булганмы? Балаларына ятимлек ачысы, хатынына толлык әҗере, михнәтле тормыш авырлыгын татырга язганмы? Җавап табып булмый, ул бары тик бер Аллаһы Тәгаләгә генә билгеле.

Бала күңеле сизгән, күрәмсең. Нуретдин абыйга күп еллар үткәч кенә серемне ачтым. Елмаеп тыңлап торды да: «Әй сеңлем, мин әтиемнең исән икәнен гел тоеп яшәдем. Авыр мизгелләремдә гел төшемә керде. 1987 елның февраль аенда соңгы тапкыр әтиемне төшемдә күрдем. Онытмыйм туасы көннәр иде ул. Әтием, кулыма бала арбасы китереп тоттырды да, вакытым юк, ашыгам – мәңгелеккә китәм инде, дип китеп барды. Йокымнан уянып киттем дә, менә бүген әти үлде, дигән нәтиҗә ясадым», – дип сөйләде Нуретдин абый әтисе турында...

Гәүһәрия ВӘЛИУЛЛИНА-ЗАРИПОВА.
Лаеш районы, Кече Елга авылы.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA



МИН ГАЕПЛЕ, КЫЗЫМ...

«Елмаюына, «ыг-гы, ыг-гы» килүенә эреп утырам. Бу могҗиза чыннан да минекеме дип. Һәм яшәвемнең төп мәгънәсен дә аңлый башладым кебек. Шул аңлаудан рәхәт дулкын йөгерә. Ашыкмыйча иркәләнеп, кочаклашып утырырга вакыт та, мөмкинлек тә бар. Һәм сиңа беркем дә бер сүз әйтмәячәк. Тормыш тәгәрмәче акрынайган рәхәт чор». Асылъярга икенче хат әнә шулай башланган иде. Ләкин аны дәвам итәргә язмаган икән...

Гүзәл СӘГЫЙТОВА

Барысы да дүрт ай дигәндә үзгәрде. Миңа эш тәкъдим иттеләр. Һәм гади эш түгел: яшьләр театрын җитәкләргә. Өч ел буе декрет ялында бала үстерүнең бөтен тәмен татырмын дигән ниятем күз алдында көннән-көн ныклыгын югалта башлады. «Мондый вазыйфадан бер баш тартсаң, башка андый тәкъдимнәр булмас», «Бу бит Асылъярның киләчәге дә», «Кызым, балаңны карашырга ярдәм итәрбез» – якыннарымның сүзләре «әйе», «әйе» дип сикеренгән күңелгә ак ипи өстенә май яккан кебек иде. Башкортстан әбиең генә: «Кирәкмәс, үзеңне жәллә, балаңны жәллә, «кырык»ка җитеп бала таптың, кадерләп үстер», – дип, бүгенгә кадәр тәкрарлый.

Кыскасы, бу тәкъдимне алганда сиңа ике ай гына иде әле. Дүрт ай ярым булганда эшкә чыктым. Бу адымның ни дәрәҗәдә тәвәккәл булуын син үз балаларың тугач кына аңларсың, кызым. Хәзерге көн биеклегеннән торып, бу уңайдан мин сиңа бер киңәш тә бирә алмыйм. Вакыт үзе күрсәтер. Эшемне бик яратам, андагы мохитне... Әмма синең белән саубуллашканда яисә сине искә төшергәндә күзләр дымланмый калмый... Узган ел шундый авыр, мәшәкатьле үтте. Театр юбилее, премьералар, яңа проектлар, грантлар язу, ниндидер конфликтларны чишү, Башкортстанга гастрольләр, «Калеб» эшчәнлеге; шул ук вакытта йокысыз төннәр, өй җыю, юу, әтиең кайтуына, икенче көнне дәү әниең килүенә ашарга әзерләү – болар барысы да бүген төш кебек кенә. Әнә шундый мәшәкатьләр белән 1 яшеңә җиткәнеңне абайламый да калдым. Сиңа һәр ел язарга вәгъдә иткән хатымны да яза алмадым, дусларымның балалары тугач, үзем яратып бүләк итә торган «Бәбиләр» фотоальбомын да тутыра алмадым, хәтта аны сатып алырга да вакыт табылмады, фотога төшәргә дип икебезгә бертөрле тектерелгән күлмәгең дә инде кечкенә... Дөрес, өйдә вакыты иркен кайбер әниләр дә боларны эшләмәскә мөмкин, ләкин мин башка булырга тиеш идем...

Гаеп хисе. Моннан да авыррак нәрсә бармы икән? Бигрәк тә бүген балалар тәрбияләүдә кызыклы китаплар, вебинарлар белән дөнья тулганда, Монтессори методикалары колач җәйгән, социаль челтәрнең һәр битендә диярлек бер яшьтән үк дөрес туклану турында язганда, бала вакыттан ук лидер тәрбияләү белән бәйле марафоннар уздырылганда... Син, бары син генә үз балаңны, бербөртегеңне боларның барысыннан да мәхрүм итәсең кебек... Ярый, алдынгы методикалар бер кырыйда торсын, хәтта бала өчен иң кирәкле булган ана назыннан, ана җылысыннан да...

Дөрес, бер ай тулганчы эшкә чыккан аналар бар. Америкада исә урынын югалтасы килмәгән барлык яшь әниләр дә ике айдан соң эшләренә кайта, алар өчен күкрәк сөтен саварга аерым бүлмә, сөтне сакларга суыткычлар көйләнгән, ди. Француз хатыннары исә бала тапкач та эшкә чыгарга үзләре үк ашкына икән, шулай да өч айга кадәр гәүдәләренең элекке формага кайтуын көтәләр. Франциядә алар эшкә чыксын өчен бөтен мөмкинлекләр дә булдырылган: нянялар яллаган өчен акчаны дәүләт түли, профессионал тәрбиячеләр белән яслеләрне тулы режимда эшләтә. Бу дәүләт өчен отышлы.

Америкада яшәүче ханымнар исә гаеп хисе белән гармониядә яшәү чарасын тапкан: «Мин – начар әни» – алардагы әниләр авызыннан иң еш чыга торган гыйбарә икән. Әлеге сүзләр психологик яктан ана кешегә җиңеллек бирә дигән фикер бар. Бу турыда кычкырып әйткәч, гаеп хисе, үз-үзеңне ашау юкка чыга, имеш.

Мин – начар әни. Белмим, минем моны икърар итәсем килми. Әле һаман да керләреңне махсус порошок белән үзебезнекеннән аерып юам, киемнәреңне тыштан да, эчтән дә үтүклим, шешәләреңне кайнатам. Арабыздагы якынлыкны, бәйләнешне саклар өчен һаман да бергә йоклыйбыз. Әтиең белән икебез дә

Фото: Анна Арахамия

PRESSA

Социологик тикшеренүләр шуны исбатлаган: хатын-кыз иртә эшкә чыккан гаиләләрдә аерылышулар сирәк була икән.

бик күп эшләсәк тә (ул ике эштә эшли), синең турыда гел кайгыртып торабыз: ашаганмы, Д витаминын эчкәнме – һавада йөргәнме? Бала караучыга калдырганда да салкын акыл белән эш итмәдек без. Беренче елны сине дәү әниең карады: ул ризалашмаса, чит-ят кешегә мәңге калдырып чыгасы түгел идек. Дәү әниең сигез ай буе шәһәрнең бер читеннән икенчесенә, берничә транспортка күчеп утыра-утыра йөреп, сине карады. Ул вакытта әтиең, дәү әнине ял иттерер өчен, ялын махсус атна уртасына күчерде. Көннәрнең берендә, синең белән урамда йөргәндә, дәү әниең егылып кулын сындырды. Бер кич эчендә без сиңа няня табарга мәҗбүр булдык. Сине көн буена чит кеше кулына калдыру, өйгә чит кеше кертү өчен күңелдәге тышауларны тиз чишәргә туры килде. Уйларга вакыт юк иде. Барлык кандидатуралар арасыннан Елена гына синең турында сораштырды, синең белән кызыксынды. Күңелем аны сайлады. Әйе, әйе, рус милләтеннән булган бала каручы сайлады Гүзәл Сәгыйтова үзенең кызына. Чөнки бу очракта минем өчен тел түгел, аның нинди кеше булуы әһәмиятлерәк иде. Елена инде бер елга якын безнең белән. Дәү әниең белән кебек үк: бу ел эчендә бер сүзгә дә килмәдек. Яңа ел алдыннан: «Башка эшләмим, сәламәтлегем начарлана башлады», – дисә дә, сине балалар бакчасына биреп, өч-дүрт тапкыр чирләткәч, жәлләп, янәдән яныңа йөри башлады. Без бу вакыйгадан соң тагын да якынайдык. «Асылъяр төшкә керде, кич буе Асылъярны искә төшердем», дигән сүзләре күңелемә нинди рәхәтлек биргәнен белсәң икән, кызым! Дөрес, ике ай азмы-күпме балалар бакчасына йөргәндә, бала караучыга кабаттан ияләшкәндә, син миннән берничек тә аерылырга теләмәдең. Иртәләрен яртышар сәгать сине сыйпап-назлап утыра идем. Нинди генә юату сүзләре пышылдамаганмындыр... Шулай пышылдыйм-пышылдыйм да, күзләргә яшь килә. «Әни куенында рәхәтләнеп утырыр чагың бит, кызым», – дип елаганнарым аз булмады. Бер яшең тулгач җайлырак булыр дип уйлап ялгышканмын. Физик планда – әйе. Ләкин рухи яктан бәйләнеш көннән-көн ныгый икән. Һәм аерылып китү газапка әверелә... «Бәхетле бул, балам! Бәхетле генә бул! Шушы кечкенәдән кичергән сынауларың сиңа бәхет булып икеләтә-өчләтә кайтсын иде! Киләчәгең дә, холкың да әнә шул китүләрдән сынмасын иде». Яшь ярымга кадәр баланы анасыннан аерырга ярамый, ул курку-комплекслар булып урнаша дип тукып торганда, әлбәттә, бик күп уйланасың. Киләчәктә нindидер эчке киеренкелекләр булырмы, алар өчен мине гаепләрсеңме – төнлә синең елавыңа уянам да шул турыда уйлап ятам. Мин бернәрсә дә белмим, кызым, каралама язып, төзәтеп, аннан акка күчерергә вакыт юк. Ялгышларыбыз да, табышларыбыз да нәкъ менә хәзер языла. Син – беренче бала, беренче тәҗрибә, бәлки, бердәнбердер дә...

Мин, нишләптер, үземнең балам булмас дип уйлый идем. Яшь чакларда, 20–30 яшьләрдә. Бала шундый зур бәхет (аның мәгънәсен шул вакытта ук аңлый идем), миңа Ходай андый зур бәхетне бүләк итмәс кебек иде... Хәзер инде ул вакытларны искә төшереп елмаям. Син – бар, син – чын. Һәм бөтен нәрсә шундый табигый кебек. Сине тотып була, сөеп, иркәләп, шелтәләп, хәтта әрләп була... «Балама беркайчан авыр сүз әйтмәм» дигән сүзләр дә онытыла икән. Ару, нәрсәгәдер ярсу – барысы да сиңа мөнәсәбәтләрдә чагыла. Гафу ит, кызым. Еш кына синең белән булып та, синең янда булмавым өчен дә гафу ит, балам! Әйе, без, әти-әниләр, баланың Ходай бүләге булуын, аның кадерен шулкадәр тиз онытабыз. Югыйсә һәр минутның кадерен бел дә бит... Икенче яктан, баланы артык сөяргә, Ходайдан да ныграк зурларга ярамый, диләр. Гел өф-өф итеп 3-4 яшькә кадәр ана куенында утырган балалар мөстәкыйль тормышка әзер булмый дигән фикер дә бар. Бәлки, хәерлеседер. Кем белгән инде...

Тиздән сиңа 2 яшь тула. Бер караганда, бу ике ел күз ачып йомганчы, шул ук вакытта бик озак узган кебек. Бу вакыт аралыгында ничек кенә үзгәрмәдең син, әле синең хакта «үз сүзен өскә чыгарырга тырышкан көйсезрәк кыз» дияргә мөмкин. Кучкарлыгың чагыламы, 2 яшь кризисымы, әллә үз-үзеңне яклау ысулымы (әниләрен еш күрмәгән балаларда ул сыйфат булырга мөмкин икән)?! Үзгәрерсең әле, чын күңелдән ышанабыз. Ничек кенә булмасын, бу ике ел «Тормышның мәгънәсе нидә?» дип, элек борчыган сорауларымны юкка чыгарды, дөньяны ак һәм кара төсләрдән төрле төслегә әйләндерде, вакыт төшенчәсенең кадерен арттырды, «үземнеке»нең чикләрен билгеләде. Рәхмәт сиңа, кызым! Иң соры көнне дә иң бәхетле кеше кебек елмаеп уянуың, кечкенә генә кулларың белән бөтен дөньяны колачларга теләвең, төгәл яңгырамаган беренче сүзләрең, берничә секундта йөзләреңне әллә ничә үзгәртеп артистлануың, хәтта киреләнүең дә миңа яшәү көче бирә! «Бу дөньяда синсез күпме гомер, / Ничек кенә, ничек түзгәнмен?!» Резеда апаң Гобәеваның бу шигыре синле халәтемә шундый туры килә! Әйе, ничек түзгәнмен...

...2 яшең көнне зур вакыйга – филармониядә «Калеб» оештырган «Безнең җыр» концерты, аңа кадәр исә театрның Мәскәүгә гастрольләре булырга тиеш иде... Ләкин бөтен Җир шарында коронавирус галәмәте башланды, һәм күпме әзерлекләр юкка чыкты... Карантин игълан ителмәсә, син бу көннәрдә әниеңне бөтенләй күрмәс идең... Һәм, бәлки, бу хатны да... Бернәрсә дә очраклы түгел. Барысы да яхшыга, кызым! Барысы да яхшыга! Тормышыңда нинди генә кыенлыклар, авырлыклар булса да, әнә шуңа өметлән, ышан, инан, балам!

ТАТ МЕДИА

ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР

Язылган өчен мотоблок, ТВ, планшет һәм башка бүләкләр от!



Бүләкләр 2020 елның 19 августында уйнатылачак

1 язык
2020 елның 30 июненә кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең газета һәм журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 җибәр
«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең күчермәсен безгә җибәр (телефон номерын язарга онытма). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 от
Язылган өчен мотоблок, телевизор, планшет, тузансуырткыч, 100 л бензин, блендер, үтүк от

Тулырак мәгълүматны, акциянең узу вакытын, бүләкләр, аларны алу тәртибен tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 2020 елның 12 маеннан 2020 елның 20 сентябренә кадәр үткәрелә. Гаризалар 2020 елның 20 июленә кадәр кабул ителә. Оештыручы – ТАТМЕДИА» АҖ. Бүләкләр рәсемдә күрсәтелгәннән үзгә булырга мөмкин. Реклама 16+





«Сөембикә» редакциясе дә журналга язылучылар арасында бүләкләр – көнкүреш товарлары уйната: блендер – 2 данә; сэндвич-тостер – 2 данә; кухня үлчәве – 2 данә.
Алдагы ярты елга журналга язылу турындагы квитанция күчермәсен, телефон номерыгызны да күрсәтеп, 20 майдан 15 июльгә кадәр редакциягә яки электрон почтабызга юллагыз: ssuum@yandex.ru Җиңүчеләр 20 июль көнне билгеләнәчәк. Аларның исемнәрен сайттан яки журналның август санынннан укып белерсез.
Акциянең нигезләмәсе белән сайттан тулырак таныша аласыз: www.syuyumbike.ru Реклама 16+

«ХАТЫННЫ... ӘТИСЕНӘ КАРАП САЙЛА»



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

Илнур МИРГАЛИЕВ, ТР Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге институтның Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты. Гаилә стажы – 17 ел; Өч бала атасы.

1 Иң элек хатын-кызның сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Буй-сынына, киеменә... Хәер, барысына да! Ә хатынымның, мөгаен, иң элек озын чәчләренә күзем төшкәндер.

2 Нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хатыныңа кагылса, әлбәттә, хыянәттер. Ир-атлар, гадәттә, күбесе бу адымны гафу итми. Хәер, кичерүчеләр дә бар. Туганнар арасында андый бер очрак булды. Әмма ул ирнең бу карары безнең арада аңлау тапмады: ир-атлар гына түгел, хатын-кызларның да мөнәсәбәте шундый иде. Матур күренеш булмагач, кабул ителмәгәндер инде... Үзеңә, синең якыннарыңа килеп кагылгач, бу мәсьәләгә башкача карыйсың икән. Менә син әни кеше ди. Киленең хыянәт итсә, нинди позициягә басарсың? «Улым, оныт, гафу ит», – диярсеңме, әллә башка киңәш бирерсеңме? Безнең халык хыянәт дигән сүз чыккан җирдә гомер-гомергә артык кискен, кырыс булган. Европалылар, мәсәлән, аны дөнья беткән кебек итеп кабул итмәскә дә мөмкиннәр. Хатын-кыз хыянәтне күп вакыт кичерә, диләр. Элек, бәлки, шулай булгандыр, хәзер алар да кичерми, шуңа күрә аерылышулар күп тә инде.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Яшьрәк чакта җавап башкача яңгырар иде, мөгаен. Ә кушылып бергә яши башлагач, гаилә коргач, балалар тугач «комфорт тудыручы» беренче урынга чыга.
Ярату китә дигән сүз түгел бу, башка төсмерләр генә ала. Аның икенче планга күчүе, бәлки, дөрестер дә. Чөнки мәхәббәт бик эгоистик хис, ул гел үзенә каршы җавап көтә. «Мин сиңа гашыйк булдым, син минеке генә бул» дип таләп итә, елый, ялвара ул... Шуның аркасында фаҗигаләр килеп чыга, кемдер үз-үзенә кул салуга кадәр барып җитә... Хисләрнең иң зурысы мәхәббәт, диләр, килешмим.
Ул бик зур хис, әмма икенче урында тора. Беренче урында – мәрхәмәт хисе. Әйтик, баланы ярату – ул мәрхәмәт. Каршы җавап көтмичә дә яратасың бит баланы, үзеңне тулысынча аңа бирәсең. Бигрәк тә әниләр.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әлбәттә, була ала. Һәм булырга тиеш тә. Коръәндә Аллаһы Тәгалә «мин сезне бер-берегезгә кием кебек яралттым», ди. Кием – сиңа иң якыны, димәк, ир белән хатын да шулай. Кием кебек бер-береңне төрле борчулардан каплыйсың, бергә киләчәккә планнар корасың, ике яктагы туганнарга карата бергә билгеле бер сәясәт алып барасың, балалар белән туган сорауларны хәл итәсең... Дус булмасаң, боларның берсен дә эшләү мөмкин түгел.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Мин соң өйләндем, 27 яшь иде инде. Башта – университет, аннан аспирантура тәмамладым, диссертация якладым, эшкә урнаштым... Кыскасы, башта карьера ясадым. *(Көлә.)* Студент чакта тирә-юнеңдә кызлар бик күп була, аспирант вакытта да шулай әле ул. Аннан карыйсың – янәшәңдә инде берсе дә юк, барысы да кияүгә чыгып беткән. Нишләргә дигән урынлы сорау туа. Мин үзем борынгыдан килгән гореф-гадәтләребезгә мөрәҗәгать иттем – дусларымнан, аларның хатыннарыннан яучы ясадым. Булачак кәләшемдә күрергә теләгән критерийларны әйттем. Гомумән, билгеле бер яшькә җиткәч, ир-атка бөтен яктан тәкъдимнәр ява башлый икән ул. Әни, апалар – барысы да бәйләнә: өйлән дә өйлән. Хәтта вакытын билгелиләр: быел син башлы-күзле булырга тиеш, диләр. Синең белән шушы темага җитди сөйләшүләр башлана. Инде үзең дә аңлыйсың – башка сузарга ярамый... Критерийларны әйттем дидем. 27 яшьтә сиңа инде акыл утырган, тормышка караш башка. Зифа буй-сын дигәнмендер инде. Хәер, яшь чакта кызлар барысы да стандарт шикелле матур була инде алар. Тулы гаиләдән булсын, дидем. Яшь барган саен, моны ныграк аңлыйм: тулы гаилә күреп үскән кыз бала гаилә учагын ныграк саклаячак. Татарча белүе дә мөһим иде. Дингә якынлыгы, дингә хөрмәте булу да. Миңа кадәр егетләр янында үзен иркен тотмаган булуы да. (Коръәни-Кәримдә чиста кешегә генә чиста кеше бирелә диелә.

Мондый таләп куям икән, мин үзем дә шуңа туры килергә тиеш идем. Моңа кадәр берәүгә дә күңелемне ачмый торуым шуңа булгандыр. Яшь чакта игътибар тойганда да юкка гына күрмәмешкә салышып узылмагандыр: өйләнергә әле иртә икәнен аңлыйсың, алай-болай очрашып йөрергә исә теләмисең.)

Ярты ел очрашып йөргәннән соң, Диләрә белән яраштек. Бер-береңне ачу өчен күпмедер вакыт кирәк бит... Әнигә дә, апаларга: «Фикерегезне хәзер әйтегез, ошамаса хәзер үк белгертегез, юк дисәгез, аңлармын. Әмма «әйе» дип әйтәсез икән, соңыннан аның турында бер начар сүз дә, тәнкыйть тә, безнең тормышка кысылу, киңәшләр бирү дә булырга тиеш түгел», – дидем. Үтиләр!

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр, шулаймы?

– Юк, миндә андый хис булмады. «Әнисенә карап кызын коч», дип әйтү бар инде ул татарда. Әмма фән буенча, дөресе – әтисенә карап сайлау. Соңгы тикшерүләр дә шуны күрсәтә: синең балаң хатыныңның әтисенә охшаячак. Кешедә ике төрле холык һәм мөмкинлекләр бар: берсе – туганнан бирелә, икенче тәрбия белән керә. Табигатьтән бирелгәнен күпме тырышсаң да, үзгәртеп булмаячак.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Ир-ат өчен бу бигрәк тә психологик яктан авырдыр. Өстәвенә, хатыны: «Мин табам!» – дип кабатлап торса... Элеккегеләр юкка гына: «Тормыш юлдашы итеп үзеңә тиң кешене сайларга кирәк», – дип әйтмәгән. Соңыннан проблемалар килеп чыкмасын өчен шулай дигән бит алар. Проблема туса, гаилә җимерелергә, балалар ятим калырга да мөмкин... Бу ситуациянең авыр икәне белән килешәм, әмма ирнең үзен ничек тотарга тиешлеген белмим. Барысы да ике якның моңарчы үзара ни дәрәҗәдә аңлашып яшәвенә бәйледер.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Ә ул гел үзе белгертә дә! Студент елларыннан да шулай истә калган, башка тәҗрибәләр дә шуны күрсәтә. Һәм ул дөрес тә. Ялгызлык, гомумән, зур шәһәрләрнең иң зур проблемасы инде ул хәзер. Яшьләр бер-берсе белән таныша алмый, бер-берсен эзли белми. Шундый шартларда бер-береңә хисеңне белдерергә мөмкинлек бар икән, нигә кулланмаска? Каршы яктан җавап ала алсаң – тагын да әйбәт. Әмма тыйнак рәвештә белдерелергә тиеш инде, әлбәттә. Минә ни өчен бүгенге җәмгыятьтә яучылар институты эшләргә тиеш тә. Ул бар барын, әмма мин аның тагын да көчлерәк эшләвен телләр идем.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Үз-үзен тотышыдыр дип уйлыйм. Психологлар 70 нче, 80 нче, хәтта 90 нчы елларның башын «бөек харрасмент чоры» дип атый. Бу хакта бездә бик ачылып сөйләмәсәләр дә, мемуарлардан укып беләбез: эш урынында хатын-кызга бәйләнү, андый тәкъдимнәр ясау бик киң таралган булган. Хәзер җәмгыять үзгәрде, әмма ул чор кешеләре әле безнең арада – аларны хатын-кыз янында үз-үзләрен тотышыннан тиз танныйсың. Әмма бүгенге хатын-кызлар мондый мөнәсәбәтне инде кабул итми.

Гомер итәр өчен исә бүгенгеләр үз-үзенә ышанган, акыллы, перспективалы егетләрне эзлидер. Зур мәгънәдә Кеше булган көчле ир-атларны. Тормыш иткәндә барысы да мөһим: өй дә, машина булу да. Ул якны да ир кайгыртырга – болар артында җаваплы кеше күренеп торырга тиеш. Җавапсыз икән, ул тугры да, рәхмәтле дә булмый: нинди генә очракта да башкаларны гаепли. Ә җаваплы кеше гаебен таный, йөкнең авыр өлешен үз өстенә ала белә. Уңышсызлыкларда туктап калмый.

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Бу сыйфатларның икесен янәшә кую дөрес тә түгелдер. Эшләгән җирендә көчле, яхшы профессионаллар бар – андыйлар сокландыра гына. Тагын ирдәүкәләр бар әле. Болары рухи гына түгел, физик яктан да көчлеләр. Андыйлардан, гомумән, ерак торуың хәерлерәк.

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Үзе сайлаган обойны өч тапкыр кибеткә кире илтеп тапшырткан чаклары бар инде... Тик мин андый нәрсәләргә бөтенләй кысылмаска тырышам: пәрдә, обой, мебель... Диванның төсе паласка, паласныкы тәрәзә пәрдәсенә туры килү-килмәвен хатын-кыз үзе генә хәл итә аладыр. Ир-ат болардан ерак инде ул. Һәрхәлдә, мин ерак.

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный...

– Ютубта, бәлки, күргәнегез дә бардыр: мөселман илләрендә кайберәүләр, кабер казып, шул кабергә төшеп ятып карый хәзер. Аннан чыккач, инде күп нәрсәгә башка күз белән карыйсың... Теләсә нинди проблеманы чишкәндә приоритетларны дөрес кую кирәк. Гаиләдә дә шулай. Никахыгыз, балаларыгыз киләчәгенә кагыла икән, андый сорауларны, әлбәттә, уртага салып хәл итү, ә көнкүрештәгеләрен юл куеп, уен-көлке белән уздырып җибәрү дөресрәк. Тормышта шундый очраклар бар: хатын иреннән аерыла. Авырлык белән гомер итә. Азакта: «Шул чакта бергә яшәп калырга акыл җитмәгән», – ди. Кызганыч, безнең җәмгыятьтә берәүне дә гаилә корырга махсус әзерләмиләр – андый институт юк. Нинди генә һөнәр буенча эшләргә теләсәң дә, башта укыйсың, диплом аласың. Бер карасаң, гаилә дә эш бит – монда да әзерлек, проблемалар килеп чыкмасын өчен профилактика чаралары кирәк. Ә аның өчен белемле булу сорала!

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Әйе, андый хәл бик булырга мөмкин. Диванда кырын яту түгел, ашарга әзер түгел чаклар дим. Хатыным укытучы, аның эштән миннән соңрак кайткан чаклары, әлбәттә, булгалый. Көтеп торган юк – үзем пешерергә тотынам. Минеке алай тәмле килеп чыкмый, билгеле... Савыт-саба юарга да яратам – аның авырлыгы юк бит.



Начар уку, тиз кызып китү, бернәрсә дә эшләргә теләмәү – боларга начар тәрбия яки көйсез холык кына гаепле микән? Ә бәлки, сәбәп бөтенләй башкададыр? Бәлки, аның организмында йод кытлыгыдыр? Республика балалар клиник хастаханәсенең Сәламәтлек үзәге мөдире, югары категорияле балалар табибы Гүзәл ЯРУЛЛИНА белән сүзебез әнә шул хакта булыр.

ЙОД КЫТЛЫГЫ

Йод – кешенең нормаль тереклеге өчен мөһим микроэлементларның берсе. Ул ризыкның үзләштерелеше, акыл эшчәнлеге, физик ныклык, иммунитетның бактерияләр һәм вирусларга каршы көрәшүе өчен җаваплы. Әлеге микроэлемент тиешле күләмдә булса гына энергиябез дә бар, нерв системабыз да тотрыклы, юкка борчылмыйбыз да. Ә йод җитешмәсә?..

Баланың начар укуын, игътибарсызлыгын, холыксызлыгын, тиз аруын күп очракта шәхси сыйфатларына гына сылтап калдырабыз. Әлеге проблемаларның нигезендә организмда йод җитмәү дә булырга мөмкин. Йод кытлыгы озакка китсә, тагын да җитдирәк үзгәрешләр килеп чыгуы ихтимал.

Профилактика чаралары

Йод кытлыгын булдырмас өчен, табиб киңәше белән балага составында йод булган препаратлар бирергә мөмкин. Профилактика максатында яңа туган балаларга ул тәүлегенә 50 мкг (таблицаны карагыз) микъдарында кирәк. Ә менә организмда йод кытлыгы белән барлыкка килгән үзгәрешләрне дәвалау өчен доза арттырыла. Әлеге микроэлементның дарухаләрдә ирекле сатылучы поливитаминнар составында булуын да онытмагыз.

Организмда йод кытлыгын булдырмас өчен, бала рационында йодка бай ризыклар күбрәк булсын. Шуны да истән чыгармагыз: әлеге микроэлемент тиз таркалучан. Пешергән вакытта ризыктагы йодның 30–50 проценты, кыздырганда 70 процентка якыны юкка чыга. Иң яхшысы – ризыкны парда пешерү. Микроэлементлар яхшырак саклансын өчен, пешергән вакытта яшелчәләрне вакламагыз.

Шул ук вакытта организмда йодның артып китүе дә начар. Бу очракта селәгәй агу, авызда тимер тәме барлыкка килү, тәнгә чабырып аллергия чыгу кебек билгеләр күзәтелергә мөмкин.

Йодка бай ризыклар:



- Иң күп йод диңгез балыгы һәм диңгез продуктларында: тәрәч (треска) бавыры, пикша, сайра, лосось.
- Җиләк-җимешләрдән беренче урында фейхоа тора. Икенче урында – хөрмә, ананас, кавын, банан, алма (аеруча төше), цитруслылар, слива, җир җиләге һәм виноград.



- Ярмалардан: тары, солы, карабодай, бодай һәм арыш оны.
- Йодка гөмбә, бигрәк тә шампиньон гомбәсе бай.



- Яшелчәләрдән: брокколи, фасоль, шпинат, чөгендер, кишер, бәрәңге.
- Каймагы алынмаган сөт.
- Йомырка.

Фото: www.pixabay.com

Йод куллануның Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы тәкъдим иткән нормалары:

- 1 яшькә кадәрге балалар – тәүлегенә 50 мкг;
- 2–6 яшькәчә булган балалар – тәүлегенә 90 мкг;
- 6–12 яшькәчә булган балалар – тәүлегенә 120 мкг;
- Яшүсмерләр – тәүлегенә 150 мкг;

Йод кытлыгының билгеләре:

- иммунитет көчсезләнү;
- эмоциональ проблемалар – йончу, йокы туймау, ярсучанлык;
- аяк-кулларда, күз төпләрендә шешенкелек;
- йөрәк-кан тамырлары системасында тайпылышлар – аритмия, түбән яки югары кан басымы;
- канда гемоглобин күләме киму;
- укуда проблемалар башлану;
- баланың акрын үсүе, соңга калып җитлегүе.



Материал ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



Алдагы саннарыбызның берсендә без кеше гомере өчен куркыныч тудыручы җитди чирләрнең берсе – кискен панкреатит турында сөйләшә башлаган идек. Бүген сүзебез ашказаны асты бизенең дәвамлы ялкынсынуы, ягъни хроник панкреатит турында булыр. Бу хакта безгә Россиянең һәм Татарстанның атказанган табибы, медицина фәннәре докторы, КДМАның ашыгыч медицина ярдәме кафедрасы мөдире, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш хирургы һәм трансплантологы Андрей АНИСИМОВ сөйли.

ХРОНИК ПАНКРЕАТИТ

Панкреатит диагнозы пациентларга торган саен ешрак куела, һәм ул төрле өзлегүләр, катлауланулар белән уза. Аның белән ир-атлар да, хатын-кызлар да бердәй авырый. Яшьләрне дә аямый ул.

Кискен панкреатиттан аермалы буларак, аның дәвамлы формасы озакка сузыла һәм даими кабатланып тора. Ашказаны асты бизендә ашкайнату ферментларының җыелып торуы аның ялкынсынуын кузгатып җибәрүче механизм булып санала. Бу ферментлар үтә дә агрессив. Әгәр дә алар уникеилле эчәккә иреклe агып төшә алмый икән, ашказаны асты бизенең тукымаларын тарката башлый, чөнки аның үзе җитештергән ферментлардан үзен саклау механизмы юк. Таркалган тукымалар үлә, эчәклекнең ул тукымаларга тиеп торган өлеше ялкынсына, көпшәкләнә һәм бактерияләрне тоткарлау функцияләрен үти алмый башлый. Эчәклектә яшәүче бактерияләр канга үтеп кереп, сепсис та башланырга мөмкин.

Дәвамлы панкреатитның иң еш очрый торган сәбәпләре:

- алкоголь, бигрәк тә майлы ризыклар белән бергә кулланганда.
- нәселдәнлек;
- үт куыгындагы ташлар (аеруча хатын-кызларда еш очрый);
- дөрес тукланмау;
- ашкайнату органнары аномалиясе;
- артык авырлык;
- даими стресс халәте.

Дәвамлы панкреатитны дәвалау:

- диета һәм ашау режимын төгәл саклау (бу бик мөһим шарт булып тора);
- табиб кушуы белән авыртуны басучы дарулар куллану;
- ашкайнатуны яхшырту өчен табиб ферментлар билгеләргә мөмкин;
- кандагы шикәр күләмен даими күзәтеп тору.

Фитотерапия:

■ Каен җиләге – җиләге, яфрагы һәм тамыры да файдалы. Аның җиләкләренең сутын, яфраклары һәм тамырларының (чәчәк атканда казып алырга кирәк) төнәтмәсен кулланалар. 1 аш кашыгы вакланган тамырга 1 стакан кайнап торган су коеп, 45 минут төнәтәләр. Көненә өч тапкыр берәр стакан эчәсе.

■ Кара җиләк – яңа җыйганын яки кипкәнен кулланалар. 1 аш кашыгы җиләкне 1 стакан суга салып, 5 минут кайнаталар һәм көнгә 2-3 стакан эчәләр.

■ Карга миләше (бузина) – 1 аш кашыгы кипкән җиләкне 1 стакан кайнар суга салып, 5 минут пешерергә һәм көнгә 3 тапкыр 1/3 стакан күләмендә эчәргә.

■ Гади маргаритка – 3 чәй кашыгы вакланган үләнне бүлмә температурасындагы 1 стакан суга салып, талгын утта 4 сәгать төнәтергә һәм бер ай дәвамында көнгә өч тапкыр 1/3 стакан күләмендә эчәргә.

! Әлеге төнәтмәләрне бары тик табиб белән киңәшеп кенә кулланырга кирәк!



Ярамый:

■ **майлы, ачы ризыклар, тәмләткечләр, кырку соуслар, маринадлар, тозланган ризыклар, яңа пешкән ипи, камыр ашлары, майлы ит һәм балык шулпалары, субпродуктлар, ак башлы кәбестә, чи яшелчәләр, борчак һәм фасоль, сарымсак, каты чәй һәм кофе, шоколад, туңдырма, газлы сулар, исерткеч эчемлекләр, сөт.**

Ярый:

■ **парда яки томалап пешерелгән майсыз ит (күркә, йорт куяны, тиресе салдырылган тавык ите), парда яки томалап пешерелгән майсыз балык, суда гына пешкән боткалар (тары боткасыннан тыш), майсыз кефир һәм эремчек, яшелчә шулпасында пешкән ашлар, томалап яки парда пешкән яшелчәләр, искергән ипи.**



Материал ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат хезмәте җитәкчесе Әлфия Хәсәнова ярдәме белән әзерләнде.


Фото: Анна Арахамия

Ризыкта күңел җылысы

Фермерлар, гадәттә – тыйнак, нык рухлы, эшче кулларга хөрмәт белән караучылар. Җитештергән продукцияләре дә гап-гади итеп төрелгән, рекламалар белән дә иркәләнмәгән, теләсә нинди кибет киштәләрендә дә ятмый. Ләкин бер ашап, тәмен татып карасаң башка онытмыйсың инде, чөнки аларда өйдә әни әзерләгән ризык тәме. «Гудакен» фермер хуҗалыгы җитештергән продукцияләр дә – шундыйлардан. «Безнең ризыкларны сатып алыр өчен Казанның үзәгеннән үк киләләр», – ди хуҗабикәсе Кадэрия ЛОТФУЛЛИНА. Хәзер инде килеп тә йөрмәячәкләр. Фермер продукциясе чын мәгънәсендә турыдан-туры кулланучылар өстәленә барып керә. Ә бу исә, арадашчыларның өстәмә хакларыннан тыш, яңа гына әзерләгән ризык дигән сүз.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Ике меңенче еллар башында кичәге прапорщик Кадэрия фермерлык белән шөгыльләнергә ниятли. Балачагы каз-үрдәк арасында узган хатын озак уйлап тормый, кошчылык тармагына тотына. Инкубатордан бер көнлек чеби, үрдәк, каз, күркә бәбкәләре алып, халыкка сата. Бу агым көйләнгәч, яңадан җиң сызганып эшкә керешә. Яшел Үзән районындагы Осиново бистәсендә элеккеге күркә үстерү комплексын сатып алып ремонтлый да эшкәртү линиясе ача. Пилмән, мантый, котлет кебек ярымфабрикатлар ясап сатарга аңа кулланучылары тәкъдим итә. Менә инде ничә ел ул аларны үз продукцияләре белән сөендерә. Ике ел элек ысланган ит ясау линиясе ачалар. Хәзер алар җитештергән продукция төре йөзгә җитә. Ә иң мөһиме: бу колбаса нинди иттән ясалды икән дип аптырыйсы юк. Фермер кошларны үзе үстерә, үзе эшкәртә, үзе үк сата да.

Иң борынгы тамырлары күчмә тормыш рәвешенә барып тоташкан татар халкында ит гомер-гомергә табын түрендә була. Аны чи килеш каклау борынгы дәверләргә үк барып тоташа. Ыслау алымы XX гасыр башларыннан кулланылышка керә. Ә кош итеннән колбасаларны хәзерге заманда гына ясый башлыйлар. «Гудакен» фермер хуҗалыгында ит эшкәртү рецептлары әнә шулай тарих битләреннән җыела. Әрмән, грузин, азәрбайҗан, башкорт кухнясыннан да иң яхшы алымнарны сайлап алалар. Шуңа күрә рецептлары «фирменный». «Башка бер сәүдә ноктасында да безнең рецептлар буенча әзерләнгән продукция таба алмаячаксыз», – ди Кадэрия Лотфуллина. Серне исә җиде йозак астында саклыйлар. Шулай да фермер хуҗалыгындагы директор урынбасары һәм баш технолог та булып эшләгән Георгий Тамразов безгә сер итәгеен бераз ачып күрсәтте. Мәсәлән, алар ыслар алдыннан итне «Адыгей тозы» эретелгән рассолда тоталар. Шуңа күрә дә ризык эре супермаркетларда сатылган продукция тәменнән күпкә үзгә. «Иң элек ит тәмен саклап калабыз. Тәмләткечләр дә күп кулланмыйбыз. Кайдадыр сарымсак, кайдадыр анар төшләренең үзенчәлекле тәмен тоясың. Язылган кануннар да, санитар норма-

лар да стандартлардан бераз читкәрәк китәргә ирек бирә», – ди технолог.

Үрдәк казылыгы – «Гудакен» фермер хуҗалыгының горурлыгы. Аны башка беркайда да җитештермиләр. Вакуумлы упаковкадагы «Утка табака»ны хуҗабикәләр үз итә икән. «Бик популяр ул безнең», – ди Кадәрия Лотфуллина. Өйгә алып кайтып, махсус пакетка салып духовкага куясың да, сәгать ярым эчендә бәйрәм табыны әзер. Кайчандыр борынгылар мичтә томалап пешергән үрдәк ите дә шулай хуш исле булып мәмрәп торгандыр. «Цыплёнок табака» да тәмгә үрдәктән калышмый... Өстәлгә турап куяр өчен дә төрле рулетлар, ысланган итләр ясыйлар. Ысланган сардельдәлар җитештерергә ниятлиләр – кыздырырга да, пешереп ашарга да мөмкин аларны.

Гадәттә, очсыз ит продукцияләре составына соя аксымы кушыла. «Гудакен»ның бар продукциясе натураль. Бары тик фарш составы гына төрле. Иң яхшы фарш түш итеннән. Бот итеннән ясалганның сыйфаты башкачарак. Продукциянең бәясе дә шуннан чыгып исәпләнә. «Без соя да, терлек майларын да кушмыйбыз. Максат бит үзебез үстергән кошларны эшкәртү», – ди Кадәрия Лотфуллина. Бройлер итеннән ясалган пилмәннәрдә бары ит, тоз борыч кына салынган, күркәнекенә бераз сарымсак, үрдәккә кориандр, казга хмели-сунели тәмләткече кушылган. Башка берни юк!

Фермерлар, кайбер саран бизнесменнар кебек, һавадан да акча ясау ягында түгел. Акча, товар әйләнеше зур күләмдә булмаган фермерларга һәр клиент кадерле. Ә халык иң элек сыйфатка игътибарлы. Бер тапкыр сатып алган кеше, инде башка «Гудакен» белән аерылырга теләмәсен. Моның өчен бәяләрнең иртәгә кисәк кенә артмаячагына ышанычы булырга тиеш.

Бу фермер хуҗалыгының тагын бер өстенлеге – бөтен продукцияләренә «Хәләл» стандарты сертификаты бар. Хәләл статусы – продукция сыйфаты стандартларының яңа дәрәҗә символы. Ризык натураль ингредиентлардан табигый сыйфатларын саклап кала алган технологияләр буенча әзерләнә. Иң мөһиме: производствода да, күңелдә дә чисталык...

«Гудакен»да ачы камырга әзерләнгән тәмле ипиләр, авызда эреп китәрлек пироглар да пешерәләр. Үрдәк, каз итеннән ясалган бәлеш үзе генә дә ни тора! Ә токмачлары үзләрендә җитештерелгән сап-сары йомыркага басыла.

Осиноводагы җитештерү мәйданы янында заманча интерьерлы кафе белән банкет залы да ачканнар. Бик зур балалар бүлмәсе дә эшли. «Болар барысы да үз продукциябезне реализацияләү өчен эшләнде», – ди Кадәрия Лотфуллина.

Хәзерге тизлек заманында күпләр кибеттән азык-төлек җыярга да вакыт таба алмый. Моны уйлап, «Гудакен» кулланучыларына үзе барып җитәргә уйлый. Бүген бирелгән заказлар иртәгә инде өйгә килеп тә җитә. Беренче аш, икенче аш әзерләргә продукция күп аларда, чәй табынына да десертлар күп. Кибет киштәләрендә ятып искереп беткән дә түгел, кичәбүген генә әзерләнгән тазә тәм-томнар. Үзебезне ярату бит ашаудан башланырга тиеш. Күңел биреп әзерләгән ризык кына тәнгә сихәт бирә.





PRESSA

Өлеш рецепты – авторның үзеннән





■ Мәскәү кунаклары белән. Уртада – Юныс Әхмәтҗанов, Фатыйма ханым Мәҗитова – сулдан икенче. Фото: Ф. Мәҗитова архивыннан.

«Хатын-кыз галәме» рубрикасының бүгенге кунагы пешеренергә яратучы гади генә ханым түгел. Фатыйма МӘҖИТОВА – халкыбызның легендар аш-су остасы Юныс Әхмәтҗановның шәкерте. Үзе дә Россиянең атказанган сәүдә хезмәткәре, «Мастер-повар» дәрәҗәсе алган ашчы. Бүген күпләр яратып пешерә торган, өчпочмак-сумсалар кебек үк, кулланучылар күңеленә хуш килгән өлеш дигән ризыгыбыз да бар безнең. Менә шул өлешнең авторы – Фатыйма Мәҗитова! Без аңардан өлешне уйлап табу тарихы белән кызыксындык.

– Бауман урамында «Чәй йорты»н ачкач, яңа төр камыр ашы пешерергә кирәк иде, – дип, шул вакытларны искә алды оста. – Ул елны ит комбинатында үрдәкләр күп булды, складлар тулды. Шул үрдәк итеннән өлеш пешерү рецептын уйлап таптым. Ә исеменең сере гади генә. Аның ите кисәкләп – өлешләп салына. Шуңа күрә өлеш дип атала да. Соңрак тавык итеннән дә пешерә башладык. Үрдәк белән тавык итен бергә кушып пешерсәң дә бик тәмле. Каз ите өлеш пешерү өчен бармый.

Фатыйма апа Мәҗитова – бүгенге Әтнә районы Олы Бәрәзә авылы кызы. Мәктәптән соң Казан кулинария училищесына укырга керә. Шуннан бирле үз эшенә тугры ул. Ә Юныс Әхмәтҗанов белән танышлыгына килгәндә... «Мәскәүдә ВДНХда узган кулинар бәйгедә катнашу өчен унҗиде кешелек төркем тупладылар. Мин дә шул төркемдә идем. Бөтен союздаш республикалар Мәскәү халкын атна буе үзләренең милли ашлары белән сыйлады. Ул елларда башкалада татар халкының милли ашларын белүчеләр сирәк иде әле. Без пешергән чәкчәкләрне күреп: «Бу кукурузмы?» – дип гаҗәпләнәләр. Безнең эшне бик югары бәяләделәр: Юныс Әхмәтҗанов – алтын, ашчылар – көмеш, ә мин бронза медаль белән бүләкләндем, – дип хатирәләрен яңарта ул. – Юныс абый ихлас, балаларча самими кеше иде. Ризык турында шулкадәр тәфсилләп сөйли, әле авыз иткәнче үк син инде аның тәмен тойгандай буласың. Ресторанга килгән һәркем белән кул биреп күрешә, озаклап сөйләшә. «Кем иде ул?» – дип сорасаң, «кемлеген белмим, әле беренче генә күрәм», дияр. Татар ашларын югары дәрәҗәгә күтәрү өчен ул бик күп көч куйды. Районнарга, авылларга йөреп, халыктан борынгы рецептлар җыйды. Аларның һәркайсын Мәскәүдә раслатты...

Татар ашларын башкалада тәкъдим итүләр еш булды. Без 1980 елгы Олимпиада кунакларын да татар ашлары белән сыйладык».

Юныс Әхмәтҗановның вафатыннан соң, Фатыйма ханым остазының эшен дәвам итә, татар милли ашлары турында китаплар бастырып чыгара, «Сөембикә» журналында аш-су рубрикасын алып бара, журналның җәмәгать киңәшчесе була. Бүген исә Фатыйма Мәҗитова безгә үзе уйлап чыгарган өлеш пешерү серләрен ача.

– Кулинария кибетләрендә сатылучы өлеш белән минем рецепт буенча әзерләнгәне арасында җир белән күк аермасы, – ди ул.

Чын өлештән авыз итеп карыйк әле!


Фото: Анна Арахамия

Кирәк

- (10 өлешкә)
- 130 г сыер мае;
- 300 г кибет каймагы;
- 2 йомырка;
- тәменчә тоз;
- 20 г шикәр комы;
- 700 г чамасы иләнгән он;
- бер чеметем чәй содасы.

Эш барышы

(камыр басабыз)

■ Савытка йомырка сытып, чәнечке белән туглыйбыз. Шикәр комы, чәй кашыгы очына гына элеп тоз салабыз. Кабат туглыйбыз.

■ Кибет каймагын кушып, яхшылап катнаштырабыз.

■ Бүлмәдә торып йомшарган яки эретелгән акмай салабыз.

■ Он кушып, камыр басабыз. Камыр йомшак була, әмма кулга ябышмый.

■ Басып бетергәч, 20 минутка суыт-кычка куеп торабыз.

Эчлек әзерләү

■ Бер өлешнең эчлеге өчен 2 кисәк ит: берсе – 45, икенчесе – 25–30 г, 50 г бәрәңге, 13 г суган кирәк.

■ Бәрәңгене өчпочмакныкыннан эрерәк итеп, шакмаклап турыйбыз.

■ Итне юып, кисәкләргә бүләбез (сөякләре белән бергә). Суган белән бәрәңгене, итне бер савытка салып, тоз һәм борыч сибәбез.

Өлешне ясау

■ Бер өлеш өчен 100 һәм 30 грамм-лы ике кисәк камыр кирәк. Зурра-гы – төбенә, кечкенәсе капкач өчен.

■ Зуррак камырны уклау белән җәеп, шуңа эчлекне салабыз. Бер мөһим нәрсә: башта бәрәңге салына, аның өстенә ике кисәк ит куела. Бер ки-сәк – түш ите, икенчесе бот тирәсе булса яхшырак. Майны эчлеккә куш-маган булсагыз, һәр өлешкә 1 аш кашыгы акмай салып чыгабыз.

■ Бәләкәй камырдан кечерәк җәем җәеп, ит өстенә каплыйбыз. Аскы җәемнең читен күтәреп, капкач камы-ры белән тоташтырабыз, кырыйларын бөреп чыгабыз.

■ Өлешләрнең өстен 1 йомырка са-рысына 1 аш кашыгы сөт кушып майлыйбыз һәм 190 градуска кадәр кызган мичкә куябыз. 15 минуттан температураны киметәбез.

Өлеш 140–150 градуста 60 минут чамасы пешә.

PRESSA



Сельдерей

Табигать – иң яхшы даруханә. Белеп куллансаң, андагы һәр үсемлекнең ниндидер шифалы үзлеге бар. «Дөрес туклану» рубрикасының авторы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА бүген сельдерейның файдалы үзлекләре турында сөйли.



Әлеге үсемлекне, һичшиксез, дару үләне дип әйтергә мөмкин. Аның составы бик бай һәм уникаль: кумарин матдәсе онкологик микропроцессларны тоткарлый, ацетилен һәм фенокислоталар да яман шеш башлану ихтималын кисәтә. Фталидлар исә кан тамырларын киңәйтә, кан басымын төшерергә ярдәм итә. Организмның каршы торучанлыгын арттыручы С витамины турында болай да беләсез инде. Буыннар авыртканда да әлеге үсемлекнең шифасы бар: бәвел кудыру үзлеге белән ул буыннарга утырган тозларны эретеп чыгара. Ашкайнату системасына булган тәэсире дә исткиткеч: эч күбүне бетерә, артык авырлык белән көрәшергә ярдәм итә, бавырны саклый, холестеринны киметә, хәтта эренле бетчәләрдән, псориаздан, экземадан да дәвалау үзлегенә ия.

Сельдерейны ничек кулланырга?
Аны салатларга, ашларга кушарга, томалап пешерергә була. Ә менә сельдерейның согын куллану тагын да файдалырак. Клетчатка булмаганлыктан, андагы файдалы матдәләр тизрәк, тоткарлыксызрак үзләштерелә. Сельдерей чи килеш ашар өчен дә тәмле. Бер стакан сокны сыгып алырдай күләмдә кулланырга була аны.



Фото: www.pixabay.com

Сельдерей согын нинди микъдарда эчәргә?
Шифалы үзлекләрен тояр өчен, тәүлегенә 450 мл сок куллану идеаль вариант булып санала. Сок белән дәвалануны аз гына күләмнән башлап, көн дә арттыра барырга кирәк. Тәменә ияләнер өчен, баштагы мәлләрдә сельдерей согына лимон, лайм, алма яисә берәр үлән кушып эчә аласыз.

Аны кайчан куллану отышлырак?
Сельдерей согы иртән ач карынга эчелә. Башта бер стакан җылы су эчеп куйсагыз яхшы. 15–30 минуттан соң иртәнге ашны ашарга була. Иртән эчә алмасагыз, көннең башка вакытында – ашарга ярты сәгать кала яки ашаганнан соң ярты сәгать узгач та мөмкин.

Сельдерей согын алдан әзерләп куярга буламы?
Әле генә сыгылган сок файдалырак, билгеле. Андый мөмкинлек булмаса, әзер сокны өсте ябулы савытка салып, суыткычта сакларга мөмкин. Әмма ул бер тәүлектән артык сакланмый.

Сокны ничек әзерләргә?
Соксыккыч куллану иң кулай вариант булып санала. Ул булмаса, сельдерейны иттарткыч аша чыгарып, согын марля аша да сөзә аласыз.

Сельдерей согы куллана башлагач, күпләр эчәклектә үзгәрешләр тоя. Бу – организмның токсиннардан чистарыну процессы, борчылырга кирәкми. Сельдерей согы эчәклектәге патоген микроорганизмнарны юк итә, бавырны чистарта. Эчнең йомшаруы әнә шуннан, әмма ул озакка бармый, организм күнеккәч, үзеннән-үзе бетәчәк.

Кучкар. Эштә, гаиләдә проблемалар килеп чыкмасын өчен һәрвакыт уяу булырга кирәк. Көтмәгәндә тәнкыйть утына тотарга мөмкиннәр. Әйткән сүзләрегезне кирегә борып сөйләүчеләр дә табылыр.

Үгезбозау. Катлаулы ситуацияләр килеп чыкканда югалып калмыйсыз. Ләкин бу айда мәшәкатьләрне хәл итү сезгә җиңел бирелмәс. Борчылмагыз, проблемалар вакытлыча гына, аннан бар да әйбәт булачак.

Игезәкләр. Эчке тоемлавыгызга колак салсагыз, күп кенә авырлыкларны җиңеп чыгарсыз. Үз көчегез җитмәгәндә дусларыгыз, якыннарыгыз ярдәмгә килер. Акча белән сак булыгыз.

Кысла. Кискен үзгәрешләргә карышмагыз – бар да яхшыга булыр. Үз фикерегезгә таянып эш итсәгез, бу айда уңышка ирешәчәксез. Ай уртасында акча эшләү мөмкинлеге килеп чыгар, аны кулдан ычкындырмагыз.

Арыслан. Бу айда үзегездә теләсә кайсы мәсьәләне хәл итәрлек көч табарсыз. Яраткан кешегез белән күбрәк аралашырга тырышыгыз. Эштә сабыр булу сорала.

Кыз. Борчуларыгыз, ниһаять, чишелер. Тормыш үз җаена гына барыр. Якыннарыгызга ярдәм итеп, үзегезнең ышанычлы һәм эчкерсез икәнлегегезне күрсәтә алырсыз.

Үлчәү. Уңышларыгыз һәм уңышсызлыкларыгыз тормышта дөрес юл сайлагансызмы, юкмы икәнен күрсәтер. Мөһим эшләрегезне калдырып, көч җыеп алыгыз, саф һавада күбрәк булыгыз.

Чаян. Бу айда иң мөһим бурыч – шәхси тормышыгызны җайлау. Әмма төпле акыл белән эш итәргә кирәк. Эштәге унышларыгыз белән мактанмау хәерле.

Укчы. Уңыш алып килә торган эшкә юлыгырсыз. Ай уртасында кәефегез бозылып, якыннарыгызны үпкәләтүегез бар. Сүзләрегезне уйлап әйтергә өйрәнегез.

Кәҗәмөгез. Шәхси тормышыгызда йөрәгегез ничек кушса, шулай эшләгез. Үзегез турында кайгыртырга онытмагыз.

Сукояр. Күңел халәтегез һәм финанс хәлегез яхшырачак. Яңа эш эзләүчеләргә әйбәт вакыт. Якыннарыгыз уй-ниятләрегезне хуплаганын күреп, үзегезне бәхетле хис итәчәксез.

Балык. Якыннарыгызның хаталарын гафу итеп, ярдәм итәргә тырышыгыз. Бу вакытта комедия карау, күңелне күтәрә торган китап уку хәерле.

тест

ӘЙДӘП БАРУЧЫМЫ, БУЙСЫНУЧЫМЫ?

Кем сез: әйдәп баручымы, әллә көчлеләр салган юлдан килешеп атлаучымы? Менә бу тест аркылы тормыштагы позициягезне тикшереп карагыз әле.

Сорауларга «әйе», «юк», «белмим» дип җавап бирәбез.

1. Тормышымда булган һәрнәрсәгә зур җаваплылык белән карыйм.
2. Башкалар миңа карата мөнәсәбәтен уңай якка үзгәртсә – проблемаларым азрак булыр иде.
3. Уңышсызлыкларымның сәбәбе турында озаклап уйланып тормыйм, алга таба хәрәкәт итәргә яратам.
4. Кайвакыт үземне «бәхетсезләр йолдызлыгында» туганмын сыман хис итәм.
5. Һәркем үз проблемалары өчен үзе гаепле.
6. Миңа кемнәр йогынты ясаган – тормышым өчен дә алар җаваплы дип уйлыйм.
7. Авырып китсәм – үзлегемнән дәваланырга тырышам.
8. Хатын-кызның кызып китүенә, ярсуына еш кына башкалар гаепле.
9. Теләсә кайсы проблеманы да хәл итеп була.
10. Миңа булышкан кешеләргә дә рәхмәтлемен, үзем дә башкаларга ярдәм итәргә яратам.
11. Конфликт килеп чыкса, гаеп эзләүне үземнән башлыйм.
12. Кара мәче юлымны киссә, икенче якка чыгам.
13. Бернигә дә карамастан, һәр кеше көчле һәм мөстәкыйль булырга тиеш.
14. Үземнең кимчелекләремне яхшы беләм һәм башкаларның да ул сыйфатларыма тыныч каравын телим.
15. Тәэсир итә алмаганда – килешү ягын карыйм.

Нәтиҗәләр ясыйк. 1, 3, 5, 7, 9, 11, 13 сорауларына «әйе» дигән һәр җавапка – 10 балл, 2, 4, 6, 8, 10, 12, 14, 15 сорауларына «юк» дигән һәр җавапка 10 балл куябыз, «белмим» җавабына – 5 балл.

100–150 балл. Сез – үз тормышыгызның җаваплы капитаны. Башкаларны гаепләмичә генә авырлыкларны кичеп чыга беләсез. Һәр сорауга төгәл җавабыгыз бар. Көчле кеше, чын лидер икәнегез күренеп тора.


50–99 балл. Тормышны үзегез алып барасыз. Тормышка җайлаша беләсез, һәрвакыт аек акыл белән эш йөртәсез. Сезгә бер халәттән икенчесенә күчү җиңел бирелә. Бу сыйфат сезнең нервыларны саклый, тыныч күңел белән яшәргә ярдәм итә.

49 баллга кадәр. Сез башкаларга буйсынып эш йөртергә яратасыз. Уңышсызлыклар өчен дә башкаларны гаепләү дөресрәк сыман тоела. Мөстәкыйль фикер йөртергә тырышып карагыз әле. Башка кешеләрнең хыялын чынга ашырып яшәгәнче, үзегез ни телägәнне аңласагыз яхшырак бит.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен
Раилә ХӘЯЛИЕВА,
Лилия ГӘРӘЕВА
әзерләде.







ТАРИХЫБЫЗ – КИНДЕРДӘ

«Татарстан АССР төзелү турындагы Декретка кул кую» картинасы. Әлеге әсәрне Харис Якупов һәм Лотфулла Фәттахов 1950 елда иҗат итәләр. Икесе дә Татарстан рәссамнары легендасы, башка рәссамнар өчен тырышлык, осталык үрнәге. Татарстан сынлы сәнгатенең совет чорын искә алганда, Харис Якупов иҗатына һәм эшчәнлегенә аерым тукталасы килә. 1951–1975 елларда ТАССР Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе буларак, Рәсем сәнгате фонды бинасын төзетүгә, СССР сәнгать академиясенең Казандагы иҗат остаханәсен ачуга зур өлеш керткән, күпсанлы студентларны укыткан зур шәхес ул. Кабатланмас күләмле әсәрләр язып калдырган Харис Якупов үз китапларында рәсем сәнгатенең бер дә җиңел сәнгать булмавын ассызыклаган. Әмма гасырлар, еллар узса да, татар сынлы сәнгать дөньясына яңадан-яңа талантлар киләчәк.


Инде 1920 елларда ук татар рәссамнары үз һөнәри осталыклары белән күпләрне җәлеп иткән, милли сәнгатебезнең чишмә башында торучы иҗатчыларыбыз графикага, китап иллюстрацияләренә, сәяси плакатларга аеруча зур игътибар биргән. Мәскәүдәге уңышлы күргәзмәләрдән соң, 1931–1933 елларда татар рәссамнары Франциядә һәм АКШта узган Халыкара күргәзмәләрдә катнашкан.


1935 елның 3 августында СССР Рәссамнар берлегенең татар бүлеген оештыру турында махсус карар кабул ителгән, 1957 елга кадәр ул – ТАССРның совет рәссамнары берлеге, 1957–1960 елларда – СССР Рәссамнары берлегенең татар бүлеге, 1960–1968 елларда РСФСР Рәссамнар берлегенең татар бүлеге, ә 1968 елдан ТАССР Рәссамнар берлеге дип аталып йөртелгән. Кызганыч, күп рәссамнарыбыз Бөек Ватан сугышыннан әйләнеп кайтмады. Талантлы рәссамнарыбыз тарафыннан сугыш кичерешләреннән торган графика битләре, совет халкының сугышта күрсәткән каһарманлыгын раслаучы эшләр, туган якны зурлаучы пейзажлар, җәмәгать аңын активлаштыруга юнәлдерелеп, тыныч көннәрне сурәтләүче тематик картиналар, гасыр төзелешләрен югары күтәрүче индустриаль пейзажлар, сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы алдынгыларын, гомумән, хезмәт кешеләрен данлаучы портретлар иҗат ителгән. Ә «җепшеклек» елларында осталар өчен уй-фикерләрен, рухи эзләнүләрен чагылдырган әсәрләр иҗат итү мөмкинлеге туган. Соңрак яшьләр метафоралы сурәтләү алымнарына күчә алган. Күп картиналарда Ватанга булган ихлас мәхәббәтне тоясың, алар аша Татарстан гимнындагы изге теләкне ишетеп буладыр кебек: «Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз!» Үзгәртеп кору елларында исә милли үзаң үсү сизелә: шамаил язу юнәлешенең киң таралуы – ачык мисал.

ТАССР тарихын киндерләрдә тасвирлаган, шул чор рухын тоемларга булышкан мәшһүр рәссамнарыбыз иҗаты республика дәүләт музейлары тупланмаларында саклана. Музей җыелмаларында конструктивизмны, Ленинны монументализацияләүне, гади хезмәт батырлыгына дан җырлауны, региональ акцентлы социалистик реализм һәм импрессионизм юнәлешләрен барлыйбыз.

Танылган рәссамнарыбыз күп, бик күп безнең. Бакый Урманче, Рушания һәм Харис Якуповлар, Гайшә Рахманкулова, Лотфулла Фәттахов, Байназар Әлминов, Мәхмүт Усманов, Фәйзрахман Әминов, Илдар Әхмәдиев, Тавил Хаҗиәхмәтов, Николай Кузнецов, Владимир Попов, Искәндәр Рафиков, Әхсән Фәтхетдинов, Илдар Зарипов, Рифкать Вахитовлар... Аларның барысы да диярлек Казан сынлы сәнгать училищесында укыган, шунда укыткан да... 2020 елда 125 еллык юбилеен билгеләп үтәчәк Казан сынлы сәнгать мәктәбе – республика рәссамнары өчен бүген дә осталык мәктәбе. Бу дәвердә бар иҗатчыларның тематик палитрасы соцреализм белән чикләнгән булса да, без әле дә аларның эшенә сокланып карыйбыз.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА












Фото: www.art16.ru@Елена Сунгатова һәм редакция архивыннан

Лотфулла Фәттахов, Харис Якупов.
«Татарстан АССР төзелү турындагы Декретка кул кую».
Мәхмүт Усманов. «Түбән Кама. Нефтехим».

Николай Кузнецов. «Бүгенге Идел ярлары».
Закир Батраев. «Казан университеты».
Фәйзрахман Әминов. «Сабантуй».
Бакый Урманче. «Салтыкта печән өсте».
Илдар Әхмәдиев. «Безнең бригада. Туй».



Рамис САФИН, Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе, Ульяновск шәһәренең Иҗтимагый палата әгъзасы.

Борынгы Сембер – Татарстан АССР оешуга үзеннән зур өлеш керткән шәхесләрне биргән төбәкләрнең берсе. Тарихтан укып беләбез, Октябрь инкыйлабыннан соң Россиядә зур географик бүленешләр башлана, данлыклы якташыбыз Владимир Ильич Ленин милли республикаларны оештыруга аерым игътибар бирә. Танылган рәссамнар Лотфулла Фәттахов һәм Харис Якупов шул елларның истәлеге итеп Ленинның ТАССР оешу турындагы Декретка кул куюын тасвирлаган картина иҗат итәләр.

Татарстан АССРны төзүдә актив катнашкан семберлеләрнең тагын берсе – Иске Кулаткы районы Иске Зеленай авылында туып-үскән Борһан Мансуров. Егерменче елларда ул Казанда зур җәмәгать эше алып бара, партия һәм совет органнарында хезмәт итә. ТАССР оешкач, республика Үзәк Башкарма комитеты Президиумы секретаре итеп сайлана.

1959–1966 елларда ТАССР Министрлар Советы Рәисе булып эшләгән Абделхак Абдразяков та – Иске Кулаткы районыннан. Яңа Татарстан Республикасы эшчәнлегендә дә якташларыбыз зур хезмәт куйды. Радищево районы кызы Нурсинә Әбдрәшитова 1995–1998 елларда – Чаллы шәһәре вице-мэры, аннары – Татарстан Дәүләт Советы секретаре, Чынлы районында дөньяга килгән шагыйрь Ренат Харис мәдәният министры урынбасары, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары вазыйфаларын башкарды.

Тарихи ватаныбыз Татарстан тарихында якты эз калдырган бу данлыклы якташларыбыз турында өлкәбезнең Мәдәният үзәге музеенда кызыклы экспонатлар куелган.

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

